ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 5 (341)
МАЙ 2020

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ



ИГӘ БЕЛГӘН ИГЕН АШАР

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары: Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
Чыгарылыш мөхәррире: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
Веб-редактор: Алсу Дәүләтшина
Авторлар: Мөршидә Кыямова, Илдус Заһидуллин, Ксения Семина
Фотографлар: Александр Ефремов, Ната Смирнова
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Ләйсән Һадиева
Тышлыкта: яшь механизатор Айназ Шәмсетдинов (Кама Тамагы районы). Александр Ефремов фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
1 150 данә

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-1072
Басарга кул куелды: 25.05.2020
Басмадан чыкты: 28.05.2020

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

Коммерция директоры:
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 3050 данә тираж белән чыга. Гомуми тираж: 4200 данә. Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ТАССР 100 лет ел

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ МАХСУС ПРОЕКТЫ

Май аенда Татарстан Республикасына 100 ел тулды. 1920 елның 27 маенда Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының һәм РСФСР Халык Комиссарлары Советының ТАССР төзелү турындагы Декретына кул куела, ә шул ук елның 25 июнендә Казан губерна башкарма комитеты бөтен вәкаләтләрен яңа республиканың Революцион комитетына тапшыра. Шуңа да без республиканың туган көнен майда да, июньдә дә билгели алабыз.

100 ел! Түгәрәк тә, әһәмиятле дә юбилей: гасыр гына түгел, ә тарихның бер дәвере дә!

2020 елның декабрендә шулай ук 100 еллыгын билгеләячәк «Татарстан» журналы уртак юбилей уңаеннан «Буыннар» дигән проект әзерләде – анда без Татарстаныбызның олы тарихын язган кешеләр турында сөйләдек. Без республика тарихын буыннар тарихы аша күрсәтергә булдык: материал күләме зур булу сәбәпле, без ул тарихны шартлы рәвештә икегә – ике санга бүлдек. Май санында – 1920 нче еллардан 1960 нчы елларга кадәрге буыннар тарихы.

Моннан тыш, шушы май санында шулай ук быелгы чәчү кампаниясен яктыртабыз. Дөньяда нинди генә хәлләр булмасын, чәчү үз вакытында башкарылырга тиеш. Быел ул ничек үткән, нинди үзенчәлекләре бар – бу турыда игенчеләребез сөйли.

Безнең даими рәвештә алып барыла торган «Кече Ватан патриотлары» рубрикасында артист, күренекле нәфис сүз остасы Фәйзи Йосыповны искә алырбыз. Аның озын-озак иҗат гомере – ул да республика тормышының үзенә күрә елъязмасына тиң.

«Тарих» рубрикасы кысаларында безнең даими авторыбыз Илдус Заһидуллин 1812 елда Казан губернасының Наполеонга каршылык күрсәтүдә үзеннән нинди өлеш кертүе турында сөйли. Безнең тарих борынгыдан килә, ә тарихтан башка, мәгълүм булганча, бүгенге дә юк.

ЮБИЛЕЙ БЕЛӘН СЕЗНЕ!

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла
Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **933 сум 00 тиен**

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

Харис Якупов. «Хенде хох!» Разведчик сөйләве буенча. 1944 ел.

ҖИҢҮ! 1945–2020

WWW.PROTATARSTAN.RU

«Мин дүрт ел сугыштым. Минем рәсемле өч поход альбомым сакланып калды. Алар фронт тормышының авыр шартларында, сугыш арасында, су басу көннәрендә, нигездә, артиллерия снаряд гильзасыннан ясалган коптилка янына утырып, «үзебез өчен» башкарылган. Әлеге рәсемнәр сугыш юлларында күргән һәм үткәннәрнең ачык дәлиле булып тора. Аларда минем дусларым вә кардәшләрем, алар һәрвакыт минем күңелемдә сакланырлар»*.

(Харис Якупов. «Фронт зарисовкалары. Рәссам язмалары»)

© «Татарстан» журналы

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Язның бер көне ел туйдыра.
Республикада чәчү эшләре ничек бара

10. Зур елга утрауларында.
«Идел киңлекләре» дәүләт табигать тыюлыгы нинди статус бирә

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

14. Кече Ватан патриотлары.
Фәйзи Йосыпов – татар сүз сәнгате генералы

18. Тарихи сәхифәләр.
Казан губернасы 1812 елгы Ватан сугышында

22. Бөек Җиңүнең 75 еллыгына.
Ветераннарыбыз Хатирә һәм Мөбәрәкҗан Салиховлар турында

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ТАССР 100 ЛЕТ ЕЛ

26. ТАССРның 100 еллыгына.
Татарстан Президенты белән тарих дәресләре

32. 1920–1930. Яңа тормыш төзүчеләр буыны.
Республика каян башланган

46. 1930–1940. Беренче бишьеллыклар буыны.
Индустриальләшү һәм коллективлашу ничек барган...

56. 1940–1950. Җиңүчеләр буыны.
Сугышта һәм тылда Җиңүне ничек якынайтканнар

70. 1950–1960. Зур үзгәрешләр буыны.
Казан ничек яшәгән

86. 1960–1970. Галәмгә атлаучылар буыны.
ТАССРда нинди бөек төзелешләр барган

* Рәссам Харис Якупов турында тулырак – «Татарстан» журналы, 2019 ел, август

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

17.05



Владимир Путин, Россия Президенты, – «Россия 1» телеканалына биргән интервьюсында:

– Россия – ул ил генә түгел, ә чыннан да аерым бер цивилизация: төрледән-төрле гореф-гадәтләре, мәдәниятләре, диннәре булган күп милләтле ил... Әгәр без цивилизацияне саклап калырга телибез икән, әлбәттә, нәкъ менә югары технологияләргә һәм киләчәк үсешенә басым ясарга тиешбез.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

17.05

Сергей Лавров, Россия тышкы эшләр министры, – «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенә биргән интервьюсында:

– Татарстан Республикасы дөнья күләмендә билгеле, аны таныйлар. Россия Тышкы эшләр министрлыгының төбәкләр белән бергә эшли торган теләсә кайсы форматында диярлек Татарстан тәҗрибәсе Россия Федерациясенең башка субъектлары арасында иң перспективалы һәм кирәклеләренең берсе.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

18.05

Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Республикасы Президенты, – Россия Премьер-министры вазыйфаларын башкаручы Андрей Белоусовка юллаган мөрәҗәгатендә:

– Төбәк массакүләм мәгълүмат чаралары керемнәренең кискен кимүе аларның эшчәнлеген вакытлыча туктатып торуга, хәтта гомумән туктатуга китерергә мөмкин. Бу гражданнарның мәгълүмат белән тәэмин ителеше начарлануга китерәчәк, хакимият органнарын халык белән аралашуның нәтиҗәле каналларыннан мәхрүм итәчәк. Нәтиҗәдә бу иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкка һәм куркынычсызлыкка йогынты ясарга мөмкин.

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Республикада чәчү эшләре **НИЧЕК** бара

«Идел киңлекләре» дәүләт табигать тыюлыгы территорияләргә **НИНДИ** статус бирә

ЯЗНЫҢ БЕР КӨНЕ ЕЛ ТУЙДЫРА

– Әйдә, утырып карагыз, хәзерге тракторлар бик уңайлы, – диде Константин. Кызык булып китте: уйлап та тормыйча, тракторга менеп утырдым. Константин елмайды:

– Эссе түгелме, кондиционерны кабызыйммы? Нинди музыка тыңлыйсыз? Тракторның салонына күз салам: кыйммәтле чит ил машинасы диярсең – әллә нинди күрсәткечләре бар.

– Бу сиңа элеккеге МТЗ тракторлары түгел икән, – дим.

– Әлбәттә, – ди юлдашым. – Йөргәндә дә дөбер-шатыр бармыйсың...

Автор:
Руфия Фазылова

«ЯҢА ЮЛ»

Тракторда йөрү бәхете Буа районына баргач тәтеде. Майның кояшлы бер көнендә республика кырларындагы кызу эшне үз күзләребез белән күреп кайтырга ниятләдек. Сәяхәтне «Авангард» ҖЧҖнең «Яңа юл» бүлекчәсеннән башладык. (Ул «Ак Барс» ширкәтенә карый). «Яңа юл» Буа районындагы алдынгы хуҗалыклардан санала. Аның карамагында 5 мең гектар җир бар. Майның уникесенә бөртекле культураларны чәчеп бетергәннәр иде. Гомуми җирләрне бүлеп караганда: 1700 гектарда – бөртекле культуралар, 410 гектар җирдә – шикәр чөгендере, 600 гектарда – соя (кытай борчагы), 400 гектардан артык кукуруз, 50 шәр гектарда майлы торма (масленичная редька), горчица һәм башка культуралар утыртканнар.

– Ә майлы торма белән нишлисез? – дидем «Яңа юл» бүлекчәсенең баш хисапчысы Вероника Журавлевага.

Фото: Александр Ефремов

– Табигый ашлама урынына кулланабыз. Узган ел беренче тапкыр утыртып карадык. Ошаттык. Майлы торма туфракны файдалы элементлар белән баета. Бу культура үскән җиргә узган ел көзге бодай чәчтек. Быел ул кырлар гөрләп утыра.

– Алайса майлы торма ашламаны алыштыра ала? Натураль ризык кына ашый башласак, дим...

– Өлешчә алыштыра. Тик бу ашлама кертмәскә дигән сүз түгел. Кызганычка каршы, ашламасыз, агусыз булмый. Чүпкә, бөҗәкләргә каршы да агу сиптерергә кирәк.

«Яңа юл» бүлекчәсендә майның уникесенә бөртекле культураларны чәчеп бетергәннәр. Ә басуга 4 апрельдә чыккаННар. (Бу якларда яз иртәрәк килә).

– Тик басуда кара көзгә кадәр эш барачак, – диде Вероника Журавлева. – Азрак чөгендер, кукуруз чәчәсе калды, пар җирләрен сукалыйсы бар. Аннан чәчелгән культураларны эшкәртәсе була. Сезон вакытында механизаторларга ял юк.

– Ә болай ялсыз эшләгән өчен алар күпме хезмәт хакы ала?

– Эшләвенә карап. Ел әйләнәсенә бүлсәң, механизаторларның уртача хезмәт хакы 30–35 мең сум чыга. Мисал өчен. урып-җыю чорында йөз меңгә кадәр алалар. Тагын чәчү вакытында аерым кызыксындыру чаралары бар: әйтик, тракторчы нормадан артык эшләсә, бер кисәтү дә алмаса, хезмәт хакының сиксән процентын өстәп, премия итеп түлибез.

Кызыксындыру чарасы моның белән генә бетми икән – иң зур күрсәткечләргә ия булган өч механизаторга җиңел машина бирәләр.

ЮЛ – ЯШЬЛӘРГӘ!

Буа районында безне нәрсә гаҗәпләндерде, дөресрәге, сөендерде: механизаторларның күбесе утыз яшькәчә. «Авылда яшьләр калмый», – дип лаф органда, биредә, киресенчә, кырда өлкәннәр азрак икән. Районның баш агрономы **Раил Идрисовның** бу уңайдан үз фикере бар:

– Югары белем алгач та, Буага – дәү әти, дәү әни янына кайттым. Әти-әниләр Казанда калды. Авылда чиста һавада яшәү үзе ни тора! Минем кебек уйлаучылар шактый, киләчәктә авылга яшьләр кайтыр, дип уйлыйм.

Баш агроном белән Буа җирләре турында сөйләштек.

– Безнең якта туфрак начар түгел, кара, уңдырышлы, – диде ул.

Уңдырышлы булса да, ашламасыз гына бүген бер культураны да үстермиләр. Сәбәбе – шунсыз зур уңыш үсми.

– Ашлама керткәнче, башта туфрак анализы ясыйбыз, – диде Раил Идрисов. – Туфракка нәрсә җитмәгәнен өйрәнәбез. Узган ел бу урында нинди культура үскән, анысына да игътибар итәбез. Ашламадан кала, туфракка тагын известь, туендыргычлар да кирәк. Кыскасы, фәлән тонна ашлама керттек, быел уңыш була, дип уйлау дөрес түгел.

Яшь механизаторлар дигән идем бит. (Һәрхәлдә, безнең күзгә урта, өлкән яшьтәгеләр чалынмады). Шундыйларның берсе – **Константин Захаров.**

Ул әтисе белән эшли. Көндезге сменада – берсе, төнгедә – икенчесе.

– Мин өченче ел эшлим, – диде Константин. – Армиядән кайткач, анда-монда сугылып йөрдем. Һөнәрем буенча эретеп-ябыштыручы мин. Тракторны өч ел элек өр-яңа килеш әтием Николайга бирделәр. Кайвакыт аңа ярдәмгә килә идем. Аннан соң үзем дә «Авангард» ҖЧҖнең «Яңа юл» бүлекчәсенә урнаштым.

– Яңа трактор кызыктырдымы? – дигән булам.

– Анысы да бардыр, заманча техника бик уңайлы бит. Тик төп сәбәп – хезмәт хакы начар түгел, айга 30–35 мең сум тирәсе чыга. Көнен көнгә аванс, зарплата алабыз. Тормыш иткәндә иң мөһиме шул бит – кредит, коммуналь хезмәтләр өчен түлисе бар.

– Бер сменага күпме җир эшкәртеп була? – дим.

– Һава торышы әйбәт булса, бер сменага 15–20 гектар җир сөрелә. Мисал өчен, апрель аенда әти белән икебезгә 1 мең гектар җир сөрдек.

Константин өйләнгән, гаиләсе белән Буада яши. Көн саен ун чакрым ара килеп йөрүне бер дә авырсынмый.

– Ун минутлык юл, – диде ул. – Казанда эшләүчеләр сәгать буе эшкә бара әле…

Икенче яшь механизатор **Рәдис Төхвәтулловка** – 24 яшь. Өйләнгән, баласы бар. Әлеге оешмада 2016 елдан бирле эшли икән. Аны «универсал» диделәр. Сезонга карап, теләсә кайсы техникага утыра.

– Тумышым белән Чүпрәле районыннан мин, – диде Рәдис. – Буа аграр колледжын тәмамладым. Кулга диплом алгач, Буа шәһәрендә яшәргә калдым. «Яңа юл»га эшкә кердем. Башка бер җиргә дә эш эзләп бармадым. Тракторда эшлисем килде. Хәзерге тракторларны йөртү үзе бер рәхәт бит.

Без Буага барган көнне җир юешрәк иде – кичтән яңгыр яуды. Шуның өчен чит ил техникасының кайберләре кырга чыкмаган. Рәдис безгә кечкенә генә экскурсия ясап чыкты.

– Менә бу мин яраткан трактор – «Джон Дир». – Германиядән кайтартылган ул. Үзе җирне эшкәртә дә, чәчә дә. Орлыкны да пистолет кебек җиргә «атып» кына бара. Моңа тракторчыдан кала бер кеше дә кирәк түгел, барысын да үзе эшли. Чәчүлекнең күпмегә җитәсен дә күрсәтә. Утырып барырга да бик җайлы. Бердәнбер кимчелеге – юештә эшли алмый, чөнки ул зур, аңа никадәр агрегатны тартып барырга кирәк.

Бу трактор чынлап та гаҗәп. Чагыштырыр өчен бер сан: безнең техника белән бер тәүлеккә 40 гектар җир чәчеп булса, «Джон Дир» йөзне чәчә. Гадәттә, мондый заманча техникаларга яшьләр утыра икән. Кирәк очракта Казанга барып семинарларда укып та кайталар.

SP275
№ ЦБ 0009472

КАМА ТАМАГЫ

Буа районыннан соң Кама Тамагына юнәлдек. Әлеге районнарны сайлавыбыз юкка түгел: беренчесе уңыш җыю буенча алдынгылардан санала. Ә Кама Тамагы, киресенчә, бу исемлектә артта бара. Сәбәп нәрсәдә соң? Бу сорауга **Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы Наил Вазыйхов** җавап бирде:

– Кама Тамагы районы чын авыл хуҗалыгы районы гына түгел. Монысы, беренчедән. Бездә, башка төбәкләр белән чагыштырганда, туфракның уңдырышлылыгы да түбән. Гел вак ташлардан торган басулар да бар. Таулар, үзәнлекләр турында әйткән дә юк. Андый җирләрдән ничек югары уңыш аласың? Ләкин бу эшләмәскә кирәк дигән сүз түгел. Район сәясәтенең бер тармагы, һичшиксез, – авыл хуҗалыгы. Моңа иген үстерү, мөгезле эре терлек үрчетү дә керә.

Наил Вазыйхов район башлыгы булып бер елдан артык кына эшли. Шул вакыт эчендә авыл хуҗалыгы проблемаларын ныклап өйрәнгән. Һәм хәлне уңай якка үзгәртүнең берничә юнәлешен күрә икән.

– Моңа кадәр районда мең дүрт йөз гектар җир эшкәртелмәгән. Эш менә нәрсәдә: ул җирләр закон нигезендә торгиларда сатып алынган. Иң аянычы – алар чәчелми, тик ята. Сатып алучы аны милек итеп кенә алган, яки кайчан да булса яхшы бәягә сатып җибәрермен, дип уйлаган. Шул җирләрне быел тиешле структуралар белән карап, тикшереп йөрдек. Хуҗаларга болай ярамаганлыкны аңлаттык. (Закон нигезендә, чәчелмәсә дә, хуҗадан җирләрен тартып алып булмый. – Авт.). Фермерлар белән җир хуҗаларын очраштырып, килешү төзелде. Бу язда ул җирләр эшкәртелә башлады. Дөрес, мең дүрт йөз гектар җирнең барысына да иген утыртып булмый. Мисал өчен, аның 500 гектары элеккеге алмагач бакчалары. Тик агачлар, куаклар картайгач, алар ташландык хәлгә килгән. Анда хәзер каен, нарат кебек агачлар да үсеп утыра. Аларны төпләп атып, чәчүлек җирләре ясау өчен күпмедер күләмдә акча кирәк. Миңа калса, ул иске алмагачлыкны авыл хуҗалыгы җирләре исемлегеннән төшереп, урман хуҗалыгы фонды җирләренә кертергә мөмкин. Бу мәсьәләне хәл итеп бетерәсе бар.

Район башлыгының тагын бер идеясе – зур кооператив төзү.

– Кеше үз мөлкәтенең хуҗасы икәнен аңлагач кына күңелен биреп эшли башлый, – дип дәвам итте Наил Вазыйхов. – Эре агрохолдинглар башта зур тизлек белән күтәрелеп китәләр, аннан соң тиз арада аларда эш сүлпәнләнә, сүнә. Чөнки эш башлаганда зур акчалар, яхшы техника була, аннан алар юкка чыга. Зур холдинг бөлгенлеккә төшсә, аны районның күпчелек халкы сизә, ә кечкенә



бер кооператив ябылса да, ул гомуми массада сизелми.

Яңа башлык дәүләт ярдәме белән дә районның авыл хуҗалыгы тармагын күтәрергә уйлый. Журналыбызның алдагы санында «Агростартап» программасы турында язган идек. Шушы программа буенча районның 8 кешесе грант алган.

– Бүген дәүләт авыл кешесенә эш башлар өчен күп мөмкинлекләр бирә, – ди Наил Вазыйхов. – Ә шуны аңлап, үз эшләрен башлаучылар сирәк. Кайчак кулларыннан тотып йөртәбез. Әйе, мин аңлыйм, авыл кешесе җирдә эшләргә өйрәнгән. Кәгазь тотып йөгерү аның өчен ят. Тик грант алуның уңай якларын аңлаткач, башкалардан күреп тә, халыкның фикере үзгәрә. Фермер булырга теләүчеләр, иң беренче чиратта, җир юклык белән очраша. Үз исеменә рәсмиләштермәгән җир турында сүз бара. Һәм бу гаҗәп тә түгел, гомер буе комбайнда эшләгән механизатор кайчан җир рәсмиләштерсен? Ул аңа кирәк тә булмаган. Ләкин тәҗрибә күрсәткәнчә, заманалар үзгәрә, үзеңә эшләргә мөмкинлек бар. Минемчә, моны кулдан ычкындырырга ярамый…

«ИКЕНЧЕ СМЕНАГА МЕХАНИЗАТОРЛАР ТАБЫП БУЛМЫЙ»

Кама Тамагы районының авыл хуҗалыгы бүлеге вәкилләре белән кырларны карарга чыктык. Күзгә бодайлар ямь-яшел булып тишелеп чыккан. Инде иртәрәк чәчкән арпа, бодай кебек культуралар да шытып, матур итеп баш калкыткан.

– Көзен чәчкән иген культуралары кышны әйбәт уздырды, – диде җирле җитәкчеләр.

Кырдагы техниканы күреп, гаҗәпләнеп куйдым: Буа районында гел яңа техника иде.

– Бездә дә заманча тракторлар бар, – диде «Кызыл Шәрык» ширкәтенә караган «Олы Кариле» ҖЧҖ бүлеге җитәкчесе **Вәкил Касыймов.** – Соңгы өч елда берничә яңа чит ил техникасы кайтты. Теләсәгез, алып барып күрсәтербез. Бүген кукуруз чәчәбез, анда чит ил техникасы кирәк түгел.

Кама Тамагы районы җирләре өч агрохолдинг кулында. Шуларның берсе «Кызыл Шәрык» ширкәте икән.

– Безнең карамакта алты мең гектарга якын җир бар, – диде Вәкил Касыймов. – Ике авыл җирлеге кырлары ул. Иген культуралары, рапс, көнбагыш чәчүне майның уникесенә тәмамладык. Малларга ашатыр өчен берьеллык үлән чәчәсе калды.

Буаның «Яңа юл» бүлекчәсендә механизаторларның уртача яше 30–35 дисәләр, биредә 50–55 яшь тирәсе икән. Басуда бары үзләренең авыл кешеләре генә эшли. Вәкил Касыймов үзе дә шушы җирлектә туып-үскән, гомер буе колхозда эшләгән.

– Эшче көчләргә кытлык бармы? – дим җирле җитәкчегә.

– Бар да, юк та. Икенче сменага механизаторлар табып булмый. Шуңа күрә бер смена итеп, көн яктысында эшлибез.

– Механизаторлар хезмәт хакы күпме ала?

– Уртача хезмәт хакы нинди техникада эшләвенә бәйле. Мисал өчен, МТЗ тракторында эшләүчеләр уртача – 25 мең сум, чит ил техникасын иярләгән ир-атлар 50–60 мең сумга кадәр ала.

Биредә көнбагыш күпләп утырталар. «Кызыл Шәрык»ның үзенең сыек май заводы бар, өлгергән көнбагышны шунда алып китәләр икән. Бер өлешен сатуга чыгарыр өчен дә әзерлиләр. Рапсны исә сату өчен үстерәләр.

– Рапс белән бал кортларына зыян китермисезме соң? – дим Вәкил Касыймовка.

– Юк. Мин үзем дә умартачы, ун оя кортым бар. Гербицидны кичке якта гына сиптерәбез, аның кортлар өчен куркыныч булмаган төрен алып кайтабыз. Вотсапта район умартачыларның төркеме бар. Гербицид сиптерер алдыннан шунда хәбәр язабыз. Умартачылар кортларын иртәнге якта ябып торырга мөмкиннар.

Кырда эшләүче механизаторлар белән дә аралашып алдык. Берсе дә зарланмый, көнне төнгә ялгап эшли. Бу алар өчен күнегелгән шөгыль. Шуңа да авыл җирендә яшәүче, эшләүче кешеләргә зур ихтирам белән карыйм. Җилме, яңгырмы, сырхаумы – алар хезмәттә.

…Элек чәчү, урып-җыю чорында авыл гөр килеп тора иде. Ир-атлар, үсмер балалар – барысы да бу эштә катнашты. Бүген хәл бүтән: чәчү бара икәнен белмисең дә. Моның төп сәбәбен заманча техникаларда дип күрдем. Кул хезмәте бик аз яки бөтенләй кирәкми хәзер. Әлбәттә, бу яхшы, уңайлы. Агу, тузан сулап йөргәнче, авыл кешесе бүтән эш белән мәшгуль. Әйе, авылларда тормыш җиңеләя. Болай булса, бәлки, чынлап та авыр физик эштән шәһәргә «качып» китүчеләр кире туган якларына кайтыр? Һәрхәлдә, мин шуңа ышанам, өметләнәм…

ЗУР ЕЛГА УТРАУЛАРЫНДА

Татарстанда «Идел киңлекләре» дәүләт табигать тыюлыгы булдырылды. Әлеге яңа статус аның структурасына кергән территорияләргә нәрсә бирә? Һәм безгә, кешеләргә, моннан нинди файда булачак? Шуңа төшенергә тырышыйк һәм бераз гына хыялланып алыйк.

Автор:
Катерина Котова

БЕЗ МОҢА ЛАЕК

«Идел һәм халык каршы!» төркеменең елга ермакларын күмүгә каршы чыгуына бәйле күп елларга сузылган бәхәсне хәтерлисезме? Бу тыюлыкның пәйда булуы әлеге вакыйга өчен хеппи энд түгел, бәлки күп өмет уята торган башлангычтыр, мөгаен. «Идел киңлекләре» заказнигының гомуми мәйданы 30 мең гектарга якын территорияне үз эченә ала. Аңа Югары Ослан, Яшел Үзән, Лаеш районнарында һәм Казанда – Яшел Үзән күпереннән алып Красновидово авылына кадәр булган җирләр керә.

Тыюлыкны төзүнең максаты актуаль һәм гаять киң колачлы – Идел акваториясе һәм аның утраулар системасының биологик төрлелеген, уникаль ландшафт комплексларын саклап калу, шулай ук кешенең аларга тискәре тәэсирен туктату. Бер «атуда» – дистәгә якын куянмы? Бик шәп булыр иде бу!

– «Идел киңлекләре» стихияле рәвештә түгел, бәлки территориядә уздырылган фәнни тикшеренүләр нигезендә булдырылды, әлеге эштә ТР Фәннәр академиясе, Казан федераль университеты, Идел-Чулман тыюлыгы белгечләре катнашты, – дип сөйли ТР Биоресурслар дәүләт комитетының биологик төрлелек бүлеге башлыгы **Роза Миңнегулова.** – Галимнәр бу урыннарда үсемлек һәм хайваннарның кайберләре инде бөтенләй юкка чыгып барган һәм Россиянең дә, Татарстан Республикасының да Кызыл китапларына кертелгән сирәк төрләрен очратып булуны дәлилләде. Алай гына да түгел, биредә сирәк очрый торган ландшафтлар да, Татарстан өчен уникаль туфраклар да бар. Болар барысы да территориянең аеруча әһәмиятле булуын күрсәтә. Әмма иң мөһиме шул: тыюлыкның пәйда булуы республикабызның җир өсте сулыкларын гына түгел, бәлки җир асты суларын да туендыручы төп су объекты – Иделне саклап калу мөмкинлеген бирәчәк. Бу киләчәктә экологик һәлакәттән саклаячак.

БӨТЕН УҢАЙЛЫКЛАРЫ БУЛГАН ТАБИГАТЬ

Эссе көндә биредә сәйран кылу – үзенә бер ләззәт. Бу ярда тәүлегенә берничә йөз кеше ял итә, диләр. Хәер, машинабызга урын тиз табылды. Күрсәткечләр куелган: уңга китсәң – ял базасына барып чыгасың, туры барсаң – туристлар сукмагына төшәсең, ә безгә исә – сулга! Кием алыштыру урыннары, ятаклар патшалыгы монда – кояш яктысында ялтырап яткан ком күзне камаштыра хәтта. Тизрәк йөгереп барасы да, балачактагы кебек чыр-чу килеп, чип-чиста суга чумасы! Диңгезме? Юк, аннан да яхшырак – Идел бу! Очсыз-кырыйсыз, бертөрле түгел – кызыклы, үзенә генә хас бормалары, утраулары, табигате-холкы белән. Бу җирләрдә арып-талганчы йөреп була. Кармак салып утырыр урыннары да байтак. Балык шәп каба – бирегә, Займищега, хәтта күрше республикалардан да балыкчылар тикмәгә генә агылмый бит инде...

Йә, ничек сезгә киләчәктән шундый сәлам? Безгә бу күренеш бик ошый. Һәм хәзер моңа рәхәтләнеп ышанып та була. Әмма Займищедагы мондый кызыну һәм балык тоту урыны кебек бәхеткә ирешү әле бик ерак шул. Бу җирлек тыюлык структурасына керә, һәм эшләнәсе эш бик күп. Иң әүвәл күмелә башлаган урыннарда нормаль гидрология режимын торгызу зарур.

– Биредә яшәүчеләр ермакларның бер өлешен көрәк белән чистарткан инде. Әмма киңрәк урыннарда махсус техника таләп ителә, – дип шәрехли вазгыятьне КФУ ның су экосистемаларын оптимальләштерү лабораториясе инженеры, тыюлык проектын эшләүчеләрнең берсе **Надежда Ассанова.** – Хәзер Займище системасында кеше эшчәнлегеннән шактый зур зыян күргән йомык күлләр бар. Кышын алар Идел белән элемтәсен югалта, кислород керми башлый, һәм язын, ташу киткәч, ярда үлгән балыклар өелеп кала. Бу ямьсез, йөрәкне өзгеч аяныч күренеш. Әгәр күлләрдән су кабат ага башласа, сай сулыклар да нормаль режимга кучәчәк.

Сүз уңаеннан, әлеге территориядә бәһасез ветландлар – Идел суын чистартуда

Фото: С.В.Бердник, ТР ФА Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты архивыннан

Фото: Д.В. Иванов, ТР ФА Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты архивыннан

гаять зур роль уйнаган су-сазлык җирләре җәелеп ята. Елга суы сай сулыкка килеп эләгә. Ветландта төп «халык» булган камыш һәм башка макрофит үсемлекләр, губка кебек, судан зарарлы матдәләрне суырып ала. Шунлыктан бу җәһәттән Займище җирләрен, Иделнең йөрәге булмаса да, бөере, дип әйтеп була. Һәм елга суының чисталыгы да, андагы балыкның күплеге дә шактый дәрәҗәдә бу «бөернең» никадәр сәламәт булуына бәйле.

Займище системасындагы бөтенләй юкка чыгу куркынычы янаган флора һәм фауна төрләре очраган кайбер территорияләргә туристлар тыкшынуы бер дә файдага булмаячак. Әмма шулай да әлеге җирләрнең зуррак өлешен рекреация максатларында файдалану планлаштырыла. Тик бу көтмәгәндә биредәге бакча хуҗаларында ризасызлык тудырган. Җирле халык утрауларда тәртипсезлек хөкем сөрә башлар, дип шикләнә. Хәер, моны җайлап була, дип саный ТР ФА Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты директорының фән буенча урынбасары, тыюлык проекты авторларының берсе **Дмитрий Иванов.**

– Татарстанда иҗтимагый пространстволар булдыру буенча зур тәҗрибә тупланган – һәр муниципаль районда ландшафт архитекторлары тәкъдим иткән концепцияне тикшерүдә халык катнаша һәм үз фикерен белдерә ала. Биредә дә шул юл белән барырга кирәк, дип уйлыйм. Әмма әлеге территориянең якындагы бистәләр халкы өчен генә түгел, әле тагын Казан һәм Яшел Үзән агломерацияләре өчен дә әһәмиятле булуын, һичшиксез, исәпкә алырга кирәк. Бары тик шул рәвешле генә территориядән файдалануның оптималь концепциясен эшләп була – ул табигатьне мөмкин кадәр саф килеш сакларга теләүчеләрне дә, Иделнең чиста суында коенырга һәм ярында кызынырга теләүчеләрне дә канәгатьләндерергә тиеш. Берничә елдан соң әлеге урыннар татарстанлыларның иң яраткан ял итү зоналарыннан берсенә әйләнер, дип уйлыйм.

Сүз уңаеннан, Займище системасы – тыюлык структурасындагы «ялкау» ял итүгә тәгаенләнгән бердәнбер район түгел. «Идел киңлекләрендә» мондый урыннар күп! Әйтик, мәсәлән, кайчандыр казанлыларның яраткан ял итү урыны булган Маркиз утравын кабат искә төшерер вакыт җитте. Урманнар, култыклар, ә иң мөһиме, комлыклар узган гасыр урталарына кадәр әле ял итүчеләрне үзенә гел ымсындырып торган. Маркизны хәтта «палаткалар шәһәрчеге» дип тә йөрткәннәр. Казаннан бирегә даими рейс йөргән. Дмитрий Иванов фикеренчә, аны торгызырга берни дә комачауламый. Алай гына да түгел, Маркиз елга буйлап озакка сузылган мавыктыргыч туристлык маршрутында бер тукталыш кына да булырга мөмкин...

АҺ, АК ТЕПЛОХОД!

Теплоходыбыз Казан портыннан кузгалып китә. Алда мавыктыргыч сәяхәт көтә. Без агым буйлап аска таба йөзәбез, Победилово, Зеленый Бор, Светлая Поляна янындагы утраучыкларны узып китәбез... Кемдер, элеккечә үк, акчарлакларны сыйлый, кемдер, йомшак юрганга төренеп, табигать күренешләре белән хозурланып бара, калганнар исә Идел һәм аның тирәнлекләрендәге кызыклы тормыш турында хикәятләр тыңлый. Безнең «экспедициянең» максаты – Зәңгәр култыкның сокландыргыч утраулары. Бу утрауларда комлыклар юк диярлек, ярлары текә, биек. Әмма биредә – үзенә бер төрле куаныч! Балык бик күп, гөмбәне исә чалгы белән чабарлык, дип сөйлиләр...

Әлеге сәяхәт тә – хыял, тик бу юлы Дмитрий Ивановныкы инде. Зәңгәр култык районындагы урманлы утрауларны күргән саен, ул: «Бу искиткеч табигать белән зур шәһәрләрдә яшәүчеләрне таныштырсаң, аларда да шундый соклану хисе тудыра алсаң иде», – дип уйлый.

– Шундый танып-белү сәйраннары – әлеге территорияне үстерү кысаларында мин тәкъдим иткән идеяләрдән берсе генә әле, – ди галим.

Онега күле буйлап экскурсиядән алган җете тәэсирләрен ул һаман да хәтерендә саклый – әлеге төбәк турында никадәр яңалык белән танышуын, ярда пешергән балык шулпасының искиткеч тәмен... Карелиядә мондый сәяхәтләр бик популяр, акваторияләргә бай Татарстанда исә хәзергә кадәр бер генә «табигый» елга маршруты да юк. Ә менә табигать кочагына ашкынган миллионлы шәһәр агломерациясе бар. Дмитрий Иванов фикеренчә, эш башлау өчен инициативалы кешеләр генә кирәк.

Мисалга, Татарстанда моңа охшаш башлангычлар бар инде. Мишә тамагында зур булмаган туристлык базалары төзелгән. Анда татарстанлылар гына түгел, күрше төбәкләрдән килгән кунаклар да, хәтта таләпчән мәскәүләр дә ял итә. Искиткеч табигать, мунча, балык тоту – җәйге бәхет өчен тагын ни кирәк соң?!

– Тыюлыкта шундый урыннар һәм маршрутлар күбрәк булса, моннан халык та, эшкуарлар да, дәүләт тә отар иде, – дип саный Дмитрий Иванов. – РФ Табигый байлыклар министрлыгы инде әллә ничә тапкыр: тыюлыкларга, заказникларга һәм милли паркларга экологик туристлык үтеп керергә тиеш, дип белдерде. АКШ тагы һәм Европа



илләрендәге кебек – анда әлеге юнәлеш актив үстерелә.

Тыюлык төзелү яр буе зонасы һәм утрау территорияләре өчен генә түгел, бөтен Идел акваториясе өчен файдалы булачак, дип фаразлана. Иделдә балыкның елдан-ел кими баруы сер түгел. Әлеге проблеманы хәл итү мөмкин. Файдалы казылмалар табуны киметү (эшчәнлеккә яңа лицензияләр бирелмәячәк) һәм елгага йогышсызландырылмаган юынтык сулар түгүне тыю суның сыйфатын яхшыртачак һәм балык үрчүне арттырачак. Балыкны күпләп тотуга квоталар хәзер фәнни мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнәчәк. Законсыз балык тотучыларны заказник хезмәткәрләре туктатачак. Ә мөнә һәвәскәр һәм спорт балыкчылыгы бирөдә хупланачак кына.

СУКМАКЛАР ЧУАЛГАН...

Бу урыннан үтеп чыгу кыен. Әмма юлсыз җирдән, эссе кояш астында без ахыргы максатыбызга якынлашабыз. Әлеге маршрутта катнашучы барыбыз да – яшьләр дә, инде шактый өлкәннәр дә – ару-талу, курку белмәс тикшеренүчеләр дип хис итәбез үзебезне. Бары тик... сирена үкерүе генә туктата ала! Хәвефләнеп, озатып йөрүчегә текәләбез, ул исә безгә тыныч кына торырга ишарәли. Кара башлы шаркылдык шулай кычкыра икән. Кызыл китапка кертелгән әлеге кош бу утрауларда сирәк очрый. Аны сыңар күз белән генә булса да күреп калу – зур уңыш, һәм бу – безнең сәяхәтебезнең беренче генә ачышы түгел...

Фәнни танып белү маршрутлары системасын булдыру – «Идел киңлекләре» рекреацияләрен үзләштерү өчен тагын бер идея. Күпләп ял итү зоналарыннан гына түгел, махсус кайгыртуга мохтаҗ, сирәк очрый торган төрләр яшәгән чытырманнар аша да сукмак салырга була бит. Аларда тикшеренү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Кем белә, бәлки, урман киек-җанварлары табигатькә әллә ни исе китмәгәннәрдә дә мәхәббәт уята алыр?

Экологик сукмакларны тыюлыкның барлык юнәлешләрендә диярлек – Яшел Үзәннән алып Тетеево авылына кадәр –салып була. Кычкыручан зур бөркет, бөркет-аккойрык, кече күлбуга, саз ябалагы һәм ысылдавык аккош, шулай ук кондыз, су күсесе, куян, америка чәшкесе, урман сусары, төлке, кыр кәҗәсе, пошн – бу җирләрне өйрәнгәндә танышырга мөмкин булган бай хайваннар дөньясының әле бик аз өлеше генә. Тәҗрибәле экскурсия үткәрүчеләр бу эштә ярдәм итә ала.

Проект авторлары, экологик маршрутлар һәм тотрыклы туристлык юнәлешләрен булдыру хәтта акваториянең экологик халәтен яхшыртачак, дип өметләнә. Чөнки тәртипсез ял итүчеләр урынына тыюлыкта яхшы оештырылган турист төркемнәре йөриячәк. Гомумән, бу урыннар Татарстанда туристлык үсешенең яңа үзәкләренә әйләнергә сәләтле. Аларны инде Казан, Зөя утрау-шәһәре, Болгар кебек мәдәният үзәкләрен хозур кылу белән бәйле мәгълүм маршрутларга кертеп булыр иде. Бу республикабызга туристлар агылуын арттырып кына калмыйча, сәяхәтчеләрнең аның территориясендә булу вакытын озайту мөмкинлеген дә бирәчәк.

Әлеге эшчәнлеккә нәрсә комачаулыймы? Туристлык инфраструктурасының юклыгы һәм транспорт белән тәэмин ителеш проблемалары. Мисал өчен, бүген «Идел киңлекләре» утрауларына транспорт йөрми. Идел турында хыялларыбыз чынга ашсын өчен, зур эш башкару зарур. Һәм анда иң мөһиме – кешенекен генә түгел, бәлки табигать мәнфәгатьләрен дә кайгырту. Т

Фото: И.И. Җиһаншин, ТР ФА Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары институты архивыннан

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Фәйзи Йосыпов турында **НӘРСӘЛӘР** беләбез

1812 елгы сугышта татарлар **НИЧЕК** катнашкан

Бөек Җиңүне **КЕМНӘР** якынайткан

ТАТАР СҮЗ СӘНГАТЕНЕҢ ГЕНЕРАЛЫ

Автор:
Мөршидә Кыямова

Сүз – адәм баласының рухи байлыгы. Сөйләмең никадәр дөрес, матур һәм итагатьле булса, башкалар арасында хөрмәтең дә шулкадәр арта гына бара. Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел, дигән борынгылар да. Әлбәттә, сүз үзенә карата сакчыл мөнәсәбәт тә таләп итә. Быел республика җәмәгатьчелеге легендар нәфис сүз остасы, беренче татар конферансьесы Фәйзи Йосыповның 110 еллыгын билгеләп уза.

Сүз кодрәте аша халкыбызга милли әдәбиятны җиткерүдә гомере буе хезмәт куйган Фәйзи Йосыповның куәтле тавышы бүген дә олы буын күңелендә саклана.

Фәйзи Йосыпов җитәкчелегендәге артистлар бригадасы гастрольләрдә. Сталинабад (хәзер – Дүшәнбе, Таҗикстан) шәһәре, 1957 ел.

«МАТУР СӨЙЛӘҮЧЕ МАЛАЙ»

Фәйзи Йосыповның сәхнәдә чыгыш ясаган вакытларын күрмәсәм дә, университетны тәмамлап, «Казан» радиосында эшли башлагач, аның белән очрашып, тапшыру эшләгән идек. 90 яше якынлашканда да Фәйзи ага Бауман урамындагы «Чәй йорты»на төшке ашка йөри иде. Аны таныйлар, ул урам тутырып йөри, танышлары белән татарча сөйләшеп бара. Берочтан хәтер сандыгында сакланып калган хатирәләре белән уртаклаша.

Авылда яшәгәндә үк, Яуширмәнең җор телле Катәй бабай дигән кешесе аңа Тукай шигырьләре басылган китап бүләк иткән була. Һәфтиякне шартлатып укыган бала бу китапка бик нык куана. Андагы шигырьләрне күңеленә сеңдереп, авылдашлары арасында яттан сөйләп йөри башлый. «Матур сөйләүче малай» исеме тагалар аңа.

> *«Чистай районының бөтен дөньяга танылган Яуширмә авылында тугәнмын. Гаиләдә 12 баланың унбере малай, бер кыз тәгәрәп үстек. Ачлык елларында әти-әниебез дөнья куйды. Балаларның кайберләрен Уралда яшәүче олы абыебыз Гали сыендырды. Кайберәүләребезне Гаяз Исхакыйның энесе Хәсән Исхаков үзләренә алып кайтты. Ә аннары кеше булсын, укысын, дөньяга чыксын, дип Казандагы үксезләр йортына урнаштырды...», – дип яза Фәйзи Йосыпов бала чагы турында.*

Казанда урта мәктәпне тәмамлагач, педагогия техникумына укырга керә һәм Г.Камал театры актеры Касыйм Шамил җитәкчелегендә оештырылган балалар театрына йөри башлый. «Касыйм абыйга рәхмәт, ул мине артист ясады», – дигән иде Фәйзи абый үзе дә.

Балалар театры оештырган әдәби кичәләрнең берсендә Фәйзи Һади Такташның «Нәни разбойник» шигырен укый. Автор үзе дә кичәдә катнашканга күрәме инде, егет дулкынлана, әмма сынатмый. Малайны Һади Такташ үзе дә мактый, җылы теләкләрен җиткерә. Галиәсгар Камал исә: «Тавышың көр чыга, чәчең дә бөдрә, сиңа артист булырга кирәк!» – дип, Фәйзине үсендереп җибәрә.

«Педагогия техникумында бер ел укыгач, театр техникумына күчкәндә имтихан тапшырасы бар иде. Миңа буең бәләкәй, дип бәйләнделәр. Кабул итү комиссиясендә Кәрим Тинчурин үзе утыра иде, мине урындыкка бастырып, сәләтемне күрсәтергә кушты. «Айть (сөйлә – М.К), малай!» – диделәр. Менә шуннан бирле, «айтәм» инде, тиздән туксанга җитәм, әле һаман шигырь сөйләүдән туктаган юк», – дип шаярта иде.

Фәйзи Йосыпов театр техникумының икенче курсында укыганда цирк артисты булып та эшләп ала. Бу юнәлешкә язучы Шәриф Камал фатиха бирә. Казан циркында 1927–1929 нчы елларда СССРның халык артисты Михаил Румянцев «Карандаш» образында чыгыш ясый. Менә шул легендар артист белән татар егетләре – Фәйзи – Кодрәбаш, Морзи – Каракаш та халык күңелен күтәрүдә хезмәт куя. Бу ике егетне «Фәйзи-Морзи дуэты» дип тә атыйлар.

1930 елда егет Казан театр техникумының режиссерлык, актерлык бүлеген тәмамлый. Фәйзи Йосыпов Кәрим Тинчурин, Нәкый Исәнбәт, Кәшифә Тумашева, Гомәр Дәвишев кебек татар сәнгатенең күренекле вәкилләреннән белем ала. Техникумнан соң ул күпмедер вакыт театрда эшли. Аннан Кызыл Армия сафларына алына. Хезмәт иткән вакытта да, сәхнәдән аерылмый, үзешчән сәнгатькә җитәкчелек итә, чыгышлар ясый.

Беренче укчы татар полкында хәрби хезмәтен тутырып кайткач, ике ел Мәскәү эстрадасында эшли. Анда ул рус эстрадасы осталары Смирнов-Сокольский, Илья Набатов, Аркадий Райкин, Ирма Яунзем иҗатлары белән якыннан таныша, күренекле сүз остасы Владимир Яхонтов чыгышларын тыңлый. Мәскәү эстрадасында талантлы җырчылар Наилә Рәхмәтуллина һәм Асия Измайлова белән бергә иҗат итә. Аңа Фәйзулла Туишев белән гастрольләрдә булырга, беренче профессиональ җырчыларыбыз Фәттах Латыйпов концертларында катнашырга туры килә. Фәйзи ага атаклы татар җырчылары Ситдыйк Айдаров, Галия Кайбицкая, Гөлсем Сөләйманова, Сара Садыйкова концертларында алып баручы була.

1937 елда Татар дәүләт филармониясе оештырылгач, Фәйзи Йосыпов шушы коллективның артистына әйләнә. Аның гастрольләргә бай иҗади эшчәнлеге биредә башлана. Республика сәхнәләрендә танылган сәнгать осталары катнашында концертлар алып бара, профессиональ яктан да, репертуар туплау өлкәсендә дә иҗади тәҗрибә туплый. Татар әдәбияты әсәрләреннән тыш, Фәйзи Йосыпов репертуарында Владимир Маяковский, Александр Твардовский әсәрләре дә урын ала.

БЕЛЕШМӘ:
Фәйзи (Фәйзрахман) Йосыпов Чистай районының Яуширмә авылында 1910 елның 24 декабрендә күп балалы гаиләдә туа. Әтисе Сәяр, әнисе Нурҗамал исемле. Унбер яшендә ятим калгач, ул Казан балалар йортында тәрбияләнә. Казан театр техникумында укый. 1930 елда Татар дәүләт академия театрында эшли башлый. Армиядә хезмәт итә, аннан соң ике ел дәвамында Мәскәү эстрадасында эшли. 1937 елдан Казанда Татар дәүләт филармониясе оештырылгач, шунда эшкә урнаша. 1939 елда Мәскәүдә эстрада артистларының I Бөтенсоюз конкурсында дипломант исеме яулый. Бөек Ватан сугышы башлангач, фронтка китә. 4 ел сугышта катнашканнан соң, кабат татар сәхнәсендәге хезмәтен дәвам итә. 1957 елда аңа «ТАССРның атказанган артисты» исемен бирелә.
2001 елда 91 яшендә бакыйлыкка күчә.

Фотолар Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе музееннан алынды

ХАЛЫК МӘХӘББӘТЕ

1941 елда Бөек Ватан сугышына китә. Ленинград фронтына эләгә. Туплар атудан тынып торган арада фронттагы солдатлар каршында чыгышлар ясый.

Фронттан кайткач, артист тагын авылдан авылга, шәһәрдән шәһәргә йөреп, концертлар куя. Ягымлы, көчле тавышка, тапкыр сүзгә, тамашачы белән аралашу, импровизация осталыгына ия булып, нәфис сүзнең тәмен белеп, сүз сәнгатен тамашачы күңеленә ирештереп, халык мәхәббәтен яулый.

«Шигырьме ул, прозамы, куплет яисә такмакмы, хәтта буффонада һәм клоунада әсәреме, әгәр алар кешене ышандырырлык итеп башкарылса, эстрада өчен берсе дә хилаф эш түгел. Бары тик чынбарлыктан читкә китмәсеннәр дә, якты киләчәгебезгә хезмәт итсеннәр. Шул чагында эстрада жанрының бу төре әйбәт, тегесе начар дип әйтергә урын калмый». (Фәйзи Йосыпов сөйләгәннәрдән)

Чордашлары Фәйзи Йосыповны киң эрудицияле шәхес буларак еш искә ала: «Сөйләшеп туймаслык гаҗәеп бер кеше иде. Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә озак еллар эшләү дәверендә ул Россияне аркылыга-буйга йөреп чыкты. Репертуары гаять бай, аның башкаруында Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким, Әнгам Атнабаев, Салих Баттал әсәрләре тамашачы күңелендә аеруча дулкынлану хисләре тудыра. Гомеренең азагына кадәр җор телле, шаян холыклы сәхнә генералы булып кала бирде» – дип яза үз истәлекләрендә Татарстан һәм Россиянең халык артисты Айрат Арсланов.

Фәйзи Йосыпов татарның бик күп данлыклы кешеләрен күреп, алар белән аралашкан. Бу җәһәттән ул, шагыйрь әйтмешли, илче дә. Аларның һәркайсы турында хатирәләрен яңарта. «Авылда Хәсән абыйда укыганда, Гаяз Исхакый авылга кайткан иде. «И, канәтләр», – дип, без ярлы крестьян балаларына революция турында сөйләде кебек. Сүзләре хәтердә калмаган. Ә менә сары мыегы истә... Муса (Муса Җәлил. – Ред.) мине кызлар белән танышырга өйрәтте. Кызлар янына беренче мәртәбә ул алып барды. Бик үткен, зыялы кеше иде, шигырьләрен сәхнәдән күп укыдым».

Иҗат бәхете ялкынлы булса да, шәхси тормышында аны фаҗигале язмыш озата бара, ләкин ул беркайчан да уфтанмый шикелле. «Гаилә тормышым бик катлаулы булды минем. Өч тапкыр өйләндем, өч хатыным да үлде. Дүртенче тапкыр өйләндермәкчеләр иде, Айрат Арслан каршы чыккан. Ике улым бар иде. Берсе вафат инде. Менә шуның улы белән яшәп яткан көнем. Ике бүлмәле фатирда бишәү яшибез. Сугышта катнашып, ут эчендә йөргән кеше мин. Пенсияне әйбәт алам, Аллага шөкер!»

Безнең халыкта җор телле, чичән кешеләр элек-электән булган. Алар бәйрәмнәрдә, Сабан туйларында чыгыш ясаган. Андый кешеләрне туйларда «мәҗлес күтәрүче, табын атасы» итеп билгеләгәннәр.

Профессиональ эстрадага килсәк, беренче татар актеры Ильяс Кудашев-Ашказарскийның төрле концертларда нәфис сүз сөйләгәне мәгълүм. Шәрык клубында Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев үзләренең шигырьләрен укыган. Күренекле трагик актер Мохтар Мутинның да русча һәм татарча декламация сөйләгәне билгеле. Һади Такташ, Гадел Кутуй да үз шигырьләрен сәнгатьле итеп укучы трибун шагыйрьләр булган. Ә инде профессиональ рәвештә нәфис сүз белән шөгыльләнүчеләрдән язмабыз герое Фәйзи Йосыпов, Әзәл Яһүдиннарның иҗат лабораториясе җентекләп өйрәнүгә лаек. Һәрбер сүзгә җанлы сулыш өреп, һәрбер сүзнең тәмен тоеп, тамашачы күңеленә җиткерә алган, сүз сәнгатенә чын мәгънәсендә табынган осталар буыны бит алар! Әле үзләреннән соң лаеклы алмаш тәрбияләгән чын остазлар да. Айрат Арсланов, Рәшит Сабиров – Фәйзи Йосыповның сәхнәдәшләре һәм шәкертләре...

«Битемдә никадәр җыерчык бар, гомеремдә шулкадәр концерт бирдем, 1000 гә кадәр санадым, аннан арыдым. 75 ел гомерем сәхнәдә кеше көлдереп үтте, әмма үземнең кеше көлкесенә калганым булмады. Көлә белгән кеше генә ошый иде, алай гына да түгел, кайчакта ул «образ»га кереп китеп, безгә, хәрбиләргә, боерыклар да биргәли иде, ә без бик «тырышып» аларны үти идек.

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ...

Рамил Курамшин, Татарстанның халык артисты, баянчы:

– Филармониядә эшли башлаган елны ук миңа Фәйзи абый белән бергә гастрольгә чыгарга туры килде. Шундый мәшһүр артистның беренче булып мине сәхнәгә алып чыгуын һәрвакыт горурланып искә алам. 1970 ел азагында 60 яшен тутырган Фәйзи абый лаеклы ялга чыкты, ләкин шуннан соң да әле ул байтак еллар дәвамында сәхнәдән китмәде, аны гел концертларга, гастрольләргә чакыралар иде. Ул үзенең бай тормыш һәм сәхнә тәҗрибәсен, иренмичә, яшь буын артистларга тапшырырга тырышты. Сәхнәгә алып чыгу дигәннән, тагын шуны әйтәсе килә: концертны алып баручы буларак, Фәйзи абыйның артистларны сәхнәгә чакыруы үзе бер сәнгать иде. Аның илһамлы вә дәртле сүзләре сиңа шундый көч һәм ышаныч бирә ки, үзең дә сизмәстән, сәхнәгә күктән иңгән фәрештә кебек килеп чыгасың. Фәйзи абый белән гастрольгә барсаң, моңсулану, кәефсезлек турында онытып! Ул гастрольдә инде Фәйзи абый «атмосферасы» хакимлек итә: мәзәк сөйләү, дисеңме, юк кына нәрсәдән дә көлке табып шаярумы, артистлар арасында булган төрле хәлләрне искә төшерүме... Без, филармония музыкантлары, Фәйзи абыйны, үз итеп, «генерал» дип йөртә идек. Дүрт ел буена фронтта булган карт солдатка бу кушамат, әлбәттә, ошый иде, алай гына да түгел, кайчакта ул «образ»га кереп китеп, безгә, хәрбиләргә, боерыклар да биргәли иде, ә без бик «тырышып» аларны үти идек.

1975 елның декабрь аенда Үзбәкстанда гастрольдә йөрибез. Бер район үзәгендә клубка килеп төшкән идек, ул бөтенләй ягылмаган, салкын икән. Нишләргә? Шунда Фәйзи абый: «Егетләр, бу салкында концерт куя алмыйбыз, дип борылып китсәк тә, безгә берни әйтә алмыйлар, әлбәттә. Ләкин ике-өч елга бер мәртәбә генә татар концертын карарга мөмкинлеге булган милләттәшләребезне шул бәхеттән мәхрүм итү гөнаһ булыр бит. Авыр булса да, тырышыйк инде. Ходай каршында савабы булыр», – дигәч, без аксакалыбыз сүзләре белән ризалаштык. Тамашачы безгә салкын клубны җылытырлык итеп көчле алкышлар

озак яши, озак яшәүнең тагын бер сере – кешеләрне ярата белүдә. Аннары алар үзеңне дә синнән артыграк итеп яраталар. Тирә-юньдәгеләр белән һәрвакыт дус яши белергә кирәк. Бер-береңбелән аралашып, хәл-әхвәл белешеп яшәргә, кеше елаган вакытта кушылып еларга, җырлаганда җырларга кирәк. Яшьләргә яшьнәп яшәргә! Бернәрсәгә дә бирешмәскә, кайгыларга, авырлыкларга баш имәскә. Яшьлек бер генә килә, ике килми», – дия иде дип, искә алалар аны якташлары.

Фәйзи Йосыпов, сәхнәдә армый-талмый 75 ел буе хезмәт итеп, ана телебез, матур әдәбиятыбыз сагында көч куя. Яуширмә авылында һәвәскәр артистлыктан башланган сәхнә юлы халкыбыз йөрәгендә лаеклы урынын алды һәм, чыннан да, татарча сәнгатьле сөйләмнең генералы итеп танытты!

Филармония артистлары: К. Габидуллин, Әлфия Авзалова, Фәйзи Йосыпов.

МӘЗӘКЧЕ ТУРЫНДА

МӘЗӘКЛӘР... «КҮР ӘЛЕ СИН, Ә?»

Танылган җырчы Габдулла Рәхимкулов йоклаганда бик нык гырлый иде, диләр. Аның бу гадәтеннән тәмам туеп беткән Фәйзи Йосыпов гастроль вакытында моның белән бергә фатир төшмәскә тырыша. Бервакыт поездда: «Берәр кич булса да тынычлап йокламын», – дип, икенче вагонга кереп урнаша. Яшь артистлар Фәйзи аганы кызык итәләр: тавыш операторын күндереп, Габдулла Рәхимкуловның гырлау тавышын магнитофонга яздырып алалар да Фәйзи аганың күрше купесыннан язманы «яңгыраталар». Үзегенә үткән гырлауны ишетеп уянган конферансье узалдына болай дип куя:

– Кирәк бит, ә? Бу Апушның гырлавы күрше вагоннан да ишетелә икән...

ФӘЙЗИ БАБАЙ ТЕАТРЫ

Элегрәк гастрольләр өчәр айга сузыла торган була. Артистлар бер-берсеннән ялыгып, алҗып бетә, гаиләсен сагына. Татарның беренче нәфис сүз остасы Фәйзи Йосыпов озын-озак сәфәрләрне «җанландырыр» өченме, кызык ясапмы, бригададагы артистлар арасына үзе үк «чөй кагып», аларны әрләштереп йөри икән. Эш болай була. Район үзәкләренең берсендә ул кунакханәдә Сара Садыйкова янына килә дә куе, матур тавышы белән:

– Саруш, синең турыда Зифа нәрсә ди бит әле... Сара хәзер күлмәкне элеккегечә матур язмый инде, кайнарлыгы суынды, бетте, ди. Шулай дип тора, малай!

Сара ханым, табигый ки, ачуланып, борчылып кала. Фәйзи ага исә, бүлмәсенә барып, Зифа Басыйрованы эзләп таба:

– Карале, Зифакаем! Сара нәрсә ди бит әле... Бу Зифа көйләремне бозып җырлый. Әй, җырчы түгел инде, ди. Менә!

Кайнар темпераментлы Зифа ханымның да бу сүзләрдән саруы кайный башлый. Ике хатын бер-берсен табып әрләшә кала, Фәйзи ага кармакларын ала да, мыек астыннан гына елмаеп, су буена балыкка китеп бара. Ул әйләнеп кайтканчы, зыялы ике ханым әйтәсен әйтеп, эшнең хикмәтенә төшенеп, аңлашып, инде суынып, дуслашып та өлгерәләр һәм «болгатучы»ны көтәләр. Ишектән күренүгә үк, Фәйзинең өстенә ябырылалар. Фәйзи бабаң да эшнең шулайрак бетәсен чамалаган күрәсең, йөрәген тотып идәнгә утыра. «Уф, әллә нәрсә булды, күз алларым караңгыланды, үләм ахры!» – дия-дия, валидол төймәсен кулында әвәли дә тегеләр күрмәгәндә генә колак яныннан артка чөеп җибәрә. Янәсе, авызына капты! Ханымнар тынычланырга мәҗбүр була. Фәйзи ага исә судан коры чыга. Башка чакта андый хәл булса, артистлар башта: «Фәйзи сөйләдеме моны?» – дип сорый торган булып китәләр.

«ИЛҺАМ ШАКИРОВ КУШТЫ»

1996 елның февраль аенда Түбән Кама шәһәренең мәдәният сараенда Казан артистларының «Йолдызлар сәламе» дип аталган зур концерты бара. Сәхнә ветераны, нәфис сүз остасы Фәйзи Йосыпов беренче бүлектә аракы эчүгә каршы язылган бер шигырь сөйли. Программа буенча икенче бүлектә дә аның чыгышы була. Инде 86нчы яше белән барган аксакалның хәтере сыната – ул алдагы шигырен тагын бер кат сөйләргә тотына. Тамашачы аптырый, пышылдаша, көлә башлый. Фәйзи ага эшнең нидә икәнлеген сизә, әмма берни булмагандай, әсәрне ахырына кадәр сөйләп чыга да:

– Җәмәгать, сәхнә артында Илһам Шакиров миңа: «Фәйзи абый, халык бит хәзер бик каты эчә, син бу шигырьне тагын бер кабатлап сөйлә, аз гына булса да файдасы тияр, бәлки!» – дип, мине тагын сөйләргә күндерде, – дип шома гына үзенең ялгышын төзәтә.

Бу тапкырлыгына сокланып, тамашачы Фәйзи аганы кайнар алкышларга күмә.

бүләк итте һәм, мең рәхмәт әйтеп, озатып калды.

Рәшит Сабиров, Татарстанның халык артисты, нәфис сүз остасы:

– Фәйзи Йосыпов – телебезне саклауда үзеннән биниһая өлеш керткән шәхес. Аны бүген дә өлкән буын тамашачылар сагынып, яратып искә ала. Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Габдулла Рәхимкулов концертларын алып барганда сөйләгән шигырьләре, юмористик хикәяләре бүген дә колакта чыңлап тора. Аның тавышы да көчле, дәртле иде. Йоклаган күңелләрне уятып җибәрә иде. Казандагы Бауман урамының бер башында Фәйзи агай кем беләндер сөйләшсә, урамның икенче башында да ишетелеп тора торган иде. Ул сәхнәдә дә, урамда да, кешеләргә татар теленең матурлыгын, затлылыгын зур горурлык белән пропагандалады.

Фәйзи Йосыпов кеше буларак та татарның затлы, чын аксакалы булды. Ул сәхнәгә нәфис сүз өлкәсендә иҗат итәргә килгән яшь артистлар белән үзенең озак еллар туплаган тәҗрибәсен бик теләп уртаклаша иде. Шәхсән үзем дә аңа бик рәхмәтле. Минем күңелемдә иң матур хисләр генә калдырган олы шәхес ул. Аны сәнгатебезнең барлык артистлары да яраттылар, бүген дә сагынып искә алалар, «безнең Фәйзи», диләр.

Ләлә Зарипова, Чистай районының Яуширмә авылы китапханәчесе:

– Фәйзи Йосыповлар гаиләсе, Гаяз Исхакыйлар белән күршеләр булып, тату, дус яшәгән. Гаязның әнисе Камәрия әби Фәйзинең кендек әбисе булган. Дөньяга Фәйзи Йосыпов кычкырып, елап туа. Шунда Камәрия әби: «Һәй, бу баланың тавышы, бөтен дөньяны яңгыратырлык! Йа Раббым, яңгыратсын, бәхете, тәүфыйгы белән туган бала булсын!» – дигән. Менә шушы сүзләр аңа сәхнә юлына хәерфатиха булгандыр да инде.

Авыл аксакаллары истәлекләреннән:

– Гаяз Исхакыйның әтисе Гыйләҗетдин мулла бик укымышлы, гыйлемле кеше була, авылда мәдрәсә ачып, балалар укытуны оештырып җибәрә. Әхмәтхәсән (Гаяз Исхакыйның энесе) – Фәйзинең беренче укытучысы. Сигез яшендә мәктәп сәхнәсендә шигырьләр сөйли, спектакльләрдә катнаша. Аның сәхнә теле Габдулла Тукайның «Туган тел» шигыре белән ачыла.

Кызганыч ки, Яуширмәдә Йосыповлар нәселеннән беркем дә калмады, туганнары да авылда юк инде.

КАЗАН ГУБЕРНАСЫ 1812 ЕЛГЫ ВАТАН СУГЫШЫНДА

(АХЫРЫ. БАШЫ ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ 4 НЧЕ САНЫНДА)

Узган санда без тарихка «Беренче Ватан сугышы» исеме белән кереп калган тарихи вакыйганың алшартларына һәм төрле чорларда ничек бәяләнүенә тукталган идек. Бу юлы ошбу сугышта татарларның нинди катнашы булуга турыдан-туры тукталырбыз.

Автор:
Илдус Заһидуллин

АЛПАВЫТ-ДВОРЯННАР

Казан губернасында көн күргән һәм Петр I 1824 елда үзләрен крестьян сословиесенә яздырган татар морзалары, 1784 елгы Екатерина II указы булуга карамастан, төрле сәбәпләр аркасында үзләренең затлы нәсел дәвамчылары икәннәрен раслый алмый. Нәтиҗәдә ополчение әзерләү мәшәкате фәкать рус алпавытлары җилкәсенә төшә. Әйтергә кирәк, 1812 елны ополчение туплау 1806–1807 нче еллардагы ополчение җыю тәҗрибәсенә таянып оештырыла. Бу юлы ополчениегә алынудан дәүләт һәм удел крестьяннары азат ителә (18 июль манифестында аларның рекрут бирәсе барлыгы искәртелә), фәкать алпавыт крестьяннары, мещаннар һәм цехларга беркетелгән һөнәрчеләр генә кабул ителә.

Дәүләт алпавытларга «һәр 25 ир-ат крестьяннан бер сугышчы» дигән норматив куя. Крестьяннары аз булганнарга акчала ярдәм итәргә кушыла. Ополчение туплау сентябрь аена, урып-җыю вакытына туры килү сәбәпле, алпавытлар эшче кулларны озаграк эшләтеп калырга тырышканнар. Губернатор Борис Мансуров өяз шәһәрләренә кисәтү җибәрә башлагач кына, тәртип урнаша башлаган.

Дворяннар үз авылларында яшәгән 82000 ир-ат крестьяннан, дәүләт билгеләгән норматив буенча, ополчениегә 3280 сугышчы, шул исәптән 280 җайдак, аларны кием-салым белән тәэмин итәләр, үзләре хуҗа булган һәрбер крестьян исәбеннән 2 сум (Казан губернасыннан җыелган иганә акчасы җәяүле ополчениегә 1813 елның май ахырына кадәр җитә. – Авт.). 12 крестьяны булмаганнар дворяннар дәүләт билгеләгән акчасын бирә. Казан төбәгендә һәм Вятка губернасында алпавыт крестьяннары аз булу сәбәпле, бу ике ополчение берләшеп хәрәкәт итә. Бер төркем дворян, үзләре теләп, ополчениегә языла.



Алпавыт крестьяннарының, хуҗалары кушуына каршы килмичә, үзләре теләп ополчениегә язылуларының сере бар. Бу хакта Карл Фукс 1822 елда болай дип яза: алар ополчениегә патша галиҗәнаплары миһербанлыгына өмет итеп, сугыш беткәч, крепостной бәйләлектән котылып булыр, дип киттеләр. Кышкы салкыннарда шушы өмет белән җылынган, шушы хакта уйлап меңнәрчә чакрым юл үткән, 1813 елның октябрь башында Дрезденны камауда катнашкан бу батыр кешеләр, ни кызганыч, 1815 елда туган авылларына кайткач, кабат хокуксыз крестьяннарга әверелә. Аларның хыялы 1861 елда гына тормышка аша.

КРЕСТЬЯННАР ҺӘМ МЕЩАННАР

XIX гасыр башында шәһәрдә төпләнеп яшәүче татар мещаннары аз була, шуңа күрә үзләре теләп ополчениегә язылу очраклары да күп булмый. Татарларның ополчениегә язылулары турында ике факт билгеле. Татар бистәсендә яшәүче Нигъмәтуллина фамилияле хатын, Татар ратушасына мөрәҗәгать итеп, бер улының рекрут булып армиягә киткәнен әйтә, икенче улын да ополчениегә яздыруны сорый. Бу тарихның ничек төгәлләнгәне мәгълүм түгел. Мещаннар ополчениегә язылырга теләсәләр, салымнарны түләп бетерү турында кәгазь күрсәтергә тиеш булалар.

Икенче факт Казан ополчениесенең атлы батальон сугышчысы татар Аблаевның Мерзенбург һәм Гамбург янында бәрелешләрдә күрсәткән батырлыгы өчен хәрби бүләк алуына бәйле теркәлеп калган. 1810 елның 2 февраль «Дәүләт бурычларын киметү чаралары» манифесты крестьяннар һәм мещаннар өчен җан башыннан түләү салымы күләмен – 2 сумга, мещаннардан «промысел» салымын 5 сумга кадәр күтәрә, крестьяннарга дәүләт җиреннән файдаланган өчен, губерналардагы туфракның сыйфатына карап, ел саен җан башыннан 2 сумнан 3 сумга кадәр өстәмә түләү кертә. Шулай итеп, дәүләт крестьяннары кимендә ике тапкыр (2 + 2 сум) күбәйтелгән җан башыннан салым түләргә мәҗбүр ителәләр. Бу манифестта халыкка бердәнбер җылы сүз булып хакимияткә, дәүләт салымнары арту сәбәпле, җирле салымнарны күбәйтмәскә дигән кисәтү ирешә.

Җирдән файланган өчен җан башыннан салым түләү тәртибе беренче карашка гаҗәпләндерә, чөнки салым объекты – крестьян общиналарына дәүләт файдалануга биргән имана җирләр. Тиздән бу адымның дәвамлы булуы ачыклана: 1811 елда хөкүмәт салым түләүчеләр исемлеген яңарту (арттыру. – Авт.) өчен халык санын ала. Моңарчы крестьяннар һәм мещаннар 1795 елда уздырылган 5 нче ревизия буенча җан башыннан салым түләсәләр, хәзер барлык ир-атлар, яңа туган сабыйларны да исәпләп, салым түләүчегә әверелә, эксплуатацияләү тагын да көчәя. Шушы вакыйгаларга 1810–1812 нче елларда биш тапкыр рекрут бирүне дә өстәсәң, авыл халкының тормыш хәле начараюны ачыктан-ачык тоярга мөмкин. Ризаэтдин Фәхретдин үзенең биобиблиографик «Асар» исемле хезмәтендә 1812 елны ире рекрут итеп гаскәргә алынган Лаеш өязе Кече Елга авылыннан Фәйзулла кызы Зөһрәнең 1816 елның 6 апрелендә Казан ахуны Ибраһим Хуҗашка язган хатының күчермәсен бастыра. Кечкенә улы булган хатын каенатасы һәм иренең энесе белән бер йортта хуҗалык алып бара. Хәләл җефетенең ир туганы үлгәч, картайган каенатасы аңа «үз көнен үзе күрергә» куша. Ахун, ике шаһит раславына таянып, Зөһрәне армиягә киткән һәм инде 4 ел бер хәбәре дә булмаган солдат иреннән шәригатьчә аера.

Дәүләт болай да күп салым түләгән крестьянны иганәчелек кампаниясенә тартырга базмый. Тормыш хәлләре авырайган, рекрут яки ополчениегә ирегетләрне җибәреп, хуҗалыкта эш көченнән мәхрүм калган Казан губернасы крестьяннары арасында баш күтәрү очраклары булмый. Кайбер губерналарда крестьяннар хәрәкәтен бастыру өчен Наполеонга каршы җибәрелгән гаскәрләр дә җәлеп ителә. Сугыш хәленә тарган илдә салымнарны түләү һәм дәүләт куйган бурычларны үтәү (шул исәптән, регуляр армиягә рекрут биреп) татар игенчеләренең Наполеонны җиңүгә керткән өлеше була.

Регуляр армиядә күпме татар солдаты? Төгәл саннар билгеле булмау сәбәпле, без аларны математик исәпләү белән ачыкларга тырышырбыз.

1868–1873 нче елларда уртача ел саен 15815 татар (мөселманын һәм керәшенен кертеп) рекруты хәрби хезмәткә алынган, ягъни – 2,4%. 1812 елда регуляр гаскәрләрдә татар рекрутлары шул чама булган, дип әйтергә мөмкин.

Әйткәнебезчә, хөкүмәт 1810, 1811 һәм 1812 елларда халыктан биш тапкыр рекрут ала. Татар крестьяннары һәм мещаннары да төркем-төркем армиягә китә. 1812 елгы бәрелешләрдә һәм салкыннан Кутузов гаскәре саны нык кимү сәбәпле, яңа набор рекрутларны озак та үтми сугышка кергән, дип уйларга тулы нигез бар.

СӘҮДӘГӘРЛӘР

Шәһәр халкы һәм алпавытлар арасында хәрби иганәчелеккә 1812 елда, әле сугыш башланганчы ук старт бирелә. Май аенда төбәкләргә өстәмә 12 җәяүле полк төзү турында патша рескрипты килеп ирешә. Шуларның берсе – 2 нче Кострома полкы чыгымнарын Казан, Пермь һәм Оренбург губерналары капларга тиеш була. Казан граждан губернаторы Борис Мансуров тиз арада тиешле сумманы җыю өчен шәһәр үзидарәләренә һәм дворяннарга бурычлар йөкли.

6 июнь көнне Казан шәһәре думасы җыем күләмен билгели: сәүдәгәрләр 1812 елга игълан иткән капиталларының 1%ын, ир-ат мещаннар җан башыннан 2 шәр сум бирергә тиеш була. Бу җыелышта бистә татарлары вәкилләре дә катнаша.

Биредә шунысын да әйтеп китәргә кирәк: бу елларда Казанда ике үзидарә институты эшли: магистрат һәм 1782 елда Иске һәм Яңа татар бистәсендә яшәгән татарлар өчен ачылган Татар ратушасы.

15 июньдә губернатор Мансуров Татар ратушасына 2 нче Кострома полкын төзү өчен акча җыярга кирәклеген искәртеп хат җибәрә, үзидарә органы 17 июнь көнне бу эшкә җаваплы итеп сәүдәгәр М. Нагаевны һәм мещан А.Абдуллинны билгели. 3 июль көнне алар җәяүле полк төзү өчен халыктан җыелган 4100 сум акча тапшыра.

13 июнь көнне Александр I «Россия җирләреннән француз гаскәрләрен куу өчен корал күтәрү кирәклеге турында» указга кул куя. Халкының тырышлыгына, гаскәренең кыюлыгына ышаныч белдереп, император аларның туган йортларына куркыныч янаганда үзләренә хас никлык һәм батырлык белән көрәшәчәкләр дип уйлавын әйтә. Патша указы бик көчле иганәчелек дулкыны тудыра.

Иң бай сәүдәгәрләр Мәкәрҗә ярминкәсенә киткән булу сәбәпле, Казанда 1812 ел 13 июнь указын үтәү бераз кичектерелә. Алар Мәкәрҗә ярминкәсендә башка төбәкләрдән килгән дин кардәшләренең иганәчелек акцияләрендә актив катнаша. Әйтик, Казанның һәм Малмыжның 1 нче гильдия сәүдәгәрләре Муса Апанаев белән Муса Үтәмешев – 500 әр, Арчада теркәлгән сәүдәгәрләр Мөхәммәтрәхим Мәмешев, Мортаза Абурнаев, Абделкәрим Бәрәков – 100 әр, Касыйм шәһәреннән килгән морза Әхмәт Дәүләкаев – 200, Касыйм татары Тимур Максютов – 100, Хаҗитархан шәһәренең 1 нче гильдия сәүдәгәре Нияз Измайлов 1000 сум иганә итәләр. Муса Измайлов 8 август көнне купчелеге мөселманнарныкы булган Сабын сәүдә урыннарыннан 5690 сум акча җыеп тапшыра.

Казанның эре сәүдәгәрләре ярминкәдән Казанга әйләнеп кайткач, 21 август көнне шәһәр магистратында сәүдәгәрләр җыелышы була. Анда татарлардан депутатлар буларак А. Юнысов, М. Нагаев һәм ике татар бистәсенең дә башлыгы 1 нче гильдия сәүдәгәре Ю. Кытаев катнаша. Кабул ителгән карар җитди һәм сәүдәгәрләр өчен чыгымлы була. Гильдия шәһадәтнамәсе алу өчен игълан ителгән капиталның (биредә кучемсез милек тә керә. – Авт.) һәр 1 сумыннан 2 тиен иганә итәргә, ягъ-

ни 1812 елгы табышны исәпкә алмыйча 1 нче гильдия сәүдәгәре – 1000 сум, 2 нче гильдия вәкиле – 400, 3 нче гильдия сәүдәгәре – 160 сум тапшырырга тиеш була. 26 августта Татар шәһәр ратушасында булган җыелышта бу карар хупланып, иганә җыю 2 нче гильдия сәүдәгәре А.Замановка тапшырыла, мещаннар исә бу җаваплы һәм мәшәкатьле эшне Г.Нигъмәтуллинга йөклиләр.

Хакимият, иганә акчасын тизрәк җыю максатында, паспорт алу яки башка йомыш белән мөрәҗәгать иткән мещаннарның, тиешле иганә суммасын түләмичә торып, гозерләрен тоткарлау чарасын киң куллана.

Ләкин иганәчелек хәрәкәте тиз генә җәелеп китми. Казан иганә комитеты Татар ратушасына беркетелгән сәүдәгәр һәм мещаннардан мәҗбүри рәвештә 8360 сум һәм, шуңа «ирекле рәвештә» җыелачак суммаларны да өстәп, барлыгы 8808 сум 90 тиен тапшыру кирәклеген ирештерә һәм бу кадәр сумманы 5 октябрьгә түләп бетерергә кирәклеген искәртә. Татар шәһәр ратушасы 8 октябрьдә карар чыгара: тиешле иганә акчасы тапшырмаган кешеләр, канун бозучы сыйфатында, җаваплылыкка тартылачак! Ләкин эшләр барыбер акрын бара: 10 октябрьгә Казан иганә комитетына татар сәүдәгәрләреннән тагын 328 сум, мещаннардан 125 сум һәм ике ратуша әгъзасы биргән 32 сум тапшырыла. 12 октябрь көнне биредә 9 сәүдәгәр гаиләсе биргән 384 сум теркәлә. Шулай да 6 атна дәвамында 3 нче гильдия сәүдәгәр гаиләләренең берсеннән дә (егерме гаилә, яки ратушада теркәлгән гаиләләренең 67%) һәм 61 мещаннан (57%) акча гомумән җыелмый кала.

Сәүдәгәрләр, зарланып, өстәмә вакыт сорыйлар. Аларның дәлилләре урынлы: берәүләр янчыкларында акча булмау белән, икенчеләре товарлары сатылмау белән (чыннан да, бу юлы Мәкәрҗә ярминкәсендә сату-алу сүлпән бара, күпчелекнең табышлары уйлаганнан күпкә кайтыш була. – Авт.), өченчеләре бурычка акча алып торган кешеләрнең җавапсызлыгы белән аңлата. Мещаннарның да күрсәткечләре мактанырлык булмау сәбәбе: бер ишләрнең чит төбәкләрдә сату итәргә китүләре, икенчеләренең авыл җирендә яшәүләре.

ПОЛИЦИЯ

Аптырагач, түләмәүчеләр исемлеген Ратуша полициягә тапшыра. Полиция басымы астында иганәчелек акциясе алга китә: 18 октябрь көнне Казан иганә комитетына – 3965 сум, 24 октябрьдә тагын 148 сум тапшырыла.

Ратуша идарәсе 28 октябрь көне полиция ярдәме белән дәүләт алдында алган йөкләмәсен үтәмәгән 3 нче гильдия сәүдәгәре М.Пономаревны чакырып, гаепледән аңлатма язуы ала. Бу хакта ишеткән һәм шөбһәгә төшкән сәүдәгәрләр активлаша: 6 ноябрьдә иганәчелек комитетына тагын 1480 сум, 15 ноябрьдә 837 сум тапшырыла. Калган сумманы керттерү өчен 9 ноябрьдә Казан губерна идарәсе Татар ратушасына тиешле сумманы түләмәгәннәрнең җаваплылыкка тартылачагы турында указ җибәрә.

Алган «йөкләмәне» үтәү 1813 һәм 1814 елларда дәвам итә. Әйтик, 1813 елның июнь аенда тагын дүрт 3 нче гильдия татар сәүдәгәре, һәрберсе 160 ар сум түләп, бурычларын каплыйлар.

Әлбәттә, беренче карашка пассивлык кебек тоелган бу күренешнең объектив сәбәпләре була. Хакимият, иганә таләп итеп, сәүдәгәрләрнең матди хәленә күз йома. Сугыш чыгу сәбәпле, аларның сәүдә эшләренә зур зыян килә, планлаштырган табышларын ала алмаган эшмәкәрләр пошаманга төшә, кайберләре банкротлыкка чыга.

Рус сәүдәгәрләре арасында да иганә җыю авырдан бара, аларга карата да шундый ук полиция һәм губерна идарәсе басымы кулланыла, ләкин «йөкләмә»ләре 79% гына үтәлә (59127 сум). Биредә төп сәбәп шул ук: сугыш һәм арттырылган салымнар шартларында сәүдә итү кысылып, керәсе табышларны алмый калу, матди яктан кыен хәлгә тару күзәтелә.

1815 елгы мәгълүматлар буенча, русларның Җиңүгә керткән өлешләре түбәндәге иганә суммаларында чагыла: Казан шәһәре сәүдәгәрләре – 74040 сум, мещаннары – 10000, чит шәһәрләрдән теркәлгән сәүдәгәрләр – 640 сум, һөнәрче цехлары – 2000 сум, Чебоксар шәһәр җәмгыяте – 3000, Козьмодемьян шәһәренеке – 2000, Зөянеке – 700, Чуелныкы – 500, Лаешныкы – 500, Ядринныкы – 1520 сум. Губернада иң зур өяз шәһәре булган Чистайда күпме акча җыелганы ачыкланмый кала. Шулай да, игътибарны күпчелек өяз шәһәрләрендә җыелган сумманың ике «0» яки өч «0» гә беткәне җәлеп итә: алар өстән билгеләнгән планны үтәү саннарына ошап тора.

Хакимият бүлеп биргән сумманы арттырып түләүчеләр исемлегендә дворяннар гына була. Алар 2 нче Кострома полкының хәзерләү буенча йөкләмәләрен, натуралата түләмәүне шарт итеп, 7250 сумга арттып үтиләр – барлыгы 58000 сум җыеп тапшыралар.

ВАТАН ХАКЫ

Һәр сугыш хакимият өчен дә, гади халык өчен дә зур сынауга әверелә, ул халыкка хәерчелек, кайгы-хәсрәт алып килә. «Тыл губернасында» яшәгән халыкларның Ватанга ярдәмнәре, беренче чиратта, хәрби максатлар өчен дәүләтнең өстәмә чыгымнарын каплауда күренә. Крепостной тәртипләр хөкем сөргән дәүләттә иганәчәлек дини характерда була. Ул сословиеләргә бүленгән илдә гражданлык җәмгыяте нормаларының әле керә генә башлавы хакында да сөйли. Иганәчелек өчен кирәкле ирекле акча фәкать алпавытлар, чиновниклар һәм сәүдәгәрләр кулында булып, дәүләт билгеләгән хәрби чыгымнарның күләме зур булу сәбәпле, аларның матди ресурслары да нык чикләнә. Шәһәр үзидарәсендә яки сәүдәгәрләр җыелышында алган йөкләмәне гадел итеп бүлү кешеләрнең, чыннан да, үз теләкләре белән ярдәме кебек күренсә дә, чынлыкта ул губернатор билгеләгән суммага йөз тотып эшләнә. Нәтиҗәдә ихтыярый-мәҗбүри тәртип урнаша, халык тарафыннан пассивлык күзәтелгән очракта, административ ресурс кулланыла.

Шунысын да әйтергә кирәк: 1812 елгы сугыш шартларында аңлату эшләре җитәрлек алып барылмау күренә. Манифестны «Казанские известия» газетасында бастыралар. Әмма рус крестьяннарының күпчелеге укый-яза белмәү басма пропаганда чараларын куллану мөмкинлеген чикли.

Казан губернасында яшәгән татарлар, чувашлар, марилар, удмуртларның, русча белмәү сәбәпле, хакимият белән аралашканда тел барьерына очравы күзәтелә. Бу яктан «Ак патша» манифестын татарчага тәрҗемә итү, әлбәттә, уңай бәяләнергә тиеш. Дошман армиясен җиңү турында 1812 ел 26 декабрь манифесты та татарча бастырыла. Ул татарлар арасында гына түгел, Оренбург губернасында казахлар арасында да таратыла.

Дәүләтнең салым һәм иганәчелек сәясәте адреслы, бик төгәл, һәрбер социаль катлам вәкилләренең матди мөмкинлекләрен исәпкә алып оештырылган була.

Әмма Казан губернасында тулы канлы социаль структура руслар арасында гына булган. Нәкъ менә дворян катламы кеше ресурслары белән дә, ополчение һәм 2 нче Кострома полкын төзү чараларында да актив катнашкан.

Татарлар исә, сәүдәгәрләр, мещаннар һәм төп өлеше дәүләт крестьяннары катламнарына бүленеп яшәгәннәр. Чувашлар, марилар, удмуртлар фәкать авыл җирлегендә, игенче булып көн күргәннәр. Бу халыкларның һәрберсе үз социаль катламына йөкләнгән бурычны үтәгән. Үтәмәгән булса, административ яки җинаять җаваплылыгына тартылган.

Шулай итеп, крестьяннар салымнарны вакытында түләп һәм иген игеп, рекрут итеп армиягә алынганнары – командирлары боерыгына буйсынып, мещаннар – салымнар түләп, сәүдәгәрләр – салымнар түләүдән һәм иганәчелектән тыш, тире тетү, сабын кайнату, комач җитештерү, терлек мае эретү мануфактураларында халык хуҗалыгына һәм армиягә кирәк булган товар җитештереп, сату-алу итеп, 1812 елгы җиңүгә үз өлешен керткәннәр. Төрле катлам вәкилләренең тырыш хезмәте һәм нык арткан салымнарны вакытында түләве 1812 елгы җиңүнең матди нигезен тәшкил иткән. ■

ЖИҢҮ!
1945–2020

Сугыш ветераннары... Әйе, алар көннән-көн сирәгәя.
Шулай да бар әле, безнең бәхеткә,
зур сөенечкә, дип тә өстәргә кирәк.

Бөек Җиңүнең 75 еллыгын каршыларга җыенганда,
без аларны барларга, бер мәлгә булса да, ул елларны күз алдына
китерергә тырыштык. Юк, бу өлкәннәр өчен генә түгел,
бу, иң беренче чиратта, безнең үзебез өчен мөһим.

Алар кичергән фаҗигане ваемлау бүгенге
тормышыбызның кадерен белү, шөкер итү өчен кирәк...

«БЕЗНЕҢ ӘТИ БЕЛӘН ӘНИ БИК БӘХЕТЛЕ»

Автор:
Руфия Фазылова

– Картайды инде әни белән әти, – диде ишектән кергәндә Асия апа.

– Юкны сөйләмә, аякта йөрибез, колак ишетә, күз күрә, – дип шелтәләгән итте кызын Хатирә апа.

Асия апа, колакка пышылдап кына:

– Безнең әни гомергә ут булды, шуңа да үзен бер дә карт итеп күрсәтәсе килми, – диде.

Хатирә апа иплэп кенә тормыш иптәше янына барып утырды да:

– Менә бабаем гына өлкәнәйде, – дип, Мөбәрәкҗан аганың иңбашыннан какты.

Ирексездән барыбыз да елмаеп куйдык. Суслонгерда булып, сугышны кичкән бу ике ветеранның күргәннәрен ишеткәч, чәчләр үрә тора. Шул ук вакытта бу икәүнең 65 ел бергә иңгә-иң куеп, тигез гомер итүләрен, тәрбиядә яшәүләрен күргәч: «Яшьлекләрендә күргән михнәтләре өчен Аллаһы Тәгалә шундый гомер насыйп иткәндер», – диясең.

Салиховлар Кукмара районының Өлге (Люга) авылында яши. Мөбәрәкҗан агага 93 яшь, Хатирә апага июнь аенда 97 тула. Ике кыз тәрбияләп үстергәннәр. Олы кызлары Асия гел яннарында булган – күрше егетенә кияүгә чыккан. Ә төпчек кызлары Әлфия Казанда яши, шәфкать туташы булып эшли.

Фото «Хезмәт даны» (Кукмара районы) газетасыннан алынды

– Әти белән әнигә көн дә төшке ашка яңа ризык кертәм, – диде Асия апа. – Әлегә кадәр әни үзе пешерә иде. Соңгы бер елда ун тапкыр нурланыш алды. Шуңа да хәзер элеккеге кебек йөрми инде.

Ул да түгел, сүзгә Хатирә апа кушыла:

– И, кызым, әле өйләрне җыештырам, чәй куеп эчәбез, Аллага шөкер бит.

– Шулай, әни, – дип, елмаеп куя Асия апа. – Мин инде сине элеккеге чагың белән чагыштырып әйтәм. Бер генә дә тик тора торган кеше түгел идең бит. Өйне ялт итеп җыеп куя, шул арада тәмле итеп ризыгын әзерли...

– Әтиегез дә чисталыкны бик ярат-ты, – диде Хатирә апа. – Ишек алдында бер чүп тотмады. Ипле кеше булды, рәхмәт. Бер тавыш чыгарганын белмим.

Мөбәрәкҗан ага үзе турында сүз барганын аңлап, елмаеп куйды. Бабайның колаклары начар ишетә икән. Ирләргә хас булганча, күп сөйләргә яратмый ул. Бу гаиләдә Хатирә апа күз өстендәге каш булган. Мәктәп балалары белән очрашуларга, клубта чыгыш ясарга гел ул йөргән. Ә Мөбәрәкҗан ага ирләрчә юл куйган:

– Хатирә сөйләргә ярата, ул барсын, – дигән. Сугыш кичкән ханым исә ире өчен дә, үзе өчен дә сөйләгән.

Бу юлы да шулайрак булды, күбрәк Хатирә апа җавап бирде.

– Без икебез дә Өлге авылы кешеләре. Мөбәрәкҗан белән күрше урамнарда яшәдек. Бер-беребезне кечкенәдән белсәк тә, шактый соң кушылдык. Утыз тулгач кына кияүгә чыктым.

Мөбәрәкҗан ага 1943 елның ноябрендә фронтка чакыру кәгазе ала. Алты ай Суслонгерда үлем белән көрәшә. Аннан аны Калининград фронтына җибәрәләр. Укчылар полкына пулеметчы итеп билгелиләр. Тик зур тәҗрибәсе булмаган егет, минага эләгә. Нәтиҗәдә, ике аягы да җәрәхәтләнә. Һәм берничә ай госпитальдә дәвалана. Туган ягына ул 1945 елның октябрь аенда гына әйләнеп кайта.

Хатирә апа исә фронтка унтугыз яшендә китә. Тизләтелгән хәрби әзерлек узганнан соң, кызны Ленинград өлкәсенә – Киров заводына җибәрәләр. Бер төркем кызлар заводны саклый.

– Дошман самолетыннан җибәрелгән бомбалар бик күп кызларыбызны юк итте. Әле сугыш бетеп, күп еллар үткәч тә, самолет өстебезгә килә икән, дип төшләр күрә идем, – дип сөйләде Хатирә апа.

Әйе, барысы да артта калган, инде күбесе онытылган да. Бары күкрәкләрендәге медальләре генә ветераннарга ул дәһшәтле елларны хәтерләтә.

– Әле әти, сугыштан кайткач та, аягындагы мина кыйпылчыкларын чүпләп ала торган булган, – диде Асия апа.

Мөбәрәкҗан ага барысына да нәтиҗә ясагандай:

– Аллаһы Тәгалә матур тормыш насыйп иткән миңа, – диде. – Кызлардан уңдык. Әлфия атна саен диярлек кайтып йөри. Асияне әйткән дә юк, гел безнең белән. Кияүгә дә рәхмәт, улыбыз кебек булды. Оныклар, оныкчыклар күрергә дә насыйп итте. Тагын ни кирәк?! Калган гомеребезне дә Хатирә белән тигезлектә яшәп бетерергә язсын. Дәүләт тарафыннан да ихтирам зур, мин бик канәгать.

Ихтирам дигәннән, Хатирә апа быел, 8 март бәйрәме уңаеннан, Президент Рөстәм Миңнеханов янына очрашуга барган. Бик тәэсирләнеп кайткан ул аннан. Республика башлыгы ветеранга ак тун бүләк иткән.

– Кышларын шушы тунны киеп, очрашуларга барасым, кеше арасында йөрисем килә, – диде безгә ветеран.

Амин, шулай булсын...

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

100 ел эчендә ТАССР **НИНДИ** юллар үткән

Республика **КАЯН** башланган

30 нчы елларда **НӘРСӘЛӘР** булган

Бөек Җиңүне **НИЧЕК** якынайтканнар

50 нче елларда Казан **НИЧЕК** яшәгән

ТАССРда **НИНДИ** зур төзелешләр барган

ТАССР 100 ЕЛ ЛЕТ

БУЫННАР

«Татарстан» журналының махсус проекты

Май аенда Татарстан Республикасына 100 ел тулды. Түгәрәк тә, әһәмиятле дә юбилей: гасыр гына түгел, ә тарихның бер дәвере дә! 2020 елның декабрендә шулай ук 100 еллыгын билгеләячәк «Татарстан» журналы уртак юбилей уңаеннан «Буыннар» дигән проект әзерләде – анда без Татарстаныбызның олы тарихын язган кешеләр турында сөйләдек.

Бүген без җиңүләр һәм каһарманнар тулы 20 нче еллар буыны турында бәянебезне кабатларбыз. Ул – республиканы үз куллары белән төзегән кешеләр турында. ТАССР тарихын яза башлаганнар, Гражданнар сугышы тәмамлангач, тыныч тормыш төзегән, ачлык, караклык һәм талауларга каршы көрәшкәннәр турында. Коллективлаштыруда, сала-калаларны электр уты белән яктыртуда катнашканнар, чиркәү-мәчетләрне сүтеп, диннән баш тартканнар, иске тормышны җимереп, яңасын төзегәннәр турында...

Без моңа кадәр күрелмәгән энтузиазм һәм коточкыч репрессияләр чорында яшәргә туры килгән 30 нчы еллар буыны турында сөйләрбез.

Бөек Ватан сугышында катнашып, аннан җиңүче булып чыккан 40 нчы еллар буыны турында.

Сугыш җимергән шәһәрләрне торгызып, республиканың нефть сәнәгатен күтәргән 50 нче еллар буыны турында.

Космосны буйсындырган 60 нчы еллар буыны турында.

Ә инде журналыбызның июнь санында буыннар язмышы турындагы бәянебезне дәвам итәрбез...

ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ БЕЛӘН ТАРИХ ДӘРЕСЛӘРЕ

Республиканың 100 еллыгы – безнең горурлыгыбыз һәм киләчәккә өметләребез чагылышы ул. Безнең бу бер гасырлык тарихыбызны һәрбер татарстанлы белергә тиеш. Татарстан үсешендәге һәр чор, һәр этап – безгә, үткәннәр тәҗрибәсенә таянып, бүгенгебезне төзергә һәм киләчәкне планлаштырырга ярдәм итә торган сабак ул. «Татарстан» республика Президенты Рөстәм Миңнеханов белән яңа һәм иң яңа тарих дәресләре турында әңгәмә корды.

Фото: Рамил Гали

БЕРЕНЧЕ ДӘРЕС

ДӘРЕС АЛДЫ

– Рөстәм Нургалиевич, 1920 елның 27 маенда Мәскәүдә Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитеты (ВЦИК) һәм РСФСР Халык Комиссарлары Советының «Автономияле Татар Социалистик Совет Республикасы турында» декреты имзалана, ә 1920 елның 25 июнендә Казан губерна башкарма комитеты үз вәкаләтләрен тулысынча АТССР Вакытлы революцион комитетына тапшыра. Әлеге даталарның кайсысы республика өчен әһәмиятлерәк?

– Бу мөһим даталарның икесе дә яңа тарихи шартларда татар халкының дәүләтчелеге торгызылуын белдерә һәм борынгы заманнардан бирле зур цивилизацияле үзәкләрдән берсе булган төбәкнең алгарышлы үсеше нигезенә салына.

XX гасыр башына әлеге территория куәтле сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы төбәгенә әверелә, Россия империясендә иң укымышлылардан саналган татарлар буржуаз типтагы алдынгы милләт булып формалаша. Даһи Тукай һәм аның фикердәшләре эшчәнлеге нәтиҗәсендә татарлар арасында милли әдәбият зур абруй казана, матбугат, театр сәнгате, сәяси культура үсә.

Татар халкы вәкилләре гомумроссия сәяси партияләре, Дума эшчәнлеге мәктәбен үтә. 1917 елгы Февраль һәм Октябрь революцияләре йогынтысында Идел-Урал төбәген баштарак Идел-Урал Штаты, соңрак Татар-Башкорт республикасы формасында административ-территориаль үзгәртеп кору проектлары тәкъдим ителә. 1919 елның



В пятницу, 25 июня, в 3 ч. дня, в Красноармейском Дворце устраивается банкет по случаю объявления Автономной Татарской Соц. Советской Республики, на каковой банкет вы настоящим приглашаетесь.

Председатель Губисполкома Ходоровский.

Фото: ТР Милли музее, «Татарстан» журналы архивыннан

мартында Башкортостан автономияле республикасы төзелә. Шуннан соң татарларның дәүләтчелеге мәсьәләсе үзеннән-үзе хәл ителә – аерым Татар республикасы төзергә карар кылына. Эш 1920 елның берничә ае буе – майда имзаланган декретны әзерләүдән башлап, сентябрьдәге АТССР эшче, кызылармияче һәм крестьян депутатлары Советларының I Оештыру съездын үткәргәнче бара, анда Татарстан Үзәк Башкарма комитеты Президиумы сайлана һәм беренче хөкүмәт – Татреспублика халык комиссарлары Советы оештырыла.

ИКЕНЧЕ ДӘРЕС
СОВЕТ АВТОНОМИЯСЕ БАРЛЫККА КИЛҮ

– Сез ничек уйлыйсыз, заманча техникасыз, бөтенләй диярлек акчасыз һәм Гражданнар сугышыннан соң бик хәлсезләнгән килеш тә яшь республика ни рәвешле халык хуҗалыгын тиз арада аякка бастыра алды икән?

– Халыкның гадәттән тыш энтузиазмы, яңа тормыш төзү теләге һәм авыл хуҗалыгының тиз үсеше хисабына.

Яшь Татар республикасы Гражданнар сугышында җитди зыян күргән, хәрабәләргә күмелгән халык хуҗалыгын торгызырга тиеш була. Җитмәсә, оешкан елында ук республикага коточкыч ачлык ябырыла. Кешеләрнең ачлыктан качып илнең башка төбәкләренә күченүе һәм үлем-китем АТССР халкының 600 мең кешегә кимүенә китерә, 86 мең крестьян хуҗалыгы юкка чыга.

АТССРда бик кыска вакыт эчендә коллективлаштыру үткәрелә, бөтен илдәге кебек үк, биредә дә ул бик зур югалтуларга китерә. 1937 елда, яңа Конституция буенча республика ТАССР дип үзгәртелгәндә, анда колхозлар барлык крестьян хуҗалыкларының 92 процентын берләштерә, барлык чәчүлек җирләрнең 99 процентына алар хуҗа була. 51 совхоз һәм 3847 колхоз, 91 МТС исәпләнә. Авыл хуҗалыгын тиз үстерүдәге уңышлары өчен республика 1934 елда Ленин ордены белән бүләкләнә.

Ун ел дәвамында (1927–1937 еллар) Татарстан АССРда халык хуҗалыгы индустрияләштерелә. Инде 1928 елга ук сәнәгать һәм авыл хуҗалыгының барлык тармаклары тулысынча торгызыла, дистәләрчә яңа предприятие сафка бастырыла. Казан мех фабрикасы, киез-тула басу һәм җитен комбинатлары, Казандагы ТЭЦ-1 һәм ТЭЦ-2 җылылык электр станцияләре, кинопленка фабрикасы, авиация заводы, Казан синтетик каучук заводы, Яшел Үзән суднолар төзү заводы беренче бишьеллыкларның флагманнары була.

Шахтер Алексей Стаханов үрнәгендә республикада югары җитештерүчәнлек өчен ярыш кыза. Кузнецов, Сәйфуллин, Нигъмәтҗанов, Носов, Садриев һәм Татарстанның башка бик күп стахановчыэшчеләренең исемнәре бер дә газета битләреннән төшми.

Укый-яза белмәүчелеккә каршы көрәш, белем бирүнең барлык баскычларын актив үстерү Татарстандагы интеллектуаль потенциалны ишәйтү өчен алшартлар тудыра.

Казан университеты һәм 1921 елда Казанда ачылган Академия үзәге базасында фән уңышлы үсә. 30 нчы елларда иң зур югары уку йортлары – авиация, химия-технология, авыл хуҗалыгы, коммуналь хуҗалык инженерлары, медицина һәм юридик институтлар ачыла.

ӨЧЕНЧЕ ДӘРЕС
АШАУ ӨЧЕН ГЕНӘ ТҮГЕЛ...

– Театрлар төзелү яшь республика тормышының нәкъ менә беренче унъеллыкларына туры килә. Гаҗәпләнәсе генә кала – коллективлаштыру, индустрияләштерү, ачлык-ялангачлыкка каршы көрәшү һәм хәрабәләрне торгызу белән беррәттән театрлар ачарга да ничек өлгергәннәр икән?

– Мондый күтәрелеш булганда, бөтен нәрсә бик тиз үсә. Кеше ашау өчен генә яшәми бит. Күңел өчен дә һәрвакыт нидер кирәк. Бигрәк тә безнеке кебек иҗади, талантлы халыкка. Тарихтан белүебезчә, 30 нчы елларда Казанда биш профессиональ театр эшли. Милли театрның драма һәм музыкаль комедия кебек жанрлары аеруча киң тарала. 30 нчы елларда милли опера һәм балет, симфоник музыка, кино, сынлы сәнгать үсеше зур казаныш була.

Галимҗан Ибраһимов һәм Шәриф Камал, Муса Җәлил һәм Мирхәйдәр Фәйзи, Һади Такташ һәм Салих Сәйдәшев, Фәрит Яруллин һәм Бакый Урманче, Кәрим Тинчурин һәм Нәҗип Җиһанов, Галиәсгар Камал һәм Кави Нәҗми, Лотфулла Фәттахов исемнәре бу елларда милли мәдәниятнең гөрләп үсуен гәүдәләндерә.

Дәүләтчелекне үстерүдә идарә итү аппаратын тамырлаштыру һәм дәүләт идарәсенең барлык өлкәләрендә һәм халык хуҗалыгы тармаклары җитәкчелегендә татар телен киң куллануны гамәлгә кертү кампанияләре уңай роль уйный. Әлеге процессларга меңләгән укымышлы яшь татар җәлеп ителә. Шул рәвешле, совет автономиясенең татарларны югары мәдәниятле һәм үзаңлы алдынгы милләткә әйләндерү өчен бөтен шартлар тудыруында шик юк.

Әмма 30 нчы еллар азагына Татреспубликаның үсеше акрыная.

Ике тапкыр алфавит алыштыру татар мәдәниятенә зур зыян сала – киң халык массалары татар халкының гарәп графикасындагы алты йөз еллык язма мирасыннан мәхрүм ителә.

30 нчы еллардагы сәяси репрессияләр Татарстандагы 70 меңнән артык кешегә кагыла. «Хәтер китабы» мәгълүматлары буенча, 13 938 татарстанлы тоткынлыкта һәлак була, 5 922 кеше атыла.

Татарстан республикасының беренче җитәкчеләре Борһан Мансуров һәм Сәхибгәрәй Сәетгалиев, милли-дәүләт

төзелешенең күренекле теоретигы Мирсәет Солтангалиев, республиканың 30 нчы еллардагы җитәкчеләре Кыям Абрамов, Михаил Разумов, Әхмәтсафа Дәүләтьяров, татар әдәбиятында социалистик реализмга нигез салучы Галимҗан Ибраһимов, күренекле тарихчы Михаил Худяков, драматург Кәрим Тинчурин, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Шамил Усманов һәлак була; Казан шәһәр Советы рәисе Павел Аксенов, рәссам Бакый Урманче, комдив Якуб Чанышев, татар поэзиясе классигы Хәсән Туфан, Казан язучысы Евгения Гинзбург һәм башка бик күпләр репрессияләргә дучар ителә.

ДҮРТЕНЧЕ ДӘРЕС

СУГЫШ ҺӘМ ХЕЗМӘТ КАҺАРМАННАРЫ

– Бөек Ватан сугышында җиңүдән соң 75 ел вакыт үтте. ТАССРның җиңүгә керткән өлеше бөек һәм онытылмаслык. Сезне татарстанлыларның нинди батырлыгы аеруча тәэсирләндерә?

– Миңа безнең геройларыбызның һәркайсы кадерле, һәр батырлык сокланугa һәм бабаларыбыз белән горурланугa лаек. Алар Ватанны да саклаган, бирелә, тылда да геройларча хезмәт куйган. 225 татарстанлыга Советлар Союзы Герое исеме бирелгән, 48 фронтовик Дан орденының тулы кавалеры булган, Татарстанда туган 200 меңнән артык кеше орденнар һәм медальләр белән бүләкләнгән. Ничек түзгән алар? Нинди көч булган аларда? Ә менә без шулай булдыра алыр идекме?

Бик күп кеше һәлак ителүгә карамастан, Татарстан республикасы Бөек Ватан сугышы алдыннан Советлар Союзының аеруча алга киткән төбәкләреннән берсе була. Шактый азык-төлек ресурсына ия алдынгы авыл хуҗалыгы булган, сәнәгатьнең яңа тармакларына баетылган республика илдәге иң мөһим тыл базаларыннан берсенә әйләнә.

1939–1945 елларда хәрәкәттәге армиягә 700 меңнән артыграк татарстанлы алына, шулардан яртысы яу кырында ятып кала.

ТАССРның Түбән Кама районы Прости авылында туган Никита Кайманов җитәкчелегендәге чик буе заставасы 1941 елның 22 июнендә дошманны беренчеләрдән булып каршы ала. Дошман бик еракка алга үтеп китсә дә, сугышчылар совет-фин чигендәге әлеге участокны 19 тәүлек буе саклап тора. Шушы батырлыгы өчен якташыбызга Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

Танылган татар шагыйре Зәки Нури Орша тирәсендәге «Победа» партизан отрядында башта шартлатучы, аннары разведка отряды башлыгы була.

Камалышта калган Минскида яшерен оешма эшли, аны төзүчеләрдән берсе элек Казанда трамвай йөртүче булып эшләгән, соңыннан Советлар Союзы Герое исеме бирелгән Иван Кабушкин була.

Татарстан егете Петр Савинов, 1943–1944 елларда Украинада танк ротасы командиры сыйфатында сугышканда, дошманның 7 танкын, «Хейнкель-123» самолетын, 3 үзйөрешле машинасын һәм 14 бронетранспортерын, 500 дән артык гитлерчыны юк итә. Соңгы сугышында 4 «Тигр» танкын яндыра. Һәлак була, әмма яу кырыннан чигенми. Бүген герой исемен республиканың Балык Бистәсе районындагы мәктәп йөртә.

46 нчы гвардия Тамань хатын-кызлар төнге бомбардировщиклар авиация полкы эскадрилья командиры урынбасары, Советлар Союзы Герое Мәгубә Сыртланова Кызыл Армиядә 1941 елның июленнән бирле сугыша, 780 сугыш очышы ясый, иң катлаулы һава торышы шартларында да бик төгәл итеп 190 тонна бомба ташлый.

Казанда туган 17 яшьлек сержант Борис Кузнецов 1943 елның октябрендә Днепрны кичүдә катнаша. Элемтә бүлекчәсе белән үзләре ясаган салда дошман уты астында елганы кичеп, ул кабель линиясен сала һәм плацдармдагы алдынгы отрядның артиллерия батареясе белән элемтәсен урнаштыра. Ике тапкыр яраланса да, сафта кала. Советлар Союзы Герое Борис Кириллович Кузнецов бүген дә яшьләр арасында зур хәрби-патриотик эш алып бара.

Без шулай ук Петр Гаврилов, Николай Столяров, Газинур Гафиятуллин, Муса Җәлил, Михаил Девятаев, Илдар Мәннанов, Сабир Әхтәмов һәм Татарстанның башка бик күп каһарман сугышчыларының батырлыгы белән горурланабыз.

Республика Кызыл Армиянең хәрби резервларын әзерләү урыны була. Бирелә 180 меңнән артык кеше хәрби әзерлек үтә, ике авиация һәм җиде укчы дивизия, ун аерым полк һәм батальон, ил Хәрби-Һава Көчләренең йөзләрчә сугыш экипажы оештырыла.

Казан эшчеләре белән бергә 70 сәнәгать предприятиесен, СССР Фәннәр Академиясенең 33 институтын, кайбер берлек халык комиссариатларын, Дәүләт банкын кабул итә; Чистай, Казан һәм Алабугада илнең Язучылар берлеге әгъзалары урнаштырыла.

Республикада 75 хәрби госпиталь эшли, алар 20 дивизиягә сыярлык сугышчыны, дәвалап, кире фронтка җибәрә.

Сугыш елларында республика предприятиеләрендә 600 дән артык төрле корал, сугыш кирәк-ярагы, хәрби техника, Кызыл Армия сугышчылары өчен 200ләп исемдәге кием-салым һәм кирәк-ярак җитештерелә. Авыл хуҗалыгы бертуктаусыз армияне азык-төлек белән тәэмин итә.

Казанның авиация заводларында сугыш елларында 10 меңнән артык Пе-2 һәм Пе-8 стратегик бомбардировщигы, 11 меңнән артык У-2 бомбардировщигы (СССР хәрби авиациясенең һәр алтынчы сугыш самолеты) җитештерелә.

Казан предприятиеләрендә көн саен бер полкны киендерерлек һәм бер дивизияне аяк киеме белән тәэмин итәрлек продукция эшләнә. Сугыш

елларында барлыгы 822 мең шинель, 2,3 миллион шаровар һәм гимнастерка комплекты, 8,2 миллион эчке кием комплекты, 6 миллион пар киез итек, 5 миллион пар армия итеге, 4,4 миллион бүрек һәм башка продукция җитештерелә. Казан госпитальләрендә Кызыл Армиянең 334 мең сугышчысы дәвалану һәм реабилитация курсы үтә.

Халкының Бөек Ватан сугышында Җиңүгә керткән өлеше өчен СССР Югары Советы Президиумы указы белән 1984 елда Казан Ленин ордены белән бүләкләнә.

Хәтер һәм дан елында без һәркайсы уртак җиңүгә үз өлешен керткән барлык фронтовикларга, тыл ветераннарына, фашист лагерьлары тоткыннарына, сугыш чоры балаларына хөрмәт һәм рәхмәтебезне җиткерәбез.

БИШЕНЧЕ ДӘРЕС

АЛГА!

– ТАССР га Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышын кичерергә, аннары алардан соңгы җимерекләрне торгызырга туры килә. Сез ничек уйлыйсыз, халык хуҗалыгын торгызу кайчан кыенрак булган – 20 нче еллардамы, әллә 40 нчы еллардамы?

– Кешенең табигате шундый бит – һәр җимергеч халәттән соң тизрәк тәртип урнаштырасы һәм алга барасы, төзисе, иҗат итәсе килә. Шунлыктан сугыштан соңгы унъеллыклар совет Татарстанының социаль-икътисадый үсешендә аеруча нәтиҗәле чор була. Сугыштагы батырлыклардан соң хезмәт казанышлары чоры башлана.

Казанның илебездәге машина төзелеше үзәкләреннән берсенә әйләнүе, зур нефтьне үзләштерү һәм Камада нефть химиясе җитештерүләре комплексын салу, КАМАЗны төзү, Әлмәт, Түбән Кама, Яр Чаллы шәһәрләренең республиканың көньяк-көнбатышындагы зур сәнәгать үзәкләренә әйләнүе хуҗалык үсешенең яңа этабы башлануын күрсәтә.

1943 елның 25 июлендә Шөгер янында Гариф Хәмидуллин бригадасы бораулаган скважинадан тәүлегенә 20 тонна дебитлы нефть фонтаны бәреп чыга. Бу Татарстан нефте табыла башлаган көн санала.

70 нче елларда ул рекордлы күләмдә – елына 100 миллион тонна чыгарыла. Татарстан нефтьчеләре барлыгы 3,4 миллиард тоннадан артыграк кара алтын тапкан.

60–70 нче еллар – Камадагы хезмәт батырлыгы дәвере. Борынгы елга ярларында Европада иң зур нефть химиясе җитештерүләре һәм зур йөк автомобильләре җитештерә торган Кама заводлар комплексы төзелә, Түбән Кама һәм Яр Чаллы шәһәрләре калка.

Бүген КАМАЗ авыр йөк машиналары җитештерү буенча дөньяның әйдәп баручы 20 компаниясе арасына керә, анда барлыгы 2 миллион 322 меңнән артыграк автомобиль җитештерелгән. КАМАЗ төзелә башлауга 50 ел тулу уңаеннан уздырылган һәм Россия Президенты Владимир Путин да катнашкан тантанада төзүчеләрнең һәм завод эшчеләренең фидакарь хезмәте кабат зур бәя алды.

Бөгелмә, Лениногорск, Менделеевск та нефть чыгару һәм нефть продуктларын эшкәртү үзәкләренә әйләнә. Зәйдә (ГРЭС), Казанда (ТЭЦ-3), Түбән Камада (ТЭЦ-1 һәм ГЭС) зур электр станцияләрен сафка бастырганнан соң, республиканың электр энергиясенә булган ихтыяҗы тулысынча канәгатьләндерелә һәм ул аны илнең башка төбәкләренә дә җибәрә башлый.

Без горурланып әйтә алабыз – бу елларда Татарстан җитештерүләре һәм төзелешләренең Валентин Шашин, Николай Лемаев, Николай Максимов, Виталий Копылов, Лев Васильев, Владимир Лушников, Илдус Мостюков, Николай Калашников, Евгений Батенчук кебек «генераллары» Татарстан сәнәгатен һәм төзелеш тармагын бөтенсоюз дәрәҗәсенә күтәрде.

Республика илне вертолетлар, самолетлар, зур йөк автомобильләре, нефть химиясе продуктлары, шиннар, корабльләр, компрессорлар һәм суыткычлар, полиэтилен, синтетик каучук, медицина һәм оптика әсбаплары, юу чаралары һәм дару препаратлары белән тәэмин итә.

Совет елларында Татарстан башкаласы зур академик үзәккә, фән һәм студентлар шәһәренә әйләнә. Александр һәм Борис Арбузовлар, Гыйлем Камай, Евгений Завойский, Хәмит Мөштәри, Александр Вишневский, Семен Альтшулер һәм бик күп башка галимнәр Татарстан фәненә дөньякүләм танылу китерә.

Икътисад һәм мәдәнияттәге зур уңышлары һәм 50 еллыгы уңаеннан 1970 елның 24 июнендә ТАССР Октябрь революциясе ордены, ә 1972 елның 29 декабрендә Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә.

Без татарстанлылар тормышын яхшырту өчен армый-талмый тырышкан ТАССР җитәкчеләре З.И.Моратов, С.Д.Игнатьев, Ф.А.Табиев, Р.М.Мусин, Г.И.Усмановның гаять зур хезмәтенә бик рәхмәтле.

Үз тарихының совет чоры азагында Татарстан Советлар Берлегенең иң алдынгы республикаларыннан санала, аның тулай продукт күләме Балтыйк буе республикаларының өчесенекен бергә кушып исәпләгәннән дә артыграк була.

Шул ук вакытта автономиянең административ-командалык кысалары тизләнешле үсешкә аяк чала, республиканың бөтенләй мөстәкыйльлеге булмый – барлык социаль-икътисадый мөнәсәбәтләр, хәтта вак-төяк тә Мәскәүдән көйләнә. Республика финанс мөмкинлекләренең чикләнгәнлеге территорияләрне үстерү мәсьәләсен хәл итүгә комачаулый. Социаль сфера халыкның ихтыяҗларын канәгатьләндерергә өлгерми. Милекне бүлүдә кискен каршылык күзәтелә – республика

үз территориясендәге мөлкәт комплексының нибары 3 процентына гына хуҗа була.

Җитештерелгән тулай продукт күләме күрсәткечләре һәм бөтенсоюз масштабындагы гигант проектлар артыннан куганда, еш кына конкрет кеше мәнфәгатьләре онытыла. Советлар чорының соңгы дәверендәге рәсми купшылык, җитешсезлекләрне яшереп калдыру җәмәгатьчелекнең ризасызлыгын уята. Милли мәктәпләр санының кимүе, татар телен куллану мохитенең әкренләп чикләнүе татар зыялыларын хафага сала. Республикада Татарстанның союздашлык статусын дәгъвалаучы иҗтимагый хәрәкәт колач җәя, гомумроссия процесслары йогынтысында ул соңрак чын суверенлык өчен хәрәкәткә әйләнә. Җәмгыятьтә кискен бәхәсләр кыза, урамнарда митинглар кайный. Ул чактагы сәяси көрәш үзәгендә республиканың статусы, аның киләчәктә Мәскәү белән мөнәсәбәтләре мәсьәләсе тора.

Илнең таркалуы һәм хуҗалык итүче субъектлар арасындагы икътисадый бәйләнешләр өзелү халыкның матди һәм социаль тормышында гаять зур кыенлыкларга китерә – товар кытлыгы, инфляция, хаерчеләнү, җинаятьчелек арту һәм башка бәлаләр берсе өстенә берсе өелә.

АЛТЫНЧЫ ДӘРЕС

МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК ЗАМАНЫ

– Республиканың дистәләрчә еллар буе тупланган потенциалын саклап калу, аны әлеге катлаулы заманның бихисап проблемаларын хәл иткәндә җуймау Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев сәясәте нәтиҗәсендә мөмкин булдымы?

– Республика җитәкчелеге һәм җәмәгатьчелек демократлаштыру процессында күп гаделсезлекләрне төзәтү, күбрәк мөстәкыйльлек алуга өметләнде.

1990 елның 30 августында бертавыштан диярлек кабул ителгән Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы Декларация һәм 1992 елгы референдум кысаларында республиканың яңа статусын халыкның хуплавы (62 процент) иң мөһим сәяси карарлар булып тора. Алар Татарстандагы сәяси процессларның киләчәгенә зур йогынты ясады.

Федераль үзәк белән компромисслар системасы кискен конфликт булдырмау, киләчәктә исә «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында үзара эшләр бүлешү һәм вәкаләтләр алмашу турында» Шартнамә төзү мөмкинлеген бирде.

Яңа дәүләтчелек шартларында гамәлгә кертелгән базарга «йомшак керү» һәм халыкны адреслы социаль яклау программалары, 1996–2000 елларда республиканың социаль-икътисадый алгарышы, тузган торакны бетерү, торак пунктларны газлаштыру һәм башка программалар ахыр чиктә татарстанлыларның тормыш сыйфатын яхшыртуга китерде.

ҖИДЕНЧЕ ДӘРЕС

ДӨНЬЯ АРЕНАСЫНА ЧЫГУ

– Яңа меңьеллык Татарстанны бөтен җиһанга танытты. Һәм дөнья күләмендәге һәр вакыйга, аңа әзерлек татарстанлылар тормышын уңай якка үзгәртте. Татарстанда хуҗалар да, кунаклар да яхшы яши башлады. Бу республика җитәкчелегенең принципиаль позициясеме?

– Бу безнең йортыбыз, без биредә яшибез, безгә уңайлы булырга тиеш. Һәм безнең халык һәрвакыт бик кунакчыл булган – моны тарихтан да, әдәби әсәрләрдән дә күрергә мөмкин. Әгәр туган җиреңдә яшәве рәхәт икән, беркемнең дә аннан китәсе килмәячәк. Киресенчә, башкалар безгә омтылачак – рәхим итсеннәр!

2005 елда Казанның меңьеллыгын билгеләп үтү мөһим тарихи вакыйга булды. Аңа биш ел буе әзерләндек. Юбилейны бәйрәм итү комиссиясен Россия Президенты Владимир Владимирович Путин җитәкләде. Тантанадагы чыгышында ул: «Казан бер-берсенә бөтенләй охшамаган мәдәниятләр һәм цивилизацияләрне озак вакытлар буе көйләп һәм килештереп торды, үзгә милләтара эретмә хасил итүгә булышты, ул исә, һичшиксез, Россия дәүләтчелеген ныгытты, ә милли һәм дини сабырлык принцибы күп гасырлар буе янәшә тыныч яшәү нигезенә әйләнде», – дип билгеләп үтте. Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итү татарстанлыларның бөтен ил белән берләшүен, халкыбызның тарихи һәм яңа казанышларының дәүләткүләм танылуын күрсәтте.

Республиканың иҗтимагый үсешенең иң мөһим нәтиҗәсе – гомумгражданлык, бигрәк тә милләтара килешү һәм динара тынычлыкның югары дәрәҗәсен саклау һәм ныгыту, рухи яңарыш процессының позитив агышы.

Монда федераль үзәкнең, барыннан да бигрәк лидерыбыз Владимир Владимирович Путинның һәрьяклап хуплавы зур роль уйнады.

Татарстандагы иҗтимагый-сәяси тотрыклылык икътисад һәм социаль сфераларның уңышлы үсеше өчен ныклы нигез булды һәм булачак та.

Бүген Татарстан – куәтле Россия төзү курсын хуплый торган алдынгы, икътисадый яктан уңышка ирешкән төбәк.

Без үткәннәребезнең кадерен беләбез һәм бүгенге кыю үзгәрешләргә әзербез. «Яңарыш» фонды химаячелегендә борынгы Болгарның һәм Зөя утрау-шәһәренең уникаль объектлары торгызылды, алар бүген, Казан Кремле белән беррәттән, ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы Исемлегенә кертелгән.

Республика нефть чыгару һәм эшкәртү төбәге, нефть химиясе, машина һәм авиатөзелештә төп уенчылардан берсе, фән-мәгариф үзәге сыйфатында,

Фото: Рамил Гали

шулай ук авыл хуҗалыгы җитештерүе лидерларыннан берсе буларак бөтен илгә һәм бар җиһанга мәгълүм.

Татарстанда заманча инновацион структура формалашкан, илдә иң шәп «Алабуга» махсус икътисадый зонасы югары нәтиҗәләр күрсәтә, Россиядәге иң яшь шәһәр – Иннополис һәм аның йөрәге – халыкара университет бик тиз үсә.

Республика тулысынча газлаштырылган, шәһәр һәм авыл төзелеше тизләтелгән темпта бара. Дистәләрчә яңа спорт һәм мәдәният-сәламәтләндерү объекты пәйда булды. Республика башкаласында метро төзелде, Кама елгасы аша күпер салынды, йөзләрчә чакрым юлга асфальт җәелде.

Без гамәлгә кертә торган «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе» көндәшләрдән глобаль өстенлекләргә ирешү, заманча югары технологияле җитештерүләрне үстерүгә юнәлтелгән.

Бүген Татарстан Россия Федерациясе милли проектларын һәм стратегик инициативаларын гамәлгә кертүдә актив катнаша. Без төп бизмән һәм бер үк вакытта ахыргы максат булган кеше капиталын камилләштерүгә өстенлек бирәбез. Әлеге җәһәттән республикада илледән артык социаль программа уңышлы тормышка ашырыла.

Алар арасындагы сәламәтлек саклау объектларын, мәктәп биналарын, авыл клубларын, балаларның җәйге ял лагерьларын капиталь ремонтлау кебекләре, иҗтимагый пространстволарны, парк һәм скверларны үстерү һәм «Безнең ишегалды» программасы белән берләштән, кешеләрнең яшәү мохитен үзгәртү, татарстанлыларның тормышын тагын да уңайлырак һәм баерак итү мөмкинлеген бирәчәк.

Татарстан халыкара хезмәттәшлектә актив катнаша, инвестицияләр җәлеп итү рейтингында беренче урыннарда бара, еш кына чит ил компанияләренең Россия базарына керү ноктасы булып тора.

«Россия – Ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме кысаларында элемтәләр урнаштыру, республикабызда ЮНЕСКО конференцияләрен, БРИКС илләренең туганлашкан шәһәрләре һәм муниципаль берәмлекләре форумнарын, KazanSummit Халыкара форумын үткәрү республиканың югары халыкара абруен ачык дәлилли.

XXI гасырның икенче унъеллыгында без чын спорт тантанасына һәм кешеләр арасындагы дустанә мөнәсәбәтләр бәйрәменә әйләнгән халыкара ярышлар уздырдык. Алар арасында – 2013 елгы Бөтендөнья җәйге Универсиадасы, 2015 елгы су спорт төрләре буенча дөнья чемпионаты, 2018 елгы футбол буенча дөнья чемпионаты матчлары.

Милли беренчелектә җиңү һәм 2019 елда һөнәри осталык буенча WorldSkills дөнья чемпионатын уңышлы үткәрү югары квалификацияле кадрлар әзерләүгә куәтле этәргеч бирде.

Казан хаклы рәвештә илнең спорт башкаласы, республика исә зур туристлык үзәге булып санала башлады – кунаклар саны 2010 елгы 1,4 миллионнан 2019 елгы 3,5 миллионнан артык кешегә җитте. Татарстанлыларның яшәү рәвешенә спорт үтеп керү безнең тормыш сыйфатын тагын да яхшыртты.

Татар халкының этномәдәни үсешендәге уңышларны үткән гасырның мөһим нәтиҗәләреннән берсе, дип атап була. Татар теленең дәүләт статусын алуы, милли мәгарифкә ярдәм, абруйлы татар иҗтимагый берләшмәләре барлыкка килү, ватандашларга булышу, ниһаять, Россиядә халык саны буенча икенче урындагы татарларның уңай имиджын булдыру татар милләте үзаның яңа биеклеккә күтәрде.

СИГЕЗЕНЧЕ ДӘРЕС

ТОРМЫШ ДӘВАМ ИТӘ

– 2020 ел – Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгы. Коронавируска бәйле вазгыять нәтиҗәсендә республика үз хөрмәтенә бәйрәмнән мәхрүм кала язды. Шундый юбилей хөрмәтенә бүләксез дә калмасмы икән?

– «Бу да үтәчәк», – дигән Сөләйман патша. Коронавирус та үтәр. Тормыш дәвам итә. Быелгы яздагы пандемиягә бәйле катлаулы вазгыятькә карамастан, ТАССРның 100 еллыгы хөрмәтенә тантаналар үткәрелэчәк. Без Зур Казан боҗрасының яңа участокларын ачабыз; Татарстан Республикасы Милли китапханәсе яңа бинага күчә; элеккеге Эшче (Алафузов) театры бинасында ремонт тәгәлләнеп, «Созвездие-Йолдызлык» театры шунда урнашачак; Дәрвишләр бистәсендәге Сәетгалиев исемендәге һәм Юдинодагы тимерьюлчылар мәдәният сарайлары да ремонттан соң ачылачак. Мәдәният-спорт сферасының социаль әһәмияттәге башка объектлары, парк һәм скверлар сафка басачак. ТАССРның 100 еллыгы исемен Казан метросы станцияләренең берсе, Татарстан шәһәр һәм район үзәкләре урамнары һәм мәйданнары йөртәчәк.

Һичшиксез, кешеләр һәрвакыт безнең игътибар үзәгендә булачак. Республика уңышларының нигезендә ничәмә буын татарстанлының тырыш хезмәте ята бит.

Татарстан АССР төзелү турында Декрет имзалануга 100 ел тулган көнне сезнең барыгызны да туган республикабызның бер гасырлык юбилее белән тәбрик итәм һәм туган Татарстаныбызның гөрләп үсүенә үз өлешен кертүче һәркемгә үземнең рәхмәтемне белдерәм.

Безгә борынгы бабаларыбызның бөек рухы белән сугарылган ватаныбызда туарга, яшәргә һәм халкыбызга хезмәт итәргә насыйп булды. 100 еллык иҗади-тарихи юл – безнең горурлыгыбыз һәм киләчәк көнгә ышанычыбыз ул!

«Татарстан» журналының махсус проекты

20нче еллар

БУЫННАР

ЯҢА ТОРМЫШ ТӨЗҮЧЕЛӘР БУЫНЫ

20 нче еллар буыны – Татарстан тарихын башлаган, төзегән, балалары – киләчәк буыннар хакына тырышып хезмәт иткән кешеләр һәм вакыйгалар ул. Нәтиҗәләре нинди булуын без беләбез, әмма алар, киләчәк буыннар язмышына тигән сугышларны да, фаҗигаләрне дә белмичә, якты киләчәк өчен армый-талмый хезмәт иткән. Шулай да республика тарихы, нинди генә глобаль вакыйгалар кичерсә дә, иң беренче нәүбәттә анда гомер иткән конкрет кешеләр, алар язмышына туры килгән тарихлардан тора.

Республика каян башланган? Узган гасырның 20 нче елларында нәрсәләр булган? Аның чишмә башы нинди шәхесләр һәм тарихлар белән бәйле?*

ХРОНОГРАФ

1920

- Автономияле Татар Социалистик Совет Республикасы (АТССР) төзелү турында Декрет имзалана.
- АТССР Эшче, кызылармияче һәм крестьян депутатларының I Оештыру съездында Татар Үзәк Башкарма Комитеты (ҮБК) президиумы сайлана һәм беренче хөкүмәт – Татреспублика Халык Комиссарлары Советы (ХКС) формалаша.
- Азык-төлек отрядлары (продотрядлар) Татарстаннан 10 миллион пот икмәк җыеп җибәрә.

1921

- Татар телен барлык рәсми инстанцияләрдә куллануның мәҗбүрилеге турында Татреспублика ҮБК һәм ХКС Декреты кабул ителә.

1921–1922

- Корылык һәм ачлык. Ачлыктан 100 меңнән артык кеше үлә.

1922

- Казан авыл хуҗалыгы һәм урманчылык институты ачыла.

1923

- Мәскәүдә милли республика һәм өлкәләрнең җаваплы хезмәткәрләре белән РКП(б) ҮК киңәшмәсе уздырыла.
- Беренче Татар эшчеләр факультеты (рабфак) ачыла.

* 20нче еллар буыны турында тулырак – журналыбызның 2018 елның июль санында.

1924

• Таткино төзелә. Документаль фильмнар төшерелә башлый.

1925

• Партия ҮКның «Татар өлкә партия оешмасының торышы һәм эше турында»гы карары чыга.

1926

• Казан хезмәт биржасында 30 мең эшсез кеше теркәлә.

1927

• Татарстанда даими радиотапшырулар оештырыла. Казан радиостанциясе тапшырулары татар, рус, чуваш телләрендә бара.

• Татар теле алфавиты сыйфатында яңалиф рәсмиләштерелә. Гарәп графикасы революцион үзгәрешләрне тоткарлаучы дип танылa.

1928

• Республиканың бөтен индустриаль секторы диярлек дәүләтнекенә әйләнә.

• «Беренче татар мех фабрикасы» төзелә.

1929

• Сәнәгать ударникларының беренче республика слеты уза.

• Казанда мөэминнәрдән беренче мәчет тартып алына һәм «мәдәният хаҗәтләренә» яраклаштырып үзгәртелә.

РЕСПУБЛИКА. БЕРЕНЧЕ КӨН

1920 елның 25 июнендә иртәнге сәгать сигездә Казанның үзәгендә яңгыраган туп тавышы сизгер күңелле кайбер гүзәл затларның котын ала. Чөнки әле ике ел элек кенә булып узганнарның хатирәсе – шәһәрне аклар утка тоткан чаклар йөрәк янында сиздереп тора. Бу юлы артиллерия бернәрсәне дә җимерми. Киресенчә, әлеге ату тавышы казанлыларны төзелешкә, эшкә – Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелү уңаеннан шимбә өмәсенә чакыра...

ТАССР оешу турындагы Декретны имзалау.

Автор:
Әскәр Сабиров

Дөресен әйткәндә, Казан губернасы башкарма комитеты хакимиятне рәсми рәвештә Татар республикасы Ревкомына тапшырырга тиешле көн җомгага туры килә. Ләкин әле кырып бетерелмәгән буржуйлар гына «субботник» буларак билгеле өмәнең, һичшиксез, шимбә көнне генә узарга тиешлеген расларга маташа ала. Яңаны төзүче революцион хезмәткә атнаның теләсә кайсы көнен багышлау да гөнаһ түгел! Казан губернасының башкарма комитеты рәисе Иосиф Ходоровский (френч, күн пальто, хром итекләр – барысы да үзендә!), бәлки, нәкъ әнә шулай, большевиклар рухында фикер йөрткәндер.

Кызганыч, әлегә яңаны кору, иҗат итү эше әллә ни уңышлы бармый. Патша хөкүмәтен – «явызлык дөньясы»н җимерү процессы барышында Казан бик тиз искерә һәм таушала. Гражданнар сугышы вакытында туктаган трамвайлар һаман йөреп китә алмый, күңелсез шәһәр читләре пычракка батып ята. Завод-фабрикаларның бер ише соңгы сулышын ала, башкалары бөтенләй эшләми. Хәтта берсеннән-берсе хөрмәтле кешеләр яшәгән, кайчандыр ялтырап торган, чиста-матур булган шәһәр үзәгендә, Дворяннар җыены бинасы тирәсендә, диварларга ябыштырып ясалган бизәкләр хәзер инде купкан, ишегалларында – тау-тау чүп өемнәре, көек, төтен исе – анысы бу вакыйгадан өч атна әүвәл янган шәһәр театры харәбәләреннән килә.

Яңаны төзеп булмый икән, димәк, өр-яңадан башлап китәр өчен, бераз җыештырып, тәртипләп куйганда, булганы да ярап куяр. Өмәдә катнашучылар театр мәйданында җыелалар һәм, бик дәртләнеп, янгыннан калган кисәү башларын җыештыралар. Корым катыш тир гимнастёркаларда һич юылмас эз калдыра. Ул арада кемдер зарланып, сүгенеп куя: «Бу кыяфәттә банкетка ничек барасың, ди?!»

Әлеге мәҗлескә җаваплы партия хезмәткәрләрен көтәләр. Революцион хакимият фикеренчә иң лаеклы саналган башка иптәшләрне дә. Ходоровский үзе кул куйган чакыру кәгазьләрендә болай диелгән: «25 июнь, җомга көнне, көндезге сәгать 3 тә, Кызыл Армиячеләр сараенда


В пятницу, 25 июня, в 3 ч. дня, в Красноармейском Дворце устраивается **банкет** по случаю объявления Автономной Татарской Соц. Советской Республики, на каковой банкет вы настоящим приглашаетесь.

Председатель Губисполкома Ходоровский.

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын игълан итү уңаеннан тантаналы мәҗлескә чакыру билеты. 1920 ел.

Фотолар ТАССРның 100 еллыгы сайтыннан (100.tatarstan.ru)



Сәхибгәрәй Сәетгалиев (1894–1939), ТАССР Халык Комиссарлары Советының беренче рәисе.

Татар республикасының Оештыру съездында катнашучылар. Казан, 1920 ел.

Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын игълан итү уңаеннан банкет оештырыла. Әлеге билет белән сез шул банкетка чакырыласыз».

Янгын урынын чистартучылар арасында бәйрәмгә чакырылганнары күп түгел. Өмә үзе дә бик тыйнак булды, дип әйтү хаклыкка якынрак. Соңыннан газеталар язганча, хезмәт бәйрәмендә 4161 кеше катнашкан. Бу исә халыкның өч проценттан да азрагы дигән сүз. Нигездә, болар Запастагы армия солдатлары, эшчеләр һәм хезмәткәрләр була. Үз ирекләре беләнме? Әлбәттә! Гарнизон, хезмәт комитеты башлыклары, губерна башкарма комитеты президиумы тарафыннан бастырылган кырыс фәрманнарны үтәп...

ДӨНЬЯ УЛ – ТЕАТР

Әлеге тарихи көндә тагын бер мөһим вакыйга исә каланың татарлар яшәгән өлешендә була. Мондагы Юнысов мәйданында Мулланур Вахитов һәйкәленә нигез салына. Әлеге мизгелнең ни дәрәҗәдә тантаналы булганын кызыл комачтагы гарәп хәрефләре белән татарча язылган лозунг та раслый: «Татар пролетариаты яшь республиканың чәчәк атуы өчен бар көчен куярга ант итә!» Шул ук сүзләр кириллица белән русча да кабатлана.

Татар милли театры нигезенә беренче ташны салу тантанасы тагын да зурлабрак уздырыла. Халык җыены каршындагы балконга тулы бер президиум чыга: иптәш Ходоровский, Сәхибгәрәй Сәетгалиев, Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты вәкиле, эчке эшләр буенча халык комиссары урынбасары Михаил Владимирский. Хәтта хөрмәтле чит ил кунагы да була. Сүз иптәш Фуад турында бара. Ул – төрек коммунистлар партиясе әгъзасы, баш күтәргән Кемаль паша хөкүмәте вәкиле. Революцион нотыклар яңгыраганмы? Әлбәттә!

– Шәһәр театры, Дворяннар җыены һәм башка шуның ишеләр безнең өчен ябык иде, – дип сөйли яхшы куелган яңгыравык тавышы белән актёр Камал (Габдулла Камалетдинов булса кирәк, тәхәллүсе Камал I. – Ред. иск.). – Андагы беренче рәтләрдә иң элек губернатор белән полицмейстер утыра иде. Республика безгә спектакльләребезне Казанның теләсә кайсы театрында куя гына түгел, үзебезнекен төзү мөмкинлеге дә бирә!

Оештыручыларның эшен билгеләп китик, чөнки митинг әллә ни озакка сузылмый. Көндезге бердә Иосиф Ходоровский театр мәйданында була инде. Тураеп басып, фуражкасына бармакларын тидереп ала– Казан гарнизоны гаскәрләре парадын сәламли. Беренче булып мәйданнан Казан хәрби курсларының кызыл командирлары һәм курсантлары уза. Алар артыннан, колонна-колонна булып, – пехота, артиллерия һәм кавалерия частьлары. Кырыслык, таләпчәнлек тә, матурлык һәм ышаныч та бар монда. Бер ай гына элек солдатлар бунты булмаган да диярсең, ул чагында ярымач хәлләренә канәгатьсез хәрбиләр, кулга корал тотып, урамнарга чыга...

«ЧЫНГА АШМАСТАЙ» ИДЕЯ ЯШӘСЕН!

Бәйрәмнең иң якты, иң биек ноктасы, әлбәттә, Сөембикә манарасы. Аны бүген кияү куенына керәсе комиссар кыз кебек бизиләр. Күккә ашкан өске яруста – РСФСРның бик зур гербы. Җиргә якынрак катта аршындай эре хәрефләр белән: «Бөтен илләрнең пролетарийлары, берләшегез! 1552-1920 ел. 25 июнь – татар хезмәт халкының үзбилгеләнү акты тормышка ашу көне. Яшәсен автономияле ТАССР! Яшәсен РСФСР!» – дип язып куелган. Манараның бар катларында да – байраклар, байраклар, байраклар. Әле Сөембикә манарасын кич электр уты белән яктырткач ни булыр... Бөтен Казанга бер-ике йөз лампочка, ә монда шундый зиннәтле байлык!

Манарадагы утлар Иосиф Ходоровский Кызыл Армиячеләр сараенда трибунага чыккан вакыттарак кабына. Монда хәзер иң төп вакыйга – хакимиятне тапшыру тантанасы узарга тиеш.

– Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын игълан иткән 27 май акты пролетар революциянең үсешендә бик зур роль уйнарга тиеш, – губерна башкарма комитеты рәисе үз чыгышын большевикларча башлап җибәрә. Һәм һичкем кире кага алмаслык тонда дәвам итә. – Совет хакимиятенең яңа республика игълан итүе гаять уйланылган һәм аңлы, һичкем тарафыннан мәҗбүриләп тагылмаган карары булып тора. Эшче-крестьян хакимиятенең Татар республикасын ике ел элегрәк игълан итмәве тышкы шартларның бөтен игътибарны саклану тарафына юнәлтергә мәҗбүр ителүе белән генә аңлатыла. Менә хәзер генә, бераз хәл алырга һәм көчләрнең бер өлешен эчке төзелешкә юнәл-

1920 елның 28 маенда РОСТА (Россия телеграф агентлыгы) дөньяга хәбәр сала: «Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты президиумы 27 майда кичке сәгать 7 дә үзәге Казан шәһәре булган Автономияле Татар Социалистик Совет Республикасы турында карарны раслады. Республика составына Казан губернасының көнчыгыш өлеше, Уфа губернасының Минзәлә өязе һәм Бөгелмә шәһәре белән бергә, Самара губернасы Бөгелмә өязенең күп өлеше керә».

тергә форсат табылгач кына, без татар хезмәтчәннәренә үзбилгеләнү мөмкинлеге бирә алдык!

Иптәш Ходоровскийның әчкерсезлеге һәм ныклы ышанычы Ревком белән губерна башкарма комитетының уртак утырышында катнашучыларның барысына да гипноз сыман тәэсир итә. Аңа аягүрә торып кул чабалар. Хәтта Иосиф Исаевичның әле күптән түгел генә Татар республикасын оештыру идеясенә нинди ирәк фикердә торганын белгән көрәштәшләре дә. (Соңрак үз истәлекләрендә Ходоровский таный булыр: «Татар республикасын оештыруга беренче әзерлек адымнары да ясамадык. Ул гына да түгел, без хәтта бу мәсьәләне чын-чынлап карамадык та, чөнки Татар республикасын оештыру безгә шулкадәр кирәксез, зарарлы һәм чынга ашмастай идея булып тоела иде».)

Иптәш Иосиф үз фикерен бер сәгать эчендә үзгәрткән дип сөйлиләр – Мәскәүгә, Ленин янына келәмгә чакырылу белән. Ни дисәк тә, партиядә большевиклык дисциплинасы – искиткеч үтемле көч. Һәм менә хәзер иптәш Ходоровский, хакимият вәкаләтләрен тапшыру турында актны бик ышаныч белән, мыскал да шикләнмичә укый.

– Шушы сәгатьтән хакимият Татар республикасы революцион комитетыныкы! –Тамашачыларның алкышларына күмелеп, Иосиф Ходоровский республиканың беренче җитәкчесе, Ревком рәисе Сәхибгәрәй Сәетгалиев белән пролетарларча кул бирешә.

– Татар республикасының хезмәт массалары исеменнән, – дип игълан итә Сәхибгәрәй Сәетгалиев, – аның барлык хезмәт ияләренең тулы фикерен чагылдырып, Россия Республикасы Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты тарафыннан вәкаләтләндерелгән Ревком шушы сәгатьтән башлап, Казан губерна башкарма комитетыннан яңа республика белән идарә итү вәкаләтләрен үзенә кабул итеп ала. Шушы мизгелдән Ревком үз вазыйфаларын үтәүгә керешә. Бу чынга ашты!

ЛАНДРИН ТӘМЕ ТОЕЛАЧАК КИЛӘЧӘК

Киләчәктә танылган рус шагыйрәсенә әвереләчәк Вероника Тушновага 1920 елда тугыз яшь тула. Зур популярлык яулаячак татар композиторы Сара Садыйковага – ундүрт яшь. Республика оешкан көнне алар икесе дә, башка Казан балалары кебек, революцион хакимияттән чын патшаларча бүләк – 1/8 фунт (илле граммнан бераз гына артыграк) ландрин ала. Тәме инде күптән онытылган татлы конфетны күргәч, әти-әниләрнең авыз сулары ага! 25 июнь республиканың яшь гражданнары өчен иң бәхетле көнгә әйләнә...

Татар республикасы оештырылу вакыйгасын халык ничек кабул иткән? Ул чактагы матбугат язмаларына ышансак – искиткеч энтузиазм белән. Менә «Хезмәт Байрагы» («Знамя Труда») газетасында Татар республикасын яклаган митингтан бер-берсенә игезәктәй охшаш ике мәкалә. Менә Казан дары заводы пролетарийлары республика булдыруны «Шәрыкта социалистик идеяләрне тарату чарасы, күп миллионлаган мөселман гавамының уянуына этәргеч» сыйфатында сәламли. Республика оештыруны хуплаулары хакында Бертуган Крестовниковлар заводы эшчеләре дә белдерү ясый. Һәм телеграммалар, телеграммалар... – республика исеменә котлауларны Минзәлә өязеннән, Арча, Мамадыш, Тәтештән яудыралар....

Асылда исә, мөгаен, барысы да җай гына бармагандыр. Бөтен халык бер мизгелдә һәм һич каршылыксыз ышаныч белдерсен өчен кулай вакыт түгел – республикадагы хәл артык киеренке һәм катлаулы. Чит ил интервенциясе, шпионнар һәм саботажникларның эчтән шартлату куркынычы аркасында, «16 майдан бөтен Казан губернасында хәрби хәл режимы кертелә, ә Аракчино заводы һәм дары заводы тирәләре камаулы хәлдә дип игълан ителә», – дип хәбәр итә «Хезмәт Байрагы» газетасы. Шәһәрдә хәрби коммунизмның барлык «шәп» яклары күзгә ташлана: ачлы-туклы тормыш, азык-төлеккә карточка системасы, кибетләрдә исә җил уйный. Авылларда хәлләр бөтенләй мөшкел: продотрядлар крестьяннарның бөтен ашлыгын, хәтта чәчүлек орлыкны да кырып-себереп тартып ала. Киреләнеп торудан файда юк: әле кайчан гына булган «сәнәк фетнәсенең»нең аяныч нәтиҗәләрен һәркем хәтерли. Ул чакта Минзәлә, Чистай, Бөгелмә өязләрендә продразвёрсткага каршы күтәрелергә җөрьәт иткән крестьяннарны гаскәр җибәреп бастыралар.

Казанда Татар республикасына каршы хәтта ачыктан-ачык каршы чыгучылар да табыла. Дөрес, 25 июньдә уздырылган карагруһчылар демонстрациясе әллә ни күп санлы булмый. Әмма шунысы мәгълүм: тиздән шәһәрдә янгыннар дөрли – 243 йорт көлгә әйләнә...

Мәскәү тарафыннан билгеләнгән вәкаләтләргә ия автономияле Татар республикасын бу хәлдә оештыру татар зыялылары һәм милли хәрәкәт башлыкларында да сораулар уята. Өстәвенә, әүвәлрәк большевиклар Идел-Урал Штаты, ә соңрак Татар-Башкорт республикасын оештыру идеясен бик уңышлы юк итә. Икенче яктан, белемле татар халкының зур өлеше аңлый: Татар республикасы дүрт йөз елга якын элек югалтылган дәүләтчелекне кире кайтаруга бер адым булып тора.

Хәер, татар зыялыларының фикеренә колак салырга мөмкиннәр, ләкин шуннан ары түгел. Урамда – пролетариат диктатурасы, дөресрәге, өч ел элек илдә хакимиятне яулап алган партия диктатурасы. Һәм милләтләрнең үзбилгеләнү хокукы турында Ленин шигарен никадәр гадел тормышка ашырачагын бары тик партия үзе генә хәл итә.

100.tatarstan.ru сайтында тагын да күбрәк материаллар таба аласыз

НЭП ЧОРЫ: СОҢГЫ ТАЛПЫНЫШ

Казан. Егерменче еллар башы. Әнә, Гостиный дворның ерак бер почмагында, башка чүп-чарлар арасында, азатлык бүләк иткән Александрның бронза фигурасы тузанга батып ята. Аның урынында, Кремль каршындагы мәрмәр «Александр постаментында», – ирекле хезмәтне гәүдәләндерүче таза беләкле эшче һәйкәле. Тик гасырларга дип куелган гипс эшченең хәле генә мөшкел: ул күзгә күренеп таралып бара...

Автор:
Әскәр Сабиров

– Хәерлегә түгел, – дип пышылдаша хорафатларга ышанучы кешеләр. – Чит постаментка куярга ярамый иде, гөнаһ бит ул...

Ә менә гади коммунистлар хорафатларга колак салмый. Тик аларның да, кайберләренең, билгеле, башларында – боламык. Гипсның судан һәм температура сикерешләреннән җимерелгәнен белеп торалар, югыйсә, әмма һәр начарлыкта нэпманнарны гаепләргә атлыгып торалар. Пролетариат республикасында ниндидер кирәкмәгән эшләр кылына, дип исәплиләр. Әлмәтов һәм Үтәшевның Казандагы сабын кайнату заводларын элеккеге хуҗаларына арендага биргәннәр, мамык фабрикасын – шулай ук. Нәрсә өчен көрәштеләр? Ә яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләр сыман ачыла торган вак фабрикалар, артельләр, кибетләр? Юкса болар барысы да шәхси затлар, эшче халыкны эксплуатацияләүчеләр ләбаса!!!

ХАЛЫККА – ПОРНОГРАФИЯ БӘЙЛӘМЕ

Хуҗалар үз предприятиеләрендә үзләре теләгәнчә эшли. Хуҗалар икмәк пешерә. Хуҗалар сата. Һәм оятсызларча, пролетарларга хас булмаганча, һәркайда үз көен көйләп, акча туздыра. Хәтта «Известия ТатЦИК» газетасының театр тәнкыйтьчесе дә коммунистларча үртәлүен яшереп кала алмый: «Казанда әле беркайчан да театрларның быелгы кебек күп булганы юк иде. Бөтен җирдә спектакльләр куялар. Әмма ниндиләрне бит? Арада заман рухына җавап бирүче пьеса исемнәре сирәк күзгә чалына. Октябрь көннәрендә, мәсәлән, Зур театр «Сполошный зык»ны, татар театры исә «Җирсезләр»не куйды, тик болары да бары тик Октябрь уңаеннан гына. Аңа кадәр һәм аннан соң куелганнар арасында менә ниләр бар: «Язгы ташкын», Арцыбашевның «Көнләшү»е һәм порнография тирәсендә әвәрә килүче башка чүп-чар...»

Гади большевиклар өчен нэпманнарның канкан биюе мыскыл итү кебек тоела. Ә бит социализм теләгәннәр иде, менә сиңа – шалкан мае... Партия җитәкчеләре җитди киеренкелектә: көне-төне кайнап чыгар дәрәҗәгә җитеп кызган башларын суыталар. Кабинетларда, кызыл почмакларда, җыелышларда бертуктаусыз ятланган җөмләләрен кабатлыйлар: НЭП – яңа икътисадый сәясәт. Бурычы – бөлгенлек-фәкыйрьлекне һәм ачлыкны җиңү. Шуның өчен продразвёрстка азык-төлек салымы белән алыштырыла – крестьяннарның бөтен ашлыгын кырыпсебереп алмыйча, чәчәргә һәм яшәргә (ашарга) калдырырга. Шуның өчен, элеккеге хуҗаларына булса да, предприятие һәм фабрикаларны арендага бирергә; Гражданнар сугышыннан бирле таланган һәм җимерелгән цехларны үз акчаларына кабат торгызсыннар. Шуның өчен дәүләт предприятиеләрендә хуҗалык исәп-хисабы, вак шәхси эшмәкәр өчен тулы ирек һәм сәүдә итү хокукы – барысын тигезләүдән һәм карточкалардан китү, товар-акча мөнәсәбәтләрен кабат торгызу өчен...

«СТЕНЬКА РАЗИН» ҖИЛКӘСЕ АША КАРАСАҢ...

– Димәк, кабат артка, капитализмга? Бәлки, ул чакта Крестовниковларны, Алафузовларны, Стахеевны кире кайтарырбыз, кабат аларга бил бөгәрбез? – дип, мыскыллы сорау бирә әзерлекле бер пролетарий.

– Ә менә анысына юл куймабыз! – дип, йодрыгы белән өстәлгә китереп ора партия җитәкчесе. – Эре предприятиеләрне беркем дә революция дошманнарына бирмәячәк, аның өчен кан түкмәдек...

Һәм чыннан да Крестовниковларның сабын кайнату һәм шәм заводы, Паратск остаханәләре, дары заводы, Бондюг химия заводы һәм ул заманның башка сәнәгать гигантлары тора-бара дәүләт кулына күчә, трестларга берләшә... Яңа хакимияткә, социализм идеяләренә тугрылыгын киң күләмле идеологик акция дә расларга тиеш була: фабрика һәм завод исемнәреннән аларның элеккеге хуҗаларының фамилияләре юкка чыгарыла. «Күнчеләр союзы идарәсе Кожтрестка кертелгән һәм арендага тапшырылган дәүләт предприятиеләренең исемнәрен алыштыру кампаниясен төгәлләде, – дип хәбәр итә халыкка газета. – Предприятиеләргә түбәндәге исемнәр бирелде: Алафузовлар заводына – Ленин исеме, «Поляр» фабрикасы хәзер «Спартак» дип йөртелә, Глинкинныкы – «Пугачёв», Шабановныкы – «Стенька Разин», Готлицерныкы – «Коммунист», Наумовныкы – «Освобождение труда», Сәлимҗановныкы – «Кызыл күнче». Шулай ук Крестовниковлар заводы да башка юк – Вахитов исемендәге завод кына бар.

Әмма ач карынга идеяләр начар эшкәртелә. Татар республикасында НЭП башланган вакытка хәлләр коточкыч авыр була. Сәнәгать предприятиеләренең 83 проценты тулысынча җимерек яки Гражданнар сугышыннан бирле яраксыз хәлгә килгән килеш тора. Сугышка кадәрге вакыт белән чагыштырганда, җитештерү күләме биш тапкырга кыскарган. Өстәвенә, коточкыч корылык булу сәбәпле, уңыш уңмаган 1921 елда ачлыктан һәм тифтан 218 меңнән артык кеше үлгән һәм бөтен мал-туар да диярлек суеп бетерелгән – боларын инде беләбез...

БЕРТУГАН ЖИГАЛОВЛАРДАН – КАПИТАЛИЗМ

Һәм менә Казанның нибары дүрт елдан соңгы хәле. Богоявленская чаң манарасы янәшәсендәге мәйдан хәзер Балык рәтләре дип аталмый, ул – Кооператив урамы! Әмма монда кооператорлар хуҗа түгел. Шәхси почмакларда, сәүдә киштәләрендә, ваклап сатучыларда – җаның теләгән һәр нәрсә бар. Такта чәй кирәкме – рәхим итегез! Тозлы балыкмы – алыгыз гына! Тәмәке, ситсы, крендельме? Теләгән кадәр алыгыз! Карагыз тагын – шикәр ватарга килешчәләр, «Красный Октябрь» артеленнән трюмо, «Курдим»нан папирослар, Казанның «Кроль» фабрикасыннан мехлар да бар. Чын тормыш тантанасы!

Һәм бу тантананың төп хуҗалары – шәхси эшмәкәрләр. Шәхси сәүдә әйләнеше республика башкаласында да, кантоннарда да әле ике ел элек кенә дәүләт һәм кооператив сәүдәсе әйләнешеннән күпкә артыграк булган. Инде 1923 елда ук Татарстанда 15 меңнән артык һөнәрче эшләгән. 1927 елга аларның саны 57 меңнән артып киткән. Республикадагы барлык сәнәгать продукциясенең кырык процентына якын өлешен планнардан һәм идарә итүчеләрдән азат, әмма булдыклы һәм тырыш шушы кешеләр җитештергән!

Шәхси эшмәкәрләр, күрәсең, бар фронтларда җиңәргә сәләтле. Аларга арендага вак предприятиеләрне генә тапшыралар, эрерәкләрен – әллә нигә бер. Әмма аларның заводларында, кагыйдә буларак, җитештерүчәнлек югарырак. Ике күн эшкәртү заводын арендага алган бертуган Жигаловлар Таткожтресттагы дәүләти көндәшләреннән ачыктан-ачык көлә: нэпманнар ике тапкыр артыграк җитештерә, сыйфаты да – чагыштыра торган түгел. Большевиклар рөхсәте белән үзләренең элеккеге предприятиеләрен арендага алган Якобсон һәм Готлицерда да – шул ук тенденция. Нэпманнар Даутов, Латыйпов, Сәйдәшевта да – шулай.

Шәхси эшмәкәрләргә ташламалар каралганмы әллә? Каралган, ди! Бертуган Жигаловлар, Якобсон һәм Готлицерлар белән арендага күн, сабын кайнату заводларын, тәмәке фабрикасын, «Труд» типографиясен, кирпеч заводын һәм бүтән предприятиеләрне алган башка шундый ук нэпманнар да кырыс килешүләргә кул куя. Беренчедән, юкка чыгарылган җитештерүне сафка бастырыр өчен алдан ук шактый акча кертергә тиеш булалар. Икенчедән, аренда өчен тиешле вакытта түләргә. Өченчедән, продукциянең 20 процентына кадәрен дәүләткә тапшырырга. Кайберләре, килешү буенча, станок-

ларны һәм җиһазларны да яңартырга, егәрлекләрне дә үстерергә тиеш була. Үзләренә киләчәк өченме? Тик килешү срогы – биш елдан да артык түгел бит.

– Ә аннары нәрсә? – дип сорагандыр нэпман арендага бирүчедән.

– Аннарымы? ГПУ (Дәүләт сәяси идарәсе) карар чыгарыр, – дип җавап бирәчәк эченнән генә партияле идарәче. Ягымлы йөзеннән елмаю да балкып китәдер әле, җитмәсә.

1925–1926 елларда арендаланган сигез күн заводы гына да республикага 575 мең вак күн җитештереп бирә. Таткожтрестның барлык заводлары исә – 300 меңгә якынны.

Йә, мондый хәлдә дөнья революциясе идеяләрен ничек тормышка ашырып була, ди?!

«ХУҖАЛЫГЫН ҮСТЕРГӘН ҺӘМ МИЛЕКЧЕЛЕК ЯГЫНА ТАЙПЫЛГАН ӨЧЕН»

Татарстанда НЭП чорының документаль шаһадәтнамәсе – «Коммунистический путь» журналы. 1924 елның октябрь санында БКК (Берләшкән контроль комиссиясе) партколлегиясе тарафыннан партия әгъзалыгыннан чыгарылганнарның исемлеге китерелгән. Иң гаҗәбе – «Ни өчен чыгарылган» графасы. Әйтик, элеккеге иптәшләрнең берсе большевиклар сафыннан «хуҗалыгын үстергән һәм милекчелеккә тайпылган өчен» чыгарылган. Вакыт тагын бер кызыклы документны – уртакул партия хезмәткәре чыгышын саклап калган: «Тормышының бар яклап яхшыруы, шәхси мәнфәгатьләр, матди ягы турында чиксез кайгырту – кайбер сабырсыз иптәшләрне шәхси хуҗалык булдыруга, йортлар, атлар һәм пролетар революция шартларында коммунистка тиеш һәм хас булмаган башка әйберләр сатып алуга китерде. Шуңа бәйле рәвештә кайбер партия әгъзаларының аерымланулары һәм йомылуларын билгеләп үтәргә туры килә, алар, билгеләнгән вакытны эшләгәннән соң, үзләренең шәхси, гаилә мәнфәгатьләренә тиеш булганнан күпкә артыграк игътибар бирә башладылар».

«Җиңел» акчалар – нэпманнарда, ә менә алар өчен тир түгүчеләрдә – яхшы хезмәт хаклары. Боларга пролетариатның тотрыксыз өлешенең башын әйләндерергә сәләтле буржуаз күңел ачуларны да өстәсәк... Билгеле инде, партия хәтта үзенчәлекле НЭП шартларында да пролетариатта сыйнфый нәфрәт хисе томалануына һәм шәхси милекчелеккә мәхәббәт уянуына юл куя алмый. Хезмәт халкының дошманнары, хәтта алар илнең икътисадын тирән баздан өстерәп чыгаручылар булсалар да, дошман булудан туктамый. Димәк, большевистик идеяләрне пропагандалауны көчәйтү зарур, акыллы һәм көндәлек агитация таләп ителә.

Партия журналы бу эштә алыштыргысыз роль уйный. Татреспубликада 1920 елның 1 декабрендә үк «Вестник област-кома РКП ТССР» дөнья күрә («Татарстан» журналының тарихы әнә шуннан башлана да инде. – Ред. иск.), аның оештыручысы һәм беренче редакторы партия өлкә комитетының беренче секретаре Александр Таняев була. 1921 елның сентябреннән журнал – «Спутник агитатора», ә тагын ике айдан соң «Коммунистический путь» дип атала башлый. Татреспублика РКП (б) өлкә комитетының һәм Главполитпросветының әлеге басма органы НЭПның чәчәк аткан чорында чыга...

БЕЗНЕҢ ЗАМАННЫКЫ БУЛМАГАН ГЕРОЙЛАР

Әмма, эш белән ныгытылмаса, хәтта партия сүзе дә капиталсыз банкирга тиң. Шәхси эшмәкәр белән сәламәт булмаган көндәшлектә дәүләт чигенергә җыенмый. Шул чорның газетасындагы язмадан өземтә: «Икътисадый көрәшкә... бер генә эшче һәм крестьян да битараф карарга һәм читтә торырга тиеш түгел», – дип язып, массаларда ярыш дәртен кыздыралар.

Ярыш дәрте, чыннан да, уяна. Дәүләтнеке булган Бондюг химия заводында, Вахитов исемендәге заводта, «Победа труда» Васильево пыяла заводында, Паратск остаханәләрендә – шулай ук хезмәт җитештерүчәнлеге үсә. Бондюг химия заводы илнең иң эре һәм алдынгы предприятиеләреннән берсенә әверелә – ул СССРның барлык химия продукциясенең өчтән берен бирә. Дәүләт предприятиеләрендә барысын тигезләү юк диярлек, биредә акча өчен генә түгел – идея өчен дә эшлиләр.

Республикада электр станцияләре төзелә (Ленинның ГОЭЛРО планы буенча), димәк, гамәлдәге егәрлекләрне үстерү, яңа предприятиеләр төзү мөмкинлеге дә барлыкка килә. Большевикларның эксклюзив коралы – мораль яктан күтәрү системасы эшли башлый. Иң яхшы эшчеләр хәзер Хезмәт Герое исемен ала. Беренчеләрдән булып – дәүләт заводы коючысы Владимир Бобров, бастыручы Ибәтулла Гыйззәтуллин, электр станциясе машинисты Георгий Герасимов... 1920–1926 елларда бу исем 550 эшчегә бирелә.

Партия илдә хәзер тормышның чын хуҗасы кем булуын һәрвакыт сиздерми генә искәртеп тора.

МАВР ҮЗ ЭШЕН ЭШЛӘДЕ...

Казан, 1927 ел. Шәһәрне хәзер танып булмый. Урамнар буйлап, революциягә кадәргечә, трамвайлар теркелдәп үтә. Вагоннар Суконкадан – Устьега, Академическаядан Вахитов исемендәге заводка кадәр йөри... Заречьега, Восстание бистәсенә автобуслар җибәрелгән. Авыр «фиатлар» атларны өркетә – элек шәһәрдә бер дә автобус булмаган бит. Ә Түбән Кабанда яңа электр станциясенең кызыл кирпеч бинасы калкып чыга – электрлаштыруның беренче карлыгачы, шәһәрнең горурлыгы. Хәзер хәтта шәһәрнең эшчеләр яшәгән читләрендә дә – керосин төтәткечләр генә түгел, ә чын Ильич уты. Казанда гынамы – Яшел Үзән янындагы Норлат авылының да үз электр станциясе бар...

1925 елга Татарстанның сәнәгать җитештерүе күләме сугышка кадәргенең җитмеш процентына җитсә, 1927 елда аны сизелерлек узып китә. НЭП һәм шәхси капитал үз эшен эшли – җимерелгән икътисад торгызыла, ил халкының тамагы туя. Күптән түгел ачлыктан авыллап-авыллап кешеләрен югалткан Россия 1927 елда чит илләргә өч миллион тонна икмәк сата. Ә аннан соң нәрсә, диясезме? Аннан соң, иптәш Сталин оятсыз рәвештә игълан иткәнчә, яңа икътисадый сәясәт «шайтанга олактырыла». Инде кирәге калмаганга күрә. Татреспубликада яңа җиңүләрне кулны чигәгә куеп сәламләрлек вазгыять урнаша лабаса: әле 1927 елда ук дәүләт файдасына 30 шәхси һәм арендаланган күн заводы конфискацияләнгән иде. 1929 елга сәүдәдәге шәхси сектор инде 29 процента кими, ә сәнәгатьтә – алты процентка. Бер елдан ул бөтенләй юкка чыгарыла. Сәламәт көндәшлеккә шуның белән чик куела.

Нэпманнармы? Аларның эшен, әлбәттә, әлеге дә баягы ГПУ карагандыр. Нишлисең, алар истәлекләрен яңа буыннарга калдырмаган диярлек.

ТӘМУГКА ТИҢ ИКЕ ЕЛ

Автор: Ксения Сёмина



Корбаннар күләме буенча Россиянең Гражданнар сугышындагы югалтуларына тәңгәл һәлакәт Идел буе, Урал, Казахстан, Көнбатыш Себер, Көньяк Украина территорияләрен колачлый. 1921 елда башланган ачлык санаулы айлар эчендә берничә миллион кешенең гомерен өзә. Республика бәла-казаның нәкъ үзәгендә кала.

СОҢАРГАН ЯРДӘМ

1921 елның яз азагында ук күп кенә волостьларда, шул исәптән ТАССРның шактый кантоннарында, ашарга икмәк калмый. Ашлык, орлык запасларын продразверстка отрядлары кырып-себереп җыеп китә, еш кына кирәгеннән артыгын да тартып ала. «Иртә яздан хәзергә кадәр бер тапкыр да яңгыр яумавы һәм июньдәге эсселек уҗымнарны да, сабан ашлыгын да, шулай ук бакчалардагы яшелчәләрне дә тулысынча көйдереп бетерде… – дип яза 1921 елның июль уртасында Чистай кантоны Ерыклы волосте башкарма комитеты рәисе үзенең докладында. – Ач халык инде күптәннән төрле суррогатлар белән туклана… һәм, киләчәктәге коточкыч хәлләрдән куркып, кая булса да китү ягын кайгырта… Инде хәзер үк Югары Никиткино авылында гына да 28 июньнән 3 июльгә кадәр алты кешенең ачтан үлүе һәм ачлык китереп чыгарган 289 авыру очрагы теркәлде… Ап-ак ябык чырайлы күләгәләрдәй кешеләр үлемгә хөкем ителгәннәрне хәтерләтә…»

1921 елның 18 июлендә Ачларга ярдәм күрсәтү үзәк комиссиясе (ЦК Помгол) төзелә, берничә көннән соң мондый комиссия ТАССРда да оештырыла. Ачлык котырынган төбәкләр корылыктан зыян күрмәгән республикаларга беркетелә. Татарстанны Вологда, Владимир һәм Петроград губерналары тәэмин итәргә тиеш була. Язучы Максим Горький Европа һәм Америка илләре җитәкчеләренә Россиядәге ачларга булышуларын сорап мөрәҗәгать итә. Дөньяның фән һәм иҗат җәмәгатьчелеге вәкилләре Советлар иленә ярдәм күрсәтүчеләр сафын тулыландыра. Алар арасында Альберт Эйнштейн, Анатоль Франс, Бернард Шоу исемнәре бар. Төньякны өйрәнүче танылган тикшеренүче Фритьоф Нансен ачларга ярдәм күрсәтү буенча гомумевропа оешмасын җитәкли. Идел буйлап барып, ул балалар йортларында, хастаханәләрдә, үләргә җиткән авылларда була. Милләтләр Лигасына мөрәҗәгате игътибарсыз калдырылгач, Совет Республикасына Нансен үзе зур суммада акча бирә.

Ачлык хөкем сөргән башка районнардагы кебек үк, 1921 елның көзенә ТАССРда Американың ачларга ярдәм күрсәтү администрациясе, берничә халыкара оешманы берләштергән Нансен миссиясе, Халыкара эшчеләр комитеты, Халыкара балаларга ярдәм күрсәтү берлеге һәм башка комитетлар эшли башлый. Әмма бу ярдәм генә җитми…

ҮЛЕМГӘ ХӨКЕМ ИТЕЛГӘН ТЕРЕЛӘР

1921 елның декабрендә Татреспубликаның 12 кантонын карап кайткан тикшерүче үзенең «Азык-төлек һәм санитария шартлары турында доклады»нда түбәндәгеләрне хәбәр итә: «Язын республикада, Казанны да кертеп, 3 366 719 кеше яшәгән. Хәзерге вакытта әлеге сан якынча 2 892 200 кешегә тәңгәл. Кимү 14 процентны тәшкил итә…» Докладчы фикеренчә, халыкның нибары 12 проценты гына кышны чыгачак, 2,3 миллионга якын кеше ачлыктан һәм авырулардан үләргә хөкем ителгән.

«Иделнең көнбатыш ярындагы Зөя, Буа, Тәтеш кантоннары ачлыктан бигрәк тә нык зыян күрә… Анда хәл шулкадәр авыр ки, Америка администрациясе һәм Помгол күрсәткән ярдәм генә, шартлар бераз яхшырак булган кантоннардагы кебек, хәтта вакытлыча да җиңеллек китерә алмый… Тиф, бигрәк тә тимгелле тиф, Лаеш һәм Спастан кала, барлык кантоннарда да бик тиз тарала. Күрәсең, Лаеш районында ул басылгандыр, Спаста исә бөтен кеше диярлек аның белән чирләп чыккан инде. Буа кантонында тимгелле тиф аена 300 процентка кадәр арта, күп авылларда халыкның яртысы аны йоктырган инде. Тәтеш турында да шуны ук әйтергә була. Арчада тифның таралышы 400 процентка кадәр җитә, – дип дәвам итә докладчы. – Барлык территориянең 90 процентын үтеп, мин бер генә кисәк булса да ипи яки ат итеннән башка бүтән ит күрмәдем. Күп урыннарда хәтта төп суррогат булган алабутаның да поты 120–150 000 сумга җитә».

«Татреспубликаның 13 кантонында халыкның 85 проценты ачлыктан интегә. Бары 463 755 кеше генә тук була. Калганнары алабута, сөяк оны, балчык һәм башка төр суррогат ашый. Мәче, эт, күсе һ.б.ларның үләксәләрен ашау – гадәти күренеш», – дип яза Помгол рәисе Вознесенский 1921 елның мартындагы докладында. Декабрьдә исә, кешеләкнең иң соң чигенә җиткән адәмнәр, инде хайван үләксәләре белән генә түгел, ә кеше мәетләре белән дә туклана башлый, кайчагында хәтта тере кешеләрне дә ашаудан тайчанмыйлар…

Ачлык белән көрәшү өчен ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты тарафыннан «Ачлык белән көрәшүчегә» дигән күкрәк билгесе булдырыла, аңа грамота да өстәп бирелә. «Көрәшче»ләргә һәртөрле таныклыклар белән бүләкләр дә каралган була. Әлеге күкрәк билгесе асылда орден дәрәҗәсенә ия булган.

КЕШЕГӘ ХАС БУЛМАГАН ФАҖИГА

Ач балаларга ярдәм итү Рус-Америка комитетының Спас кантоны әгъзасы иптәш Бариновның «Әти-әнисе ашаган 7 яшьлек малай мәетен тикшерү мәсьәләсе буенча» хәбәреннән:

«Беренче булып гаепләнүченең каенатасы Монаховтан сорау алынды. Ул 7 яшьлек оныгы – Малов Феофил Степан улының ачлыктан интегүе, зәгыйфьләнүе һәм 1 гыйнвар иртәсендә үлүен раслады:

– Минем Феофилны җирләргә кирәк дигән тәкъдимемә Малов улының мәетен ашарга җыенуын әйтте. Мин, әлбәттә, моңа ышанмадым һәм чиркәүгә киттем, анда руханига Маловның ниятен җиткердем... Чиркәүдән кайткач, мәетнең башы, кул-аяклары булмавын күрдем. Минем: «Кая куйдыгыз?» дигән соравыма, Малов, без хатыным белән аларны пешереп ашадык инде, диде...»

«Татреспубликаның Спас кантоны халкына кичекмәстән ашыгыч ярдәм һәм Үзәктән азык-төлек кирәк. Әгәр ашыгыч ярдәм күрсәтелмәсә, кеше ашау очраклары артачак, үлем-китем турында исә сөйләп торасы да юк инде, Спас кантонына Үзәк алдында чаң сугарга кирәк, дип саныйм...» – дип нәтиҗә ясый Баринов.

Күп кенә башка кантоннарда да мондый куркыныч хәлләр булып тора. Бу турыда мәгълүмат ТАССР Үзәк Башкарма Комитеты каршындагы Ачларга ярдәм күрсәтү үзәк комиссиясенең архив папкасында саклана.

«Февральдән (1921 ел – ред.иск.) 5нче номерлы хәбәр: Сәпәй волосте башкарма комитеты 10 февральдә хәбәр итүенчә, Азнакай авылында гражданин Фәбрулла Фарукин үзенең өч айлык улын суеп ашаган, тикшерү бара».

Югары Байлар авыл советы рәисе Садыйковтан хәбәр: «1922 елның 28 гыйнварында Югары Байлар авылында гражданка Шәмсениса Сәхабиеваның кызы Рәхилә ачлыктан үлгәч, ач ана кызының күкрәк читлеге һәм корсагын ярып, бөтен эчке әгъзаларын казанда пешереп ашаган, аннары үзе дә үлгән. Моны аның балалары – 11 яшьлек Фәридәбану белән 8 яшьлек Әхмәтгариф карап торган. Әлеге мәетләрне тикшерү өчен, Югары Байлар авыл советының Күзкәй фельдшерлык пунктыннан табиб яки фельдшер чакыртуын сорыйбыз...»

Чистай, Кантон башкарма комитеты, телеграмма: «Күтәмәдә 3 кешене ашауларын хәбәр итәбез җинаять ачыкланган Башкарма комитет рәисе урынбасары Якупов».

ТОРМЫШ ТИГЕЗЛӘМӘСЕ

«Известия ЦК РКП(б)» газетасының 1921–1922 еллар архивыннан: «Иделдә ачлык куәтләнә, 13 миллионлап кеше – республика халкының уннан бер өлеше ачлыктан интегә... Хәзерге вакытка кадәр бик аз яки очраклы гына ярдәм күрсәтелә, анда әле хосусый хәйриячелек формалары өстенлек итә, азык-төлек ярдәме акча ярдәменнән шактый калыша һәм халыкның реаль ресурсларына бөтенләй туры килми... Партиянең төп өндәмәсе – «Ун тук кеше бер ачны ашата» – бернигә дә карамастан үтәлергә тиеш. «Партия түбәндәге бурычларны үтәүне тәэмин итәргә тиеш: һәр эшче үз ихтыяры белән аена 3 фунт акчасын биреп барсын; һәр утыз эшче һәм хезмәткәр бер баланы уллыкка алсын; һәр крестьян ач кешегә ай саен, кимендә, 3 фунт икмәк бирсен; һәр ун йорт бер баланы асрамага алсын... Ачлыкны киметүдә авылның өлеше күбрәк булырга тиеш. Әмма крестьяннар ачларга ярдәм эшенә хәзергә кадәр тиешле дәрәҗәдә тартылмаган...», – дип белдерә 1922 елның февраль азагында РКП(б) ҮК секретаре Вячеслав Молотов.

Балалар Казандагы Америка комитетыннан ашау белән тәэмин ителә, 1921–1922 еллар.

Бу чорда ТАССРда балалар өчен паек нормасы аена 7,5 фунт (3,4 кг) он һәм 15 фунт (6,7 кг) бәрәңге, олылар өчен 3,75 фунт (1,7 кг) он һәм 15 фунт бәрәңге тәшкил итә. Әмма, шул исәптән ТАССРга да, 1921 елның көзендә 3 миллион пот ашлык, 1922 елда 5 миллион пот чамасы орлык җибәргән шеф губерналарның ярдәме нәтиҗәсендә, көзге чәчү кампаниясе уңышлы үткәрелә. Бу һәлакәт масштабларының кими башлавына өмет уята...

Әмма әле 1922 ел азагында да җитди вазгыять саклана. «Статистика идарәсе 1922 елда ашлыкның тулаем уңышы (ашлыкка әйләндереп өстәлгән бәрәңге белән бергә) 32 775 297 потка җиткән, дип исәпли. Халык әлеге микъдардан 5 000 000 потын уҗым чәчүгә, 3 500 000 потын азык-төлек салымы (!) түләүгә, тулаем алганда, барлыгы 8 500 000 пот тоткан. Санап чыгарсак, 24 275 297 пот кала. Азык-төлек халык комиссариаты нормаларыннан чыгып, халыкның азык-төлеккә ихтыяҗы җан башына 12 поттан дип исәпләгәндә, Татреспубликада яшәүче 2 677 283 кешегә 32 127 396 пот таләп ителә. Ягъни 7 852 099 пот җитешми, һәм сабан орлыгына бернәрсә дә калмый. Халык, куллануны киметеп, норманы җан башына 7,5 потка гына калдырса, язгы чәчү өчен орлыкны экономияләп була. Әмма бу чара да 4 200 000 поттан артыграк орлык бирә алмый...», – дип яза ТАССРның беренче игенчелек халык комиссары Юныс Вәлидов.

Икмәк, халык нормасы, шулай ук профсоюзлар, армия, авыл һәм ирекле оешмалар күрсәтә торган ярдәм күләме нормаларын үз эченә алган башка тигезләмәләр, гаять күп көч түгеп булса да, нәтиҗәдә чишелә. Әмма ТАССРда халык саны 1926 елда гына «революциягә кадәрге дәрәҗәсенә» җитә – ул чактагы җанисәп республикада 3 369 000 кеше яшәвен күрсәтә...

ЯҢА РЕСПУБЛИКАГА – ЯҢА ТЕАТР

1922 ел. Мәгариф халык комиссариаты Кызыл Октябрь исемендәге Беренче дәүләт үрнәк драма татар театры булдыру турында карар кабул итә. Яңа оешкан ТАССР өчен бу олы мәдәни вакыйгага була. Татар мәдәнияте өчен яңа дәвер башланган чор.

Автор:
Ольга Туманская

ТЕРЕ ТАРИХ

...Рояль артында – Салих Сәйдәшев. Аны кабинетка бикләгәннәр! Никадәр генә ялынса да, үгетләсә дә, хезмәттәшләренең күңеле йомшармый – композиторны чыгармыйлар. Тинчуринның «Кандыр буе» музыкаль драмасына вәгъдә иткән партитурасын язмый торып чыгармаячаклар да. Кемнеңдер кинәт сак кына итеп: «Салих абый!» – дип дәшкәне ишетелә. Ишек артында актриса Сара Садыйкова тора, аңа диган ария әзер түгелме икән, дип белешергә килүе. «Үзең яз!» – дип ачу белән җавап кайтара талчыккан Сәйдәшев. Ә иртәнгә инде ноталар язылган кәгазь битен ала. Уйнап карый да ишек аша гына: «Карале, начар түгел бит!» – дип кычкыра.

Әлеге сюжет татар театрының 110 еллыгына багышланган «Дәрсе гыйбрәттер театр» спектакленең бер өлеше булып киткән, чөнки беренче татар профессиональ труппасы совет республикасына кадәр күпкә элгәре – 1907 елда ук барлыкка килгән. Спектакльнең идеясе Галиәсгар Камал исемендәге театрның баш режиссеры Фәрит Бикчәнтәевнеке. Текстны яшь шагыйрь һәм драматург Рүзәл Мөхәммәтшин язган. Әдәби бүлек мөдире, театр тәнкыйтьчесе, шулай ук татар театры тарихы белгече Нияз Игламов автордаш булган. Без аның белән узган гасырның илһамлы 20нче елларында һәм дәһшәтле 30 елларында булган вакыйгаларны искә төшерү өчен махсус очраштык.

Сүз уңаеннан, Сәйдәшев белән булган әлеге кызыклы вакыйганың чынбарлыкка туры килүе дә бик ихтимал, чөнки Гөлйөзем ариясе – Садыйкованың композитор буларак дебюты. Үз гомерендә ул берничә йөз җыр һәм 18 спектакльгә музыка язачак. Безгә исә әлеге тарих яңа барлыкка килгән республиканың милли театры пионерлары булган кешеләрнең иҗади масштабын күзалларга мөмкинлек бирә.

– Ул елларда татар театр сәнгатенең төп фигурасы, һичшиксез, Кәрим Тинчурин булган, – дип сөйли **Нияз Игламов.** – Театрга җитәкчелек итәргә нәкъ менә аны чакыралар. Үзенең абруеннан файдаланып, Тинчурин Казанга революция һәм Гражданнар сугышы вакытында төрле шәһәрләргә сибелгән, төрле шәһәрләрдә гастрольләрдә йөргән беренче театр труппалары «Сәйяр», «Нур», «Ширкәт» артистларын чакырып китерә. Ул елларда татар дөньясы киңрәк һәм бердәмрәк булган, шуңа да аларның кү-

Кәрим Тинчурин – 1920–1930нчы еллардагы театр сәнгатенең иң күренекле шәхесләреннән берсе.

Фото: Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры музее архивыннан

Бүгенге көндә фикерләр төрле булса да, 20 нче еллар асылда иҗади эзләнүләр, сәхнә экспериментлары һәм фикереңне, курыкмыйча, иркен итеп белдерү чоры булган. Фотода – труппаның әнә шул мизгелләре.

бесе Әстерхан, Симферополь, Мәскәү, Ленинград, Уфа, Троицк шәһәрләрендә милли труппаларны җитәкләгән. Сәхнә корифейлары белән бергә яңа театрга Салих Сәйдәшев, Һади Такташ кебек яшь талантлар да килгән…

АЗАТЛЫК РУХЫ

1923 елның җәендә бер журналда Кәрим Тинчуринның «Татар театры кайсы юлдан китәргә тиеш?» дигән мәкаләсе чыга. Ул иҗади интеллигенцияне чын мәгънәсендә кузгатып җибәрә, ел дәвамында вакытлы матбугат битләрендә әлеге темага җавап язмалар басыла – кешеләр бәхәсләшә, фикер алыша, тәкъдимнәр кертә… Бүгенге көндә бу турыда фикерләр каршылыгына карамастан, иҗади эзләнүләр, театраль тәҗрибәләр һәм иҗатта ирек чоры була ул.

… Театрда «Шлем» спектакленең премьерасы. Сәхнәдә – «кызылармиячеләр», залда да. Финал! Сәйдәшев маршы – диварлар селкенә. Марш тагын бер кат яңгырый. Тамашачы кызылармиячеләр, хисләренә түзә алмыйча, актер кызылармиячеләрне кочакларга сәхнәгә ыргыла. Әлеге вакыйганы пьеса авторы Габдрахман Минский күзәтеп тора.

20нче елларның репертуары күпкырлы булуы белән шаккатыра. Яңа заман каһарманнары турындагы эшләр белән берррәттән милли спектакльләр дә, рус һәм чит ил классикасы да куела – «Галиябану», «Гамлет», «Отелло», «Явыз Иван үлеме» спектакльләрендә ышандыра белеп уйный торган Хәлил Әбҗәлилов, кайнар канлы Мифтах Әбсәламов, драматик рухлы Мөхтәр Мутин, күпкырлы Гөлсем Болгарская балкый… Сезон саен афишага дистәгә якын яңа спектакль өстәлә. 1925 елда беренче милли опера – «Сания» сәхнәгә куела. Ә аннан соңгы ел үзе бер дәвергә тиң булып чыга: «Тинчурин – Сәйдәшев» дуслыгы нәтиҗәсендә «Зәңгәр шәл» спектакле туа. Ул озак елларга татар театрының бренды булып әверелә.

Шул ук вакытта театрда демократик тамашачы өчен көрәш бара: кичә генә авылдан шәһәргә күчеп килгән, театрдан үзенә нәрсә кирәген аңлап та җиткермәгән тамашачының сәнгати зәвыгын формалаштырасы бар әле. Хәер, бу аңлашыла да, театр үзе дә үзенә күрә бер бүленеш кичерә – беренчелеккә ике эстетик төркем дәгъва итә. Болар – үз канаты астына радикаль сәнгать яклыларны җыйган Сул татар мәдәни фронты (СУЛФ) һәм традицион формалар, пролетар проблематика, вульгар социологизм яклыларны берләштергән уңнар (РАПП).

– Күпмедер дәрәҗәдә әле күптән түгел генә барлыкка килгән татар театр сәнгатендә барысы да новатор булган, – ди Нияз Игламов. – Инкыйлабка кадәрге ачышлардан башлап, Хәрби коммунизм һәм Яңа икътисадый сәясәт чорының мәдәни ихтыяҗларына кадәрге эволюцион юл яклы булган Кәрим Тинчурин һәм СУЛФчы Сөйләйман Вәлиев-Сульва, үзәк юнәлеш тарафдары Евгений Вахтангов шәкерте Гомәр Дәвишев.

ЯКТЫДАН – КАРАҢГЫГА

Әлеге көрәшкә ноктаны… Максим Горький белән Владимир Немирович-Данченко куя. «Инкыйлаб хәбәрчесе» 1934 елда совет Язучылар берлегенең I съездында дистәләрчә еллар буена СССР халыклары мәдәниятенең эзләнүләрен тигезләп торган төп иҗат методы – социалистик реализмның доктринасын яңгырата. Икенчесе исә Горькийның «Дошманнар»ын шундый итеп куя, ул бөтен театрлар өчен канунга әйләнә. Якут театрымы ул, үзбәкнекеме, Таировның камера театры яки Михоэлсның ГОСЭТымы – барысын да МХАТның эстетик параметрларына көйләнгән психологик сәнгать кысаларында «бер сызыктан сөрәчәкләр». Театрыбызны һәлакәткә илтүче әлеге процессның иң югары ноктасы Сталин дәверенең ахырына туры киләчәк…

– Гражданнар сугышы тәмамланганнан соң, 1927 елга кадәр безнең ил мәдәният чыганагы булып торган, – дип сөйли Нияз Игламов. – Иң яңа, радикаль, авангард идеяләр өстә генә яткан ул чорда. Татар мәдәнияте өчен дә әлеге чор ренессанс дәвере була. Аның кайтавазы утызынчы еллар уртасына кадәр ишетелә, ләкин анда хәлләр катлаулана башлаган була инде…

Антифашистик хәрәкәтнең символы булган «Профессор Мамлок» пьесасы язучы Фридрих Вольфның каләме астыннан нәкъ менә 1934 елда – Гитлер хакимияткә килүгә чыга. Ә 1935 елда инде аны Гомәр Исмәгыйлов татар сәхнәсенә күтәрә, һәм ул зур уңыш белән бара. Шунысы игътибарга лаек: Фридрих Вольф әлеге эшне күргән һәм бик ошаткан.

– Вакыттан алда баручы режиссер-психолог, – Исмәгыйлов турында тәнкыйтьче Нияз Игламов шулай ди. – Ул фашизм белән килешү мөмкин түгел, дип үтә дә җитди, тирән



«Профессор Мамлок» пьесасы үз заманында ук фашистларга каршы хәрәкәт символына әверелгән. Шунысы гаҗәп: ул татар театры сәхнәсендә 1935 елда – басылганнан соң күп тә үтмичә куела. Фотода – пьесаның авторы Фридрих Вольф һәм спектакльнең режиссеры Гомәр Исмәгыйлев.

Шомлы 1930 нчы елларда Нәкый Исәнбәткә таланты шәркый сюжетлар һәм темалар артына качарга мөмкинлек биргән. «Хуҗа Насретдин»да ул текст эченә бик күп мәгънәләр яшереп калдырган. Фотода Сәхилә ролендә Гөлсем Камская балкый.

спектакль куйган. Шулай да, спектакльне Молотов – Риббентроп пакты төзелүгә, репертуардан алалар. Шул көннән башлап, «фашистларча» сүзе Муссолини режимы, Франко Испаниясе яки Салазарның Португалиядәге тәртипләренә нисбәтле генә кулланыла башлый, Гитлер Германиясе белән бәйле бер дә искә алынмый.

Гомәр Исмәгыйлов репрессияләрдән качып котыла – режиссерның исеме «исемлеккә керүе» турында НКВД хезмәткәрләренең берсе кисәтә – таланты алдында баш иеюе була. Фанера чемоданын тотып, Исмәгыйлов башта Бохарага, аннан Сәмәркандка күчеп китә, анда периферияләге үзбәк театрлары тормышында актив катнаша. Бөек Ватан сугышы башланунга, Вольф пьесасы буенча куелган спектакль яңартыла.

ИКЕ ДӨНЬЯ АРАСЫНДА

Совет халкы, гадел җәмгыять идеясе белән илһамланып, йөзләрчә заводлар кора, яңа шәһәрләр, юллар сала, чирәм җирләрне күтәрә – күпләр өчен, чыннан да, «яшәү яхшырак, күңеллерәк» була башлый. Ләкин Архангельск зиратына куелган стела безгә башка нәрсәләр турында искәртә...

– 1930нчы еллар уртасына кадәр Мәскәү, Ленинград, Әстерхан, Орск, Свердловскида – бөтен ил буйлап! – дистәләрчә татар профессиональ дәүләт театрлары эшли, – дип сөйли Нияз Игламов. – Бер-бер артлы аларны ябa башлыйлар. Татар театрын көчләп ТАССР чикләренә «куалап» кертәләр. 23 профессиональ театрдан икене генә калдыралар – Казанда һәм Минзәләдә. Сталин торган саен гайрәтләнә бара, һәм бу аның сәясәтенең хәйләкәр бер адымы була – «бүлгәлә һәм хакимлек ит». Күрәсең, милләтләр эшләре буенча халык комиссары итеп нәкъ менә аның куелуы очраклы булмагандыр. Сәясәтчеләрнең берсе дә – аңа кадәргеләре дә, аннан соңгылары да – милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләргә андый ук зур игътибар бирми. Башка беркем дә тулаем халыкларны сөргенгә озатмый, ил составындагы милләтләрнең территориаль картасын үзгәртми.

Иҗат кешеләре арасында кискен чистарту башлана. Репрессия машинасы татар мәдәнияте әһелләрен берәм-берәм үзенә йота, алар арасында күренекле драматурглар да, талантлы режиссерлар да, актерлар да була. Кәрим Тинчурин, Гали Ильясов, Фәтхи Бурнаш, Мөхтәр Мутин, Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи-Казанлы, Мәхмүт Галәү, Гомәр Исмәгыйлов... Бу шәхесләрнең гаиләләре дә террор корбаны була хәтта. Шундый фаҗигале тарихларның берсе – татар шагыйре Хәсән Туфанның хатыны Луиза Салиәскарова турында. Шагыйрьне шул елларда эзәрлекли башлыйлар, ә 1940 елда лагерьга озаталар. Унбиш ел Луиза иренә посылкалар җибәреп тора, хәтта кан доноры була – аның өчен акча түләгәннәр чөнки.

Репрессияләрдән котыла алганнарның да хәле көнләшерлек булмый. Берәүләр, Тинчуринның якын дусты, композитор Салих Сәйдәшев кебекләр, эшсез калып, очраклы эшләр булганга гына очын очка ялгап яшәргә мәҗбүр була. Театрда калганнарга яңа чынбарлыкта яшәүнең компромисс формаларын эзләргә туры килә. Таҗи Гыйззәт, Нәкый Исәнбәт, Риза Ишморат... Алар каләме астыннан чыккан һәр пьеса иң элек органнарның өстәленә кереп яткан.

– Даими рәвештә стресс шартларында эшләргә туры килә аларга, – дип сөйли Игламов. – Һәм ул, аңлашыла инде, иҗади фикерләүне деградациягә китерә, чөнки автор яхшырак итеп языйм, дип түгел, ә репертуар комитеты аша ничек итеп үткәрергә икән, дип тырыша. Риза Ишморат үзе өчен заманчалыкны сайлый – 1930нчы елларда ул корыч коючылар, чик саклаучылар, танкистлар турында яза. Таҗи Гыйззәт инкыйлабка кадәрге татар авылының укый-яза белмәвен, алпавытларның фәкыйрьләрне изүен, муллаларның һәм им-томчыларның халык җилкәсен кимерүен тәнкыйтьли. Нәкый Исәнбәткә исә талантының масштабы шәркый сюжетлы пьесалар кинаясе артына яшеренергә мөмкинлек бирә. «Хуҗа Насретдин»да ул каһарманнарының гыйбарәләре, андагы юллар арасына күп нәрсә яшерә. Нәкъ шуңа күрә ул бүген дә әһәмиятен югалтмады, ә Ишморат белән Гыйззәт исә, бер-ике әйберләреннән кала, театр өчен югалды дияргә була. Ә алар – әсәрләренең драматик структурасы, һөнәри дәрәҗәсе турында әйтәм – беренче урындагы талантлы кешеләр булган! Кечерәк масштабтагы талантлар турында әйтеп тә торасы юк.

– Сталинны акларга теләүче кешеләр бар, ул шәп менеджер булган, дип раслыйлар, – дип дәвам итә Игламов. – Имеш, репрессия корбаннары турында Солженицын китергән саннар күпертелгән. Бу чыннан да шулай – чынлыкта репрессияләнүчеләрнең өлеше гомуми халык саныннан якынча 1,5 процентны тәшкил иткән.

Фото: Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры музее архивыннан

Ләкин шунысын аңларга кирәк: нинди 1,5 процент бит ул! Аның күпчелек өлеше интеллигенция вәкилләре. Ул репрессияләрнең һәм чистартуларның атмосферасының ни дәрәҗәдә зарарлы булуын да аңларга кирәк: кешеләр караны кара, акны ак дип әйтергә курыкканнар бит.

ТИНЧУРИННЫҢ ЧЕТЕРЕКЛЕ ХӘЛЕ

Заһидә Тинчурина кулында Әстерханнан килгән журнал. Ә анда!..«Тинчурин әфәнде Әстерхан театры чибәрләре арасында» – фото астына нәкъ шулай дип язылган. Әлеге «тәртипсезлек»не күреп, Заһидә (билгеле, башка сәбәп белән!) ире янына юлга чыга. Ләкин шикләрнең урынсыз икәнлеге ачыклана – ул хатынына тугрылык саклый һәм һәрвакыттагыча бик күп эшли.

Әстерхан дәүләт татар драма театрында Кәрим Тинчурин спектакльләр куя. Ул анда 1924 елда ук, аны Казанда «театрның эше канәгатьләнерлек түгел» дип эшеннән бушатуга, китеп бара. Вазыйфасына башка кешене билгелиләр. Нибары бер сезон эчендә театр түбәнгә тәгәри, тамашачысын югалта. Тинчуринны кире кайтырга сорыйлар.

– Мин моны без әлегә кадәр белмәгән берәр тарих белән бәйледер, дип уйлыйм, – дип аңларга тырыша Тинчурин язмышындагы борылышларның сәбәпләрен Нияз Игламов. – Минемчә, Тинчуринны эшеннән азат итү – Гаяз Исхакыйдан алган хатка карата хакимиятләрнең беренче – әлегә «йомшак» формадагы – реакциясе булгандыр, дип уйлыйм.

Танылган татар язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый революциягә кадәрге татар театрында репертуар тоткан автор булган. Аның 11 пьесасы куелган – хәтта Камалныкы да азрак!

Исхакый Тинчуриннан өлкәнрәк булган һәм илдә барган вакыйгаларга карата мөнәсәбәте күптән формалашкан. Эмиграциягә дә иртәрәк китәргә өлгергән – кыенлыклар аша, әмма ышанычлы юллар белән. Кызы Сәгадәт Тинчуриннар карамагына калган. Күпмедер вакыт узгач, аңа әтисе янына күчеп китәргә ярдәм итәләр. Әлбәттә, Исхакыйның рәхмәте зур була, ләкин бу рәхмәт Тинчурин өчен җәзага әйләнә.

– Гаяз Исхакый исемен кычкырып әйтмәскә тырышканнар, әйтәләр икән, бары тик тискәре яктан гына, – дип сөйли Нияз Игламов. – Аңа бик күп нәрсәләрне гаеп итеп тakkаннар, хәтта утызынчы елларда Германиядә яшәвен дә. Фашистлар режимы көч җыйган вакытта. Ләкин бит ул вакытта Берлинда Европадагы иң көчле тюркология мәктәбе оешкан була. Анда яшәр һәм эшләр өчен уңайлы тел мохите булган. Гитлерның да кем икәне бөтен кешегә дә ачык кына билгеле түгел әле ул вакытта. Исхакый Берлиннан 1930 нчы еллар ахырында Төркиягә качып китә. Монда да аның алдан күрүчәнлеге роль уйнаган. Мережковский, Кнут Гамсун, Герхарт Гауптман, Эзра Паунд һәм түбәнрәк дәрәҗәле әдәбиятчылар Гитлер реформалары һәм Өченче рейхның бөлүенә кадәр идеологиясе белән илһамланганда әле бу.

Шулай итеп, 1923 елда Берлиннан Казанга бандероль килеп төшә. Адресаты – Кәрим Тинчурин. Конвертта тюркология җәмгыятенең журналы, анда – Исхакыйның яңа пьесасы. Аның белән бергә авторның кызын кайгыртулары өчен рәхмәт хаты. Тинчурин бу хәбәрне дустыннан яшермәгән. Театрга: «Гаяз абый сезгә сәламнәрен юллый!» – дигән сүзләр белән килеп керә ул. Доносны кем язган – билгеле түгел, ләкин ундүрт ел узгач, ягъни коточкыч 1937 елда Тинчуринга «халык дошманы» белән элемтәсен исенә төшерәләр, өстәп, «Япония файдасына шпионаж»да гаеплиләр. Ни өчен Япония? Ул вакытта Исхакый Япониядә яшәгәнгә.

«БЕЗ КАБЫЗГАН УТЛАР»

Көрәштәшләре һәм остазларын яклап бик азлар гына күтәрелеп чыга. Аның каравы, әле күптән түгел генә бүләкләр биреп, аны икеләтә юбилее белән котлаган кешеләр Тинчуринга пычрак атарга, яла ягарга оялмый.

– «Контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнүче япон шпионы Кәрим Тинчуринны тикшерү» җыелышының беркетмәсен үзем күрмәдем, ләкин аны минем әти укыган, – дип сөйли Нияз Игламов. – Мөгаен, ул еллар контекстында иң тәрбияле позициядә беренче чакырылыш актерлар гына калгандыр. Мәсәлән, Зәйни Солтанов. «Без моңа ышана алмыйбыз! Безнең белән ул мондый сөйләшүләр алып бармады». Калганнар бертавыштан диярлек Тинчуринны «фаш иткән». Шул вакытта кинәт кенә Гөлсем Камская торып баскан. Ул вакытта инде аның ире – режиссер Гали Ильясов репрессияләнгән була. «Сез нишлисез? Кәрим ага һәрвакыт яхшы кеше булды, ә сез аны хур итәсез, буш сүз сөйлисез!»

Җыелыштан соң актрисаны театрдан куалар – сугыш башлангач кына ул, актерлар җитмәү сәбәпле, фронтта эшли торган бригадага кайта алачак. Тинчурин исә инде күптән теге якта калган…

…«Без кабызган утлар янар алар» – әлеге җыр 1930 нчы елларда бик популяр була. Сүз уңаеннан, җыр – «Кандыр буе» спектакленнән Фәридә ариясе, аны Тинчурин белән Сәйдәшев иҗат иткән. Бу заман шедеврын еш кына радиодан ишетеп булган, хәтта «Маяк»тан да. «Салих Сәйдәшев көе, халык сүзләре!» дип игълан итә торган булганнар. Тинчуринны онытырырга тырышканнар, ләкин аның фигурасы шулкадәр зур, аны мәдәни контексттан көчләп юкка чыгару мөмкин хәл булмый.

– Аның рухы барыбер һәркайда сизелеп торган, – дип сөйли Нияз Игламов. – Күрәсең, Тинчурин бик якты, сөйкемле кеше булган. Бөтен хатирәләр дә шул турыда сөйли. Хәким Сәлимҗанов үзенең хатирәләрендә болай дип язган: «Без үзебезне аның шәкертләре итеп түгел, ә мөридләре итеп саный идек». Ягъни укучылары түгел, ә тарафдарлары. Татар театры өчен драматург озак елларга җитәрлек иҗади энергия чыганагы булды.

Озак вакытлар Тинчуринның үлгән көне дә ялган мөһере астында сакланды – бары тик 1988 елда бөек татар режиссеры һәм драматургның 1947 елда каты авырудан вафат булмавы, ә 1938 елда атып үтерелүе билгеле булды. Кулга алганнан соң бер ел буена аннан күрсәтмәләр таптыралар, әмма сындыра алмыйлар. Атып үтерелгән ноябрь төнендә дистәләрчә мәетнең гәүдәсен Казанның Архангель зиратындагы чокырга илтеп аударалар.

1930 нчы еллар ахырына якынлаша. Аннан соң нәрсә була? Аннан соң – сугыш…

«Татарстан» журналының махсус проекты

30нчы еллар

БУЫННАР

БЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫКЛАР БУЫНЫ

30 нчы еллар буыны... Әлеге кешеләргә бөек каршылыклар чорында яшәргә туры килә. Искиткеч энтузиазм һәм коточкыч репрессияләр, индустриализация төзелешләре һәм ГУЛАГ концлагерьлары, стахановчылар хәрәкәте һәм оятсыз яла ягулар, күмәкләштерү һәм җир хуҗаларын күпләп үз ватаннарыннан куу чорында яшәгән кешеләр алар. Ул чорда яшәгәннәрнең күбесе үзләре һәм киләчәк буыннар өчен яңа бәхетле тормыш төзүләренә ихластан ышанган, күбесе бу ышанычларыннан соңгы сәгатьләренә кадәр, хәтта НКВД диварлары эчендә дә аерылмаган... Бу бөек экспериментта агымы, карасымы – нәрсәнең өстен чыгуы турында хөкем карары чыгарырга ашыкмыйбыз. Вакытны сайлап алмыйлар – безнең ата-бабаларыбыз, үзләренә нинди гомер тигән булса, шуны яшәгәннәр. Үз бәхетләре һәм борчулары белән. Һәм киләчәк буынга һич кенә дә зәгыйфь ил тапшырып калдырмаганнар.
Узган гасырның 30 нчы елларында нәрсәләр барлыкка китерелгән һәм нәрсәләр җимерелгән?* Зур тарихта нинди кешеләр үз эзләрен калдырган һәм гаилә архивлары гасырның нинди билгеләрен саклый?

ХРОНОГРАФ

1930

- Республикада беренче Нурлат-Октябрь машина-трактор станциясе (МТС) төзелә
- Татарстанда 15 меңгә якын хуҗалык кулак хуҗалыгы дип таратыла
- Март аена коллективлаштыру темплары буенча Татарстан илдә өченче урынга чыга. Крестьян хуҗалыкларының 83 процентган артыгы колхозларга керә
- Сталинның «Правда» газетасында басылган «Уңышлардан баш әйләнү» дигән мәкаләсеннән соң, 1 октябрьгә колхозларда крестьян хуҗалыкларының саны 10 процентган кимрәк кала
- «Татарстан партия оешмасы торышы һәм эше турында»гы ВКП (б) ҮК карары. Партия оешмасы дини хорафатларга каршы көрәштә чаманы югалтуда гаепләнә

1931

- ТАССР дәүләт электр станцияләренең «Татэнерго» район идарәсе төзелә
- Казанда Татар, Башкорт, Чуваш АССР, Удмурт, Мари һәм Мордва автоном өлкәләренең ударник колхозчылары слеты уза

1932

- «Казмаш» авиация комбинаты төзелә башлый
- Казан авиация институты ачыла
- Яшел Үзән эшчеләр бистәсе шәһәр статусын ала. Хәзер ул – Яшел Үзән шәһәре
- Казан кинохроника студиясе оештырыла

* 30нчы еллар буыны турында тулырак – журналыбызның 2019 елның март санында.



- Казан Яшь тамашачылар театрында беренче спектакль куела
- Казан сөт заводы эшли башлый

1933

- Ударник колхозчыларның I Бөтентатар съезды уздырыла
- Татар дәүләт академия театрының күчмә филиалы – булачак Тинчурин исемендәге театр оештырыла
- Казанда җылылык электр станциясе (ТЭЦ-1) сафка бастырыла

1934

- Татарстан Ленин ордены белән бүләкләнә
- I Бөтентатар язучылар съезды уздырыла

1935

- Казанда Беренче дәүләт интернациональ курчак театры ачыла
- Татарстанда стахановчылык хәрәкәте башлана

1936

- Татарстан Рәссамнар берлеге оештырыла
- Казан синтетик каучук заводы сафка бастырыла

1937

- Зур террор елы. ТАССР Эчке эшләр халык комиссариаты (НКВД) хисабыннан күренгәнчә, бу елны республикада 4173 кеше репрессияләнә
- Казанда дәүләт филармониясе оештырыла

1938

- Беренче тапкыр Татарстан АССР Югары Советы сайлана

1939

- Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты оештырыла.
- Татар алфавитын латин графикасыннан кириллица нигезендә төзелгән яңа алфавитка күчерү турында карар кабул ителә

1930нчы еллар

Фото: ТР Милли музей архивыннан алынды

ЭШЧЕЛӘР ҺӘМ КРЕСТЬЯННАР ДӘҮЛӘТЕН НЫГЫТУ

Төрле вакытта Татарстанга күп төрле сәяхәтчеләр килгән, алар Казанны һәм аның әйләнә-тирәсен төрлечә тасвирлаган: кем – картиналарында, кем – шигырьләрдә, кем – прозада, кем – фотографияләрдә, кайберәүләр яхшы сүз белән генә дә... Шуларга нигезләнеп, без, әйтик, шәһәребезне XIX гасыр гравюраларында – инглиз рәссамы Эдвард Турнерелли күзләре белән, ә XX гасырның 30 нчы еллары фотографияләрендә – Америка профессоры Франк Уитсон Феттер карашы аша күрә алабыз... Ә Казанның никадәр күренешләре һәм вакыйгалары Татарстан Республикасының Милли музее архивларында саклана.

Бүген безнең «Буыннар» проекты турыдан-туры шушы архивлардан узган йөзьеллыкның 30 нчы еллар фотографияләре белән тулыланачак. Нәкъ шушы елларда ТАССР үсә, нәкъ шул вакытта ил һәм республика тарихында күмәкләштерү, индустриальләшү, специальләшү кебек дигән яңа сүзләр һәм төшенчәләр барлыкка килә.

Димәк, артка борылып карыйбыз. Хәзерге вакытта бөтен дөньядан туристлар килергә омтылган шәһәребез элек нинди булган соң?

Казан. Ленин исемендәге Культура сарае урнашкан Казансу ярларын төзекләндерү.

Казан. Лобачевский урамын төзекләндерү.

Казан. «Авиастрой». М.И. Калинин төзелеш мәйданында (1930 нчы еллар).

Казан. Мех комбинаты төзелеше (1930 нчы еллар).

Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә библиографы В. Недорезов 30 нчы елларда яшәгән Татарстан кешеләренең тормышын саннарда һәм суммаларда тасвирлаган. Менә нинди булган ул:

ХАЛКЫ

- 30 нчы елларда Казан халкының саны – 230 мең, 1/3 өлеше – татарлар.
- 41382 кеше – эшчеләр,
- 24168 – хезмәткәр,
- 8168 – хезмәт күрсәтүче кече персонал (җыештыручылар, каравылчылар һ.б.),
- 5322 – мөстәкыйль җитештерүчеләр,
- 23330 – башка төр хезмәт ияләре.

ТОРАК

- 30 нчы елларда Казанда 42 769 корылма булган.
- Алардан 13430ы – торак йортлар.
- Торак фондының 2/3 өлеше – дәүләтнеке.
- Йортлар нигездә берәр катлы, агачтан җиткерелгән, уңайлыклар – минималь.
- Фатирларда яшәүчеләрнең нибары яртысы гына электр яктылыгыннан файдалана алган, йортларның ¼ ндә генә су үткәрелгән, 3%ында канализация булган, 4%ы үзәктән җылытылган.
- Бер кешегә – 4 кв. метр торак, 1 кв. метр яшеллек туры килгән.
- Торак йортлар аз төзелә, аның каравы предприятиеләр күп: «Авиастрой», «Машинострой», «Грэсстрой»…

ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ ҺӘМ ТРАНСПОРТ

- Урамнарның 40 процентына гына таш җәелгән.
- Урамнарның һәр километрына 1,5 фонарь туры килгән.
- 6 трамвай маршруты булган, аларда 111 трамвай вагоны хәрәкәт иткән.
- 22 шәһәр автобусы.
- Шәһәрдә 200 автомашина һәм 250 дән артык олаучы эшләгән.

ХЕЗМӘТ ХАКЫ

- 11932 елда – эшчеләр һәм хезмәткәрләрнең айлык хезмәт хакы дәрәҗәсен 101 сумга җиткерү карала. Әлегә алар түбәндә күрсәтелгән хезмәт хакын алган:
- Тегү фабрикасында майлаучылар – ай саен 60–70 сум.
- Кинотасма фабрикасын төзүчеләр: балта осталары көненә – 12 сум 25 тиен, бетончылар – 6 сум 90 тиен, арматурачылар – 9–11 сум, ярдәмче эшчеләр – 5 сум 68 тиен.
- «Машинострой»да төзүчеләрнең удар бригадасы – айга 100–150 сум.
- «Авиастрой»да йөк ташучылар – көн саен 30–40 сум.
- Каравылчы, җыештыручы, йомышчыларның (курьерларның) хезмәте аена 30–60 сум белән бәяләнгән.
- Укытучыларның хезмәт хакы 98–169 сумны тәшкил иткән.
- Югары мәктәп укытучылары, техник бүлек җитәкчеләре, инженерлар 200 дән 600 сумга кадәр хезмәт хакы алган.

Казан. Кинофабрика төзелешендә Каюмов иптәшнең ташчылар удар бригадасы (1930 нчы еллар).

Лаеш районының «Кызыл җирбиләүче» колхозы. Язгы чәчү вакытында бригадалар һәм звенолар арасында социалистик бәйгеләр уздырыла торган була.

Өч республика –Татария, Мордовия һәм Чувашия – арасындагы соцбәйге буенча килешү төзү. 1938 ел.

Казан. 4 нче номерлы Синтетик каучук заводы төзелеше (1930 нчы еллар).

АЗЫК-ТӨЛЕК

- 30 нчы елларда Казанда, төрле ларёк һәм базарларны санамаганда, 700 дән аз гына артыграк кибет эшләгән.
- Арыш ипиенең килосы – 9, бодай ипиенең килосы 20 тиен торган. Әмма карточкага бирелгән. 1929 елда ипигә генә түгел, иткә, керосинга һәм башка азык-төлек һәм сәнәгать товарларына да карточкалар кертелгән.
- Һәрбер эре предприятиенең эшчеләр өчен ябык кооперативлары, махсус ашханәләре һәм паёк системасы булган.
- Мехкомбинат төзүчеләр ашханәдә ике итле ризык өчен 47 тиен түләгән, ә ударниклар, шуңа өстәп, бушлай өченче ризык та (эремчек, кесәл яки бер стакан кофе) алган. Монда үз нормалары бар – бер кешегә көненә 200 г ипи һәм 80–100 г ит.
- Махсус белгечләр өчен коммерция тибындагы ашханәләр дә эшләгән. Анда, мәсәлән, итле ризык 1 сум 65 тиенгә төшә торган булган.
- Ит дәүләтнеке булган сәүдәдә һәм кооператив сәүдәдә 1–2 сум торса, базарда бер килосы 6–7 сумнан йөргән.
- Йомырканың дистәсе кибеттә – 90 тиен, базарда – 3 сум 50 тиен, атланмай шул ук тәртиптә – 3 һәм 10 сум.
- Базарда бер капчык арыш – 20–30 сумга, бер чирек сөт – 3 сумга, эремчекнең кадагы 3,5 сумга сатылган.
- Җәй көне өлгергән карбыз – 5–6 сум, бакча җиләгенең килосы 3 сум торган.
- Кооператив ларёкта ысланган бәртәс балыгының килосын 7 сумга, мәрсин балыгын 9 сумга сатып алып булган.

БАШКА ТОВАРЛАР ҺӘМ ХЕЗМӘТЛӘР

- Керосинның литры – 12 тиен, ситсының метры – 30 тиен. Исле сабынның бер кисәге 65–90 тиенгә сатыла торган була. Барысы да – карточкага.
- Хатын-кызлар өчен шевиот пальтоны кооперативларда – 135 сум, ирләр костюмы – 130 сум, балалар костюмы 40 сумга сатылган.
- Ситсы һәм сатин күлмәкләр – 5–8 сум, чалбар – 10–15 сум.
- Диван һәм өстәлләр – 200 әр сум.
- Велосипед 600–800 сум торган. Рояль – 1400 дән 3000 сумга кадәр.
- Баланың чәчен алу – 35 тиен, өлкән кешенекен – 80 тиеннән 1 сум 80 тиенгәчә.
- Идел аша моторлы көймәдә чыгу өчен 50 тиен түләргә кирәк булган. Паромда кечү һәм шулай ук йөк белән (автомобиль) – 70 тиеннән 10 сумга кадәр.
- 1932 елдан ике маршрут буенча пассажирлар һәм йөк ташучы авиалинияләр ачыла: «Мәскәү – Казан – Свердловск» һәм «Мәскәү – Казан – Владивосток». Мәскәүгә очу вакыты – 4 сәгатькә, Владивостокка очу 30 сәгатькә сузылган. Казаннан Мәскәүгә очу өчен тарифлар бер килограмм авырлык өчен 1 сум 40 тиеннән исәпләнгән. Казанда аэрофлот әнә шундый бәяләрдән башланган.

1930нчы еллар



ӘЙДӘ, ИПТӘШ, БЕЗГӘ – КОЛХОЗГА...

Күн авылында ныклы хуҗалык алып баручы урта хәлле крестьян Мифтах Бикмөхәммәтов ике бәла-казадан гына курка – янгыннан һәм корылыктан. Көн-төн эшли, хәер, яшәвен дә начар яшәми. Ике аты, сыеры, тавыклары бар, өендә күкеле сәгате эленеп тора... Кешенеке кирәкми, үземнекен дә бирмим, дип көн күрә ул. Өченче бәла – күмәкләшү дигән зәхмәтнең килеп чыгасын кем белгән бит?

Автор:
Әскәр Сабиров

Рәхмәт яугыры, күршеләре кичтән кисәтеп өлгерә:

– Мифтах абый, иртәгә сиңа киләчәкләр. Яшерә алганыңны яшер...

Ә кая яшерергә соң? Соңгы чиккә кадәр менә шулай тик торганнан, бер сәбәпсез, кулак дип язып, бөтенесен талап чыгасыларына да ышанмый ул. Алай да ике тавыгын суя – башка беркайчан мондый тәмле шулпа ашарга насыйп булмый инде аларга...

Уполномоченныйлар иртәнге якта килеп керә. Хуҗага кәгазь төртеп, терлекләрне алып чыгып китәләр. Аннан соң өйдәге әйберләрне ташый башлыйлар. Бернәрсәне дә онытмыйлар. Мендәрләр, хуҗалык кирәк-яраклары, сәгать, он, өйдәге азык-төлек – барысын да алып чыгып китәләр. Хәтта ашка салырга дип әзерләп куйган умачны да... Йорт бушап калгач, хуҗаларның үзләрен урамга куып чыгаралар. Биш бала белән. Иң өлкәне – Разыяга – унике яшь, кечесе Зәкәриягә бер яшь кенә тулып киткән була...

– Хәзер безгә кая барырга инде, ачтан үләргәме?

– Теләсәгез кая китегез. Дүрт ягыгыз – кыйбла, үлә дә аласыз...

Бу хәлләр 1932 елның җәендә була. Гәҗитләрдә, авыл советы диварларында – җете кызыл төстәге плакатлар... Аларның кайберләрендә алсу битле комсомолкалар: «Әйдә, иптәш, безгә колхозга!» – дип елмаялар. Икенчеләрендә өрлектәй егетләр теш арасыннан гына: «Батраклар, фәкыйрьләр һәм урта хәллеләрнең көчен бергә туплап, кулакны изик», – дип чакыралар.

Яңа тормышта бөтен кешегә дә урын табылмый.

КУЛАК, УРТА ХӘЛЛЕ – АЕРМА ЮКМЫ?

Харап, фаҗига икән – кулак урынына күп балалы урта хәлле крестьянны сөргәннәр... Үлүләре хак түгел, бәлки, әле исән дә калырлар. Бөтен җирдә күмәк хуҗалыкларга берләшү барганда аерым бер кешеләр турында уйлап торырга вакыт юк. Татреспубликада ВКП(б) Үзәк комитеты каршында кызарып торырга күнекмәгәннәр: аерым хуҗалыкларны колхозларга җәлеп итү бурычын партия кушканча ашкынып башкаралар.

Урыннарда әлеге ашкыну тәмам ярсу, шашуга әйләнә. Ятларны куркыту өчен үзләренекенә дә эләгә. Хәтта Мәскәүдән килгән Френкель һәм Грушкин иптәшләр дә ВКП(б) Үзәк комитетының оештыру бюросына аңлатма язуы әзерләгәндә теш сызлагандай чырайларын сыталар: «Яңа Чишмә районының Ямаш авылында урта хәлле салган Бухохаров Андрейга (1918 елдан 1921 елга кадәр Кызыл Армиядә хезмәт иткән, ике мәртәбә яраланган, гаиләсендә 4 кеше) партячейка секретаре һәм аның белән бергә тагын 2 коммунист кереп, 9 пот икмәген, арбасын алып чыгып киткәннәр... Ямаш авылы буенча 30% хуҗалыкны кулакларга керткәннәр. Волчья Слободада 19 урта хәлле крестьянга хаксыз рәвештә каты задание бирелгән, аларның мал-мөлкәтләре тартып алынган, кешеләрнең үзләрен өйләреннән куып чыгарганнар. Тымытык районының Сукаеш авылында барлык аерым хуҗалыкның 50%на, кулаклар белән бергә тигез, каты задание бирелгән...»

Татреспубликага җибәрелгән ҮК инструкторлары, сыйнфый юнәлешне бозган кайбер фактларны тарих өчен теркәп куйсалар да, гомумән алганда, вазгыятькә җитди йогынты ясый алмыйлар. Урыннардагы түрәләрнең кайберәүләренә, арттырып җибәрүләр өчен, күп дигәндә, партия линиясе буенча шелтә чәпиләр. Яисә кул астында эшләүчеләрнең муен тамырына берне тондыралар –– шуның белән шул. Мондый шелтәләр булды ни, булмады ни.

Ә менә икенче бер нәрсәләр өчен җәзалыйлар яисә мактыйлар. Әйтик, колхоз төзелешендәге

уңышлар яки уңышсызлыклар өчен. Икмәк әзерләү өчен. Илдә индустриальләшү башлана, шәһәрләргә икмәк күбрәк кирәк була башлый. Бу яктан Татария большевикларына тел-теш тидерерлек түгел. Френкель һәм Грушкин, хәлләрне җентекләп өйрәнеп, «икмәк әзерләүнең шактый артуын» билгеләп үтәләр: 1929 елда 7 миллион пот икмәк тапшырыла, 1930 елда – 17 миллион пот, 1931 елда исә инде – 34 миллион пот! Нәкъ менә френчларга орденнар өчен тишек тишәр вакыт…

Дөрес, һәр миллион потны җыю торган саен авыррак була бара. Бай «келәтләрдән» икмәкне башлыча 1930 елда ук кырып-себереп алып бетерәләр, ул вакытта Татариядә 15 меңгә якын хуҗалыкны кулаклар исемлегенә язып, кешеләрне туган нигезләреннән сөрәләр. Ә калган биш мең сыйнфый дошман «оясын» бер елдан соң тузгытып бетерәләр.

Шунысы билгеле: 1927 елда Татариядә 518 027 крестьян хуҗалыгы була, шуларның дүрт проценты кулак исәпләнә. Сыйнфый дошманны авыл җирендә 1932 ел башына юкка чыгаралар булып чыга. Бу очракта аннан соң кем белән көрәшкәннәр икән? Кемнең игенен, терлеген төяп алып киткәннәр, җирен, малмөлкәтен тартып алып, кемне хәерче иткәннәр?

КОНЦЛАГЕРЬ, МАХСУС ПОСЕЛЕНИЕ ЯИСӘ ИҢ ЮГАРЫ ҖӘЗАМЫ?

Җиде айга мәҗбүри эшләргә җибәрергә – Казан район суды 1932 елда Каймар авылы гражданкасы Шмелёвага каты хезмәт заданиесен үтәмәгән өчен шундый кырыс карар чыгара. Колхозга кермәгән, урта хәлле, хәер, тырышырга кирәк иде! Ә инде җәза чыгарылган кешенең сукыр карчык булуын гадел суд, баштанаяк революцион эшләргә чумуы сәбәпле, гафу итегез, күреп өлгермәгән.

Гражданка Шмелёва, мөгаен, соңгы көченә мәҗбүри эшләргә дә йөрер иде, ләкин әлеге очрак, бәхеткә, аның кадәр үк өметсез булып чыкмый. Юк, карчыкның сукыр яисә хәлсез булуы аркасында түгел. Кинәт кенә карчыкның өч улы да Гражданнар сугышында үзләре теләп Кызыл Армия сафларына язылганнары ачыклана, ике улы якты киләчәк өчен башын салган, «революция каршындагы зур хезмәте өчен» үлгәннәрнең берсенең исеме хәтта пассажир пароходына бирелгән…

Революцион законнарны бозуның әлеге очрагы турындагы хәбәр, башка бик күп фактлардан аермалы буларак, иң югарыга кадәр барып җитә. Сукыр карчыкта кызылармиячеләрнең әнкәсен күрә алмаганнарга, мөгаен, күрсәтмә җәза бирелгәндер, бәлки, хәтта җаваплы вазыйфаларыннан да колак каккаларыннардыр алар. Сәяси сукырлыкларында ачыктан-ачык үкенгән якты киләчәкне төзүчеләр, әлбәттә, әле ике еллап элек кенә дә партия сәясәтен ничек җиңел һәм артык көч түкмичә тормышка ашырганнарын сагынып искә алганнардыр.

Ул чакта ВКП(б) ҮКның 1930 елның 30 гыйнварындагы «Тоташ күмәкләшү районнарында кулак хуҗалыкларын юкка чыгару буенча чаралар турында»гы Карары яңа тормыш төзү өчен көрәшүчеләрнең иң рәхимсезләренә юл ача. Партия барлык кулакларны өч категориягә бүләргә әмер бирә. Беренчесенә контрреволюцион актив кертелә, икенчесенә – контрреволюцион активның калган өлеше, иң байлардан, өченчесенә – калган кулаклар… Ә алга таба – барысы да бик гади, инструкция буенча һәм артык хисләргә бирелмичә. Беренче категориягә кергәннәрне кулга алу көтә, аларның язмышын ОГПУ, ВКП (б) өлкә (край) комитеты һәм прокуратура вәкилләре кергән махсус өчлек хәл итә. Сайлау вариантлары зур түгел: концлагерь, иң югары хөкем… Гаиләләрне Төньякка, Себергә, Уралга, Төркестанга, махсус поселениеләргә сөрү көтә. «Калганнар» категориясенә кергән кулакларга язмыш елмая дияргә дә буладыр – бар мал-мөлкәтен тартып алып, власть аларга хәтта туган республикада да калырга рөхсәт итә.

Ят сыйныфка кертелеп, лагерьларга һәм махсус поселениеләргә озатылган татарстанлыларның төгәл санын атау кыен. Бары тик шунысы гына билгеле: ил күләмендә партия тарафыннан «беренче категория»ле 60 мең кулакны «аерып алу» буенча планны ОГПУ инде 1930 елның октябренә ике мәртәбәдән артыграк итеп үти.

БАЙЛЫК КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ БУЛАРАК КӘҖӘ, АРБА ҺӘМ УТЫН ЧАНАСЫ

Татариядә арттан сөйрәлергә күнекмәгәннәр. Кулакларны сөрү буенча план шулай ук арттырып үтәлә – шөкер, тиешле активлык күрсәткәндә урыннарда кулак дип теләсә кемне «язарга» мөмкинлек була.

Татар Томбарлысы авылында да активистлар табыла. 1930 елның 2 июлендә Баулы волосте башкарма комитеты президиумы утырышында әлеге авыл кешесе И. Газизуллинны кулак дип сөрү турында беркетмә раслана. «Байгура»ның документка теркәлгән мал-мөлкәте исемлегендә иң кыйммәтлеләре атала: «1.Ызба 2.Амбар 3.Ат 4.Кәҗә 5.Арба 6.Утын чанасы». Шунысы да язылган: ат, кәҗә, арба һәм утын чанасы колхоз өчен конфискацияләнә.

Аның каравы хакимиятнең күмәк хезмәткә кушылырга теләмәүчеләргә йогынты ясарлык күпме ысулы була! Нәтиҗә – күзгә күренерлек. 1930 елның мартына Татариядәге крестьян хуҗалыкларының 83 процентан артыгы колхозларга кергән санала. Күмәкләшү темплары буенча республика ил буенча өченче урынга чыга.

Ә аннан соң бер урында кирегә тәгәрәү. «Правда» газетасында Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» мәкаләсе һәм ҮКның «Колхоз хәрәкәтендә партия линиясен бозулар белән көрәш турында»гы карары басылып чыгуга, крестьяннар колхоздан бер-бер артлы алны-артны карамый кача башлый. 1930 елның 1 октябренә Татариядә күмәк хуҗалыкларның өлеше ун проценттан да кимрәккә кала. Крестьян хәзер инде колхозга язылуның ирекле булуына чынлап торып ышанган, күрәсең.

Большевиклар чыннан да сүз белән ышандыруга һәм икътисадый методларга басым ясый башлыйлар. Соңгылары хәтта репрессияләргә (сүз уңаеннан, аларны шулай ук беркем дә тыймый) караганда, нәтиҗәлерәк булып чыга. Бигрәк тә Тымытык районында тырышалар, монда аерым хуҗалыкларга авыл хуҗалыгы салымын 5–10 мәртәбәгә арттыралар. Аерым хуҗалыкларның күпчелеге салымны түли алмый, һәм аларның мал-мөлкәтен бурычны каплау хисабына саталар. Көзен аерым хуҗалыкларга уңышны җыярга ирек бирмиләр – иген белән нишләргә кирәклеген колхоз хәл итә. Ә аннан соң аерым хуҗалыкларның бөтенләе белән җирләрен, атларын тартып алалар. Фәкыйрьлекнең чигенә җиткәннәргә кая барырга? Менә шул юл белән район җиңел һәм җайлы гына 100 процентлы күмәкләшүгә ирешә дә.

Сүз белән үгетләү көченә килгәндә исә, һәр район диярлек үзенең ныклы аргументын кулланырга тырыша. Әлмәт башкарма комитеты уполномоченные Шәриф Булгаков, мәсәлән, тал чыбыгы һәм дилбегәнең теләсә кайсы сүздән дә көчлерәк булуына ышана. Аның күрсәтмәсе буенча Сөләйдә крестьяннарның яртысын диярлек шул ысул белән кыйнап ташлыйлар.

1931 елның көзенә индивидуаль хуҗалыкларның 62 проценты күмәкләшә. Колхоз төзелешендә яңа ыргылыш кулакларны сөрүнең чираттагы этабы белән туры килүен күрү кыен түгел.

КРЕСТЬЯН ӨЧЕН АВЫЛ ҮГИ АНАДАН ДА КАТЫРАККА ӘЙЛӘНӘ

1932 елның феврале. Кызыл командир – укчы полк взводы командиры ярдәмчесе Иван Дмитриев туган ягы – Бөгелмә районына ашыга. Дмитриев өч елга беренче мәртәбә ял ала, туганнарының хәлен белергә, шул ук вакытта авылда колхоз төзелешенең ничек барганын үз күзләре белән күрергә тели. Авылның киләчәге күмәкләшү булуына ул Совет властена ышанган кебек чын күңелдән ышана. Ләкин авылында күргәннәр сугышчыны шаккатыра. Дмитриевның «Правда»га Сталин исеменә юлланган хатында – ачыктан-ачык югалып калу күренә: «Минем гаилә Татреспубликада, Бөгелмә районындагы «Кызыл доброволец» колхозында яши. Өемнән хат алганда, мин аларның иписез, ач утырулрына ышана алмадым һәм беркайчан да ышанмадым... Ләкин 1932 елның 27 февраленнән 7 апреленә кадәр мин ял алдым һәм Бөгелмә шәһәренә кайттым, анда орлыклар артыннан килгән этине очраттым. Мин аны көчкә таныдым... Өйгә кайттым, әни миңа нәрсә ашатыр дип көзлим. Табынга ниндидер калдык-постыктан әзерләнгән боламык чыгарылды. «Сез нәрсә ашап торасыз соң?» – дип сорадым мин. «Менә шуны ашыйбыз инде, монысы да һәрвакыт булмый әле», – диделәр миңа... Район оешмалары үткәргән эш хәтта хәрби коммунизм шартларын да арттырып җибәрә. Сандыкларны актаралар, чүлмәк, мичләрдә эзләнәләр, крестьянның соңгы киемен, самоварын, мендәрләрен талап алалар, утын сарайларын ваталар, үзләрен өйләреннән куып чыгаралар... Бөгелмә районында һәм, гомумән, Татреспубликаның күп районнарында авыл үги анадан да катыраккa әйләнгән. Кешеләр, үз өйләрен ташлап, кайсы кая кача...»

Халыкны җирдән аерып, булдыклы, эшчән хуҗаларны репрессияләп, калганнарны көчләп колхозга берләштереп, хакимият нәрсәгә ирешергә тиеш иде, шуңа ирешә. «Беркемнеке дә булмаган» җирдә эшләргә атлыгып тормаган, усалланган, ярымач халык массалары пәйда була. Икмәк әзерләү планын үтәүдән баш тартучылар, барыбер тартып алынaчак икмәкне үстерергә теләмәүчеләр массасы оеша. Шуңа реакция дә шундый: шәһәргә качу, массакүләм протестлар.

АЧЛЫК ҺӘМ КҮРСӘТМӘ ПРОЦЕССЛАР

1932 елның февралендә Әлмәт районы прокуроры ТАССР Юстиция наркоматына яшерен сводка җибәрә. Фактларның берсе: Кодаш авылында аерым хуҗалык алып баручылар «70–80 кешедән торган халык төркеменең башында колхоз амбарларын таларга һәм орлыкларны бүлергә килә. Төркем, ишекләрне җимереп, бөтен орлыкны алып китәргә тели һәм авыл советы рәисен кыйнарга омтыла. Әлеге эш буенча барлыгы 6 кеше хөкем ителә, шуларның 4есе – хатын-кыз. Ике урта хәллегә карата 74нче маддә буенча 1 ел һәм 8 айлык социаль яклау чарасы кулланыла, хатын-кызларга – мәҗбүри эшләр».

Репрессия чаралары турында хәбәр итүче прокурор сүзләрендә аның әлеге вазгыять каршында көчсезлеге дә күренә: «Орлык җыю,



алда хәбәр итүемчә, көтелгән нәтиҗәләрне бирмәде. Район буенча барлыгы 35% җыелды. Мин шәхсән үзем 12 авылдагы җыенда катнаштым һәм көн тәртибенә орлыклар турындагы сорауны куйдым. Гражданнар орлык тапшыру түгел, үзләре дәүләт ярдәм итмәсә, икмәксез калулары турында ачыктан-ачык белдерәләр. Кодаш авылында фәкыйрьләр һәм урта хәлләр атларын суя башлаганнар, бу гамәлләрен ачлык белән аңлаталар».

Һәм алга таба нәрсә? Алга таба – һәрвакыттагыча. Колхоз төзелешендәге уңышсызлыкларда контрреволюцияне һәм кулакларны гаепләү кулайрак. Районда ашыгыч рәвештә суд-тикшерү бригадасы төзелә, ул «усал ният белән терлекләрне суючы һәм орлык тапшырудан баш тартучы кулакларны ачыклый һәм күрсәтмә процесслар оештыра».

Хәер, хәтта коммунистик идея күзләрен томалаган активистлар да авылдагы коточкыч вазгыятьне күрми кала алмый. Революцион җәза бирүләрне гаять зур тиз белән башкаручы прокурор да, Сөләй, Кодаш, Урсалы авылларында кешеләрнең ачтан интегүләрен, ә терлекләрнең азык булмау сәбәпле кырылуларын югарыга хәбәр итеп, болай дип яза: «Минем тәкъдим буенча Сөләйгә салам, печән җибәрелде. Хәзер район башкарма комитеты терлек азыгын көйләү буенча эшли. Ихтыяҗ кискен торган колхозларга әзрәк хәлләрдән азык җибәрү буенча чаралар күрелә».

Ә «әзрәк хәлләр» күпме соң алар? Әмма большевиклар чигенергә ияләшмәгән. Колхозларга кертелгәннәрне ничектер эшләргә мәҗбүр итәргә, кызыксындырырга кирәк. Алай итмәгәндә – һәлакәт, җиңелү.

УДАР ХЕЗМӘТ ПАТЕФОНЫ

1935 ел, көз, Ютазы районы. Колхозчы Захар Егорович Тимошин бәхетеннән нишләргә белми. Чәчүгә тырышып әзерләнгәне һәм «дирбияне яхшы ремонтлаган өчен», аңа 60 сумлык сәгать тапшыралар. Комбайнчы Шитов та хәзер хәлле кеше. 270 гектар бодай урганы өчен, ул күрелмәгән затлы әйбер – патефонга ия була. Колхозчы Шәмсия Хәсәнова язгы чәчүгә яхшы әзерләнгәне өчен, тагын да кыйммәтлерәк бүләк – тегү машинасына лаек дип табыла.

Массакүләм репрессияләрдән, крестьян чыгышларыннан һәм авылның хәерчелеккә төшүеннән әле күп вакыт үтми, шулай да колхозлардагы үзгәрешләр инде күзгә күренә. Эш итү тактикасын үзгәртеп, большевиклар барыбер күмәк хуҗалыкларны дәүләт өчен гарантияле азык-төлек тәэминатчылары итүгә ирешәләр. Вазгыятьне нәрсә бәрабәренә үзгәртергә мөмкин була соң? Мөгаен, егермебишмеңчеләр хәрәкәте дә (ул вакытта Татариягә колхозлардагы эшне оештыру өчен 400 эшче җибәрелә), партияле колхозчы-агитаторларның тырышлыгы да үз ролен уйнамый калмагандыр. Шулай ук колхоз строеның өстенлекләре турында армый-талмый сөйләп килгән газеталарның да. Әмма менә нәрсә мөһимрәк: тоташ мәҗбүриләүгә алмашка уйланыбрак эшләнгән чыбыркы һәм прәннек сәясәте килә.

Крестьянга тыйнак кына сайлау хокукы бирелә. Илдә тоташ дефицит һәм карточка системасы, ә яхшы эш өчен хәзер инде күлмәклек, сәгать яисә савыт-саба алырга була, хезмәт көне өчен – берничә килограмм ашлык. Начар эшләгән, ашлык югалткан өчен – корткыч һәм күмәк хуҗалык милкен талаучы келәймәсе сугыла, шулай ук 10 елга сөргенгә сөрергә дә мөмкиннәр...

Тагын бер стимул – социалистик ярыш (дөрес, ул нәтиҗәлелеге буенча капиталистик көндәшлеккә җитә алмый әле). Ләкин иң мөһиме: хәзер авылдан алып кына калмыйлар. Машина-трактор станцияләре оештырыла, трактор һәм комбайннар саны арта. Татария белән Мәскәү өлкәсе арасында килешү төзелә, аның буенча колхозларга һәм совхозларга эре предприятиеләр шефлык итә. Техника, акча, кадрлар белән булышалар. Бушлай түгел, әлбәттә, – бөтен авыл хуҗалыгы продукциясе (үз ихтыяҗларына һәм экспортка киткән өлештән кала) Мәскәү өлкәсенә озатыла.

1934 елның гыйнварында Татарияне Ленин ордены белән бүләклиләр. СССР ҮБК Президиумы карарында хәбәр ителгәнчә: «Төп авыл хуҗалыгы эшләрен (чәчү, урыпҗыю, орлыкка салу) башкарудагы, колхозларны һәм совхозларны ныгытудагы һәм дәүләт каршындагы бурычларны үтәүдәге гаять зур уңышлары өчен».

Икенче бишьеллык ахырына республикада 3,8 меңнән артык күмәк хуҗалык исәпләнә инде.

СҮЗ АХЫРЫНДА

Урта хәлле исәпләнгән бабам Мифтах Бикмөхәммәтов 1932 елда кулак буларак сөрелсә дә, бәхетле билет тартып чыгара. Казанга килеп җитеп, милициягә эшкә урнаша һәм тартып алынган – дөресрәге, таратып бетерелмәгән мал-мөлкәтен кире кайтаруга ирешә... Бу турыдагы документ бүгенгә кадәр гаилә архивында саклана. Авылга бабай башка әйләнеп кайтмады, гәрчә гомере буена җирне, крестьян тормышын сагынып яшәсә дә. Мөгаен, үз туган нигезләреннән куылган дистә меңләп башка булдыклы кешеләр кебек үк. ГУЛАГ лагерьларында харап булган, махсус поселениеләрдә исән кала алган, Магнитканы төзегәннәр кебек үк. Күпләгән язмышларны пыран-заран китергән бөек социаль экспериментның нәтиҗәсе аянычлы: колхозлар утызынчы елларда ничек тиз төзелсә, туксанынчы елларда шулкадәр үк тизлек белән юкка да чыкты...

Җиргә чын хуҗа әле бүген дә фаҗигале рәвештә җитми. ▪

«Татарстан» журналының махсус проекты

40нчы еллар

БУЫННАР

ҖИҢҮЧЕЛӘР БУЫНЫ

40нчы еллар буыны язмышына сугыш белән сыналу туры килә. Бөек Җиңүдән соң узган 75 ел эчендә инде барысы да сөйләнелгән кебек: татарстанлылар кайларда сугышкан, кемнәр фронттан кайта алмаган, җиңү өчен тылда ничек көрәшкәннәр... Шуңа да карамастан, һәрвакыт ниндидер архивларда, әбиләребезнең хәтер сандыгында, эзләнү эшләре алып барылган сугыш урыннарында Бөек Ватан сугышының яңа вакыйгалары ачыла, дөньяга чыга, һәм алар безгә батыр якташларыбыз турында әлегә белмәгәннәребезне кайтара. Сугыш елларында Татарстан ничек яшәгән?* Фронтка күпме доброволец киткән? Һәлак булучылар исемлеген кемнәр тутырган? Тыл хезмәтчәннәре үтә ярлы паёкка ничек яши алган?

ХРОНОГРАФ

1941

- Казан оборона комитеты төзелә.

- Сугышның унынчы көненә Казанга яралылар төялгән беренче эшелоннар килә. Көзгә кадәр 70 тән артык мәктәп, техникум, тулай торак, клуб, шифаханә, ял йорты госпиталь итеп җиһазландырыла

- Казан хәрби госпиталендә (эвакогоспиталь №361) яралылар өчен сугышның беренче көннәрендә үк 2320 урын әзерләнә. Дүрт елда биредә 32384 кеше дәвалана, 13000 операция ясала

- Татарстан Язучылар берлегендәге 53 әгъзаның 25е фронтка китә

- СССР Фәннәр академиясенең 5 меңнән артык хезмәткәре гаиләсе белән бергә Казанга эвакуацияләнә. Алар арасында 39 академик, Фәннәр академиясенең 44 мөхбир-әгъзасы була. Хәрби тематика һәм фундаменталь фәнни тикшеренүләр буенча эш җәелдерелә

- Дәүләт оборона комитеты Идел саклану сызыгын төзү турында карар кабул итә. Татарстан территориясендә саклану корылмалары ярымбоҗра булып Казан тирәли – Апас, Буа, Кайбыч, Тәтеш һәм кайбер башка районнарда төзелә

- Серго Орджоникидзе исемендәге 124 нче завод территориясенә С.П. Горбунов исемендәге 22 нче Мәскәү авиация заводы күчерелә. Пе-2 бомбардировщиклары җитештерелә башлый. Сугыш азагына кадәр фронтка 10 меңнән артык Пе-2 озатылачак

- Казанга эвакуацияләнгән 16 нчы заводта Пе-2 бомбардировщиклары өчен моторлар җитештерелә башлый

- «Комсомолец Татарии» танк колоннасын төзү өчен акчалар җыю башлана

* 40 нчы еллар буыны турында тулырак – журналыбызның 2019 елның май санында.

1942

- Чистайга эвакуацияләнгән Икенче Мәскәү сәгать заводы базасында хәрби хронометрлар җитештерелә башлый. Татарстанга барлыгы 70 тән артык завод һәм фабрика эвакуацияләнә
- Идел рокадасы – Зөядән алып Сталинградка кадәр тимер юл төзелә һәм файдалануга тапшырыла. Ул Идел буендагы шәһәрне саклаучыларга зур ярдәм була. Аның буенча Сталинградка өстәмә гаскәрләр җибәрелә, корал һәм сугыш кирәк-яраклары тутырылган эшелоннар бара
- Татарстан сәнәгатенең тулаем продукциясе күләме, сугышка кадәрге 1940 ел белән чагыштырганда, 2,4 тапкырга арта
- Илдә бердәнбер булган Казан кинопленка фабрикасында һава разведкасы алып бару өчен аэрофотопленка җитештерү дүрт тапкырга арттырыла

1943

- Казаннан Сталинградка шәһәрне торгызу өчен йөк төялгән беренче эшелон китә
- Шөгердә беренче сәнәгать нефте табыла
- Казанда, В. Глушко җитәкчелегендәге тәҗрибә-конструкторлык бюросында, илдә беренче РД-1 сыекчалы реактив двигателе ясала

1944

- Бөтенсоюз социалистик ярышындагы уңышлары, хезмәттәге батырлыклары өчен Татарстанның 22 предприятиесенә тантаналы рәвештә Дәүләт оборона комитетының Кызыл байраклары тапшырыла
- Татарстан сәнәгатенең тулай продукциясе күләме сугышка кадәргедән өч тапкырга арта. Фронт ихтыяҗлары өчен 600 дән артык төр продукция җитештерелә: самолетлар, бронекатерлар, корал, сугыш кирәк-яраклары, «Катюша» өчен реактив снарядлар, оптик төзәгечләр… Сугыш елларында ТАССРда җитештерелгән кием-салым һәм аяк киеме өч миллионлы армиягә җитәрлек була
- Берлиндагы Плетцензее төрмәсендә шагыйрь Муса Җәлил җәзалап үтерелә

Сугыш ветераны Раиса Романова.

Фото: Александр Эшкинин

1945

- Сугыш вакытында Татарстан илебезгә барлыгы 131 миллион пот икмәк бирә. Шул ук чорда дәүләткә 59 миллион пот ит, 39 миллион пот бәрәңге һәм яшелчә, 200 миллион литр сөт тапшырыла
- «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын торгызу буенча кичектергесез чаралар турында» партия ҮК Карары кабул ителә
- СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалын ачу турында хөкүмәт карары чыга

1946

- Казан моторлар төзү заводында РД-20 авиация реактив двигателен җитештерү үзләштерелә

1947

- Казан авиация заводында Ту-4 бомбардировщигы җитештерелә башлый

1948

- Ромашкино нефть ятмасы ачыла

Ә ИРТӘГӘ СУГЫШ ИДЕ...
БЕР МӘКТӘП АЛЬБОМЫНЫҢ ТАРИХЫ

Фотоальбомны ТР Милли музее тәкъдим итте

Без Казандагы 90 нчы кызлар мәктәбе укучыларының Бөек Ватан сугышы еллары чорындагы альбомын ачабыз. Аны рәссам Ф.Купцов бөтенләй бушка төзегән – фотоларны ябыштырган, каләм белән тип-тигез итеп хәрефләрне, хәзергечә әйтсәк, инфографиканы ясаган. Бик матур һәм самими, кай ягы беләндер дембель альбомына охшаш булып чыккан ул.

Бу мәктәп 1936 елда ачылган. 1942 елда 10 сыйныфны тәмамлаган беренче укучыларын чыгарган. Малайларны шунда ук фронтка озатканнар. Аннан соңгы битләрдә алар инде – «Бөек Ватан сугышында катнашучылар» буларак – мәктәпнең һәм сыйныфташ кызларының горурлыгы. Чыгарылышның беренче партиясен сугышка озатканнан соң, 1943 елдан мәктәп кызларныкына әверелә, ә герой-чыгарылышны фронттан көтәр кешеләр була. Ә альбомда шундый юллар барлыкка килә: «Безнең мәктәп укучылары фронтка доброволец булып киттеләр: алар 10 нчы сыйныф укучылары Нәзиров Р., Карпов Н., Моратов Р., Галимов И...» Карпов һәм Галимов, сүз уңаеннан, сыйныфташ кызлары янына әйләнеп кайтмаган. Аннары фронтка кызларны да ала башлаганнар: «Кызыл Армия сафларына чакырылган кызлар да сугыша: Сергина А., Булатова С., Туктарова И., Бикмуллина...» Чакырылыш яшенә җитмәгән башка кызлар фронтка булыша, тимурчылар булып эшли, госпитальгә шефлык итә...

Сугыш тарихының нәни генә бер кисәген үзенә сыйдырган бер мәктәп альбомы тарихы бу нибары. Әлеге тарих бүгенге көндә мәктәпне тәмамлаучыларның барысына да багышлана – бервакыт, зур кешеләр булгач, тормышыгызны азга гына булса да яңадан күздән кичерәсегез килгәч, мәктәп альбомыгызга күз салыгыз... Һәм тормышыгыз яңадан кабатлансын, ә сугыш – кабатланмасын.

Участники Отечественной войны.

Школа готовит убежденных, стойких, непобедимых борцов за Родину!

Преподавательница Ревина и учащиеся Назиров, Михайлов, Бикмуллина, Туктарова-зенитчица имеют правительственные награды „За отвагу" и др. отличительные знаки.

Ученик Галимов И.

Преподават. Ревина Л.К.

Участники Отечественной войны.

За весь период войны наши ученики и коллеги вели переписку со школой. В своих письмах они рассказывают о военных походах и о своем участии в них. В письмах с восхищением вспоминают всех своих преподавателей, которые воспитали их такими патриотами

„Я много думаю о школе и вспоминаю про школьную жизнь. Она оказывается самая интересная. Она научила бороться. Все думаешь, как бы лучше расправиться с фрицами, чтобы другие могли спокойно учиться и работать по старому...". (из письма Галимова.)

„....Передайте привет Ольге Андреевне, я перед ней, оказывается, был неправ, заявляя, что немецкий язык мне знать не к чему, дипломатом я не буду. Привет Марии Гавриловне и скажите ей, что теперь-то я знаю, что значит лесисто-болотистая местность, а то в школе я никак не запоминал." (из письма Назирова)

уч-к Муратов Р.

ученик Ахмадуллин Р.

Из сочинений учащихся

„Теперь можно сказать, мы стоим на пороге жизни. Мы все должны видеть жизнь в действительности. Говоря о жизни хочется повторить слова А.П. Чехова: „Жизнь дается только раз, и хочется прожить ее бодро, осмысленно, красиво" (уч-ца Муратова - X класс).

„Мы будем стойкими борцами за счастье своей Родины, за независимость советского народа" (уч-ца Калинина - X класс).

„Я преклоняюсь перед красивым. Жизнь без красоты для меня не имеет смысла. Самое красивое для меня - это книги, музыка, природа. Читая книгу, я вижу ее героев, обстановку, их глаза, жесты, мимику, слышу их голоса. Но когда я вижу на экране, я еще полнее и сильнее чувствую их жизнь, стремления и характеры. Кинокартины производят на меня сильное впечатление. Они учат жить, воспитывают. Моя мечта — стать кинорежиссером" (уч-ца Мишина - X класс)

VI-е классы писали сочинения по открыткам. Описание открытки с употреблением наречий, для закрепления темы „Наречие". Писали сочинение „День победы". Шестиклассницы заканчивают сочинения патриотическими восклицаниями: „Да здравствует народ-победитель! (Озолина). „Да разве есть на свете такая Армия, которая превосходила бы русскую!" - (Нигматзянова). „Великий день - самый радостный из радостных дней!" - (Абдуллина Роза). Вот сбылись слова великого Вождя: „Будет и на нашей улице праздник!" (Бухараева).

Связь с фронтом

За время войны пионерская дружина поддерживала крепкую связь с фронтовиками.

Эта связь выражалась в переписке с фронтовиками. С начала войны получено 400 писем фронтовиков, а послано более 1000 писем.

Связь выражалась и в беседах с фронтовиками, которые проводились на сборах, посвящённых встрече с фронтовиками.

Шефство

Пионерская дружина шефировала над госпиталем №1311 и батальон. выздоравливающих №28. Проведено 67 концертов художественной самодеятельности в госпитале и 48 концертов в батальоне выздоравливающих.

Починили 9800 пар белья, за что получили благодарность от командования воинской части п/п 73443.

Сшили 345 пар варежек из шинельного сукна, за что также получили благодарность.

1940нчы еллар

КАЗАННАН
КОСМОСКА КАДӘР

1940 нчы еллар. Илебездәге гамәли космонавтикага нигез салучы Сергей Королёв та, башка галимнәр белән бергә, Казан «шарашкасында» эшли. Нинди хисләр кичерә, нәрсә турында хыяллана икән ул? Дистәләрчә елдан соң Королёв йөргән эзләрдән үтеп, шуны аңларга тырышып карыйк әле.

Лядов урамы, 5нче йорт, 100нче фатир – биредә Королёв яшәгән!

Бүген Лядов урамы, 5нче йортта ниндидер атаклы шәхесләр яшәвен хәтерләткән бернәрсә дә юк диярлек – кайчандыр активистлар кадаклап куйган «Биредә Королёв яшәде» пластик табличкасы гына боегып тора.

«БИРЕДӘ КОРОЛЁВ ЯШӘДЕ»

Зур, бик якты бүлмә. Кояш нурларына чумган! Җиһазлардан – карават, ашъяулык урынына җәймә ябылган аш өстәле, язу өстәле, бер-ике утыргыч, тумбочка. Кирәк-ярактан – өч пыяла банка, ике шешә, кружка һәм чәй кашыгы. Менә, бөтен байлык шул! Көлкеме? «Минем үземә дә көлке шул. Тик мин бер дә кайгырмыйм... Бу бит тормышта мөһим түгел һәм, гомумән, болар барысы да вак-төяк кенә», – дип язган Королёв туганнарына үзенең – ниһаять! – иректә тормышы хакында.

Әйе, ул Казанда иреккә тиенгән – 1944 елның 27 июлендә «шарашкадагы» башка галимнәр белән бергә аны да вакытыннан алданрак азат иткәннәр. Хәер, бу ирек шартлы булган: паспорт урынына – азат ителү турындагы белешмә, тик ул күп хокуклардан мәхрүм итә – кеше сайлауда катнаша, демонстрациягә чыга алмый, атна саен «Черек күлдә» теркәлү мәҗбүри... Әмма Королёв барыбер шат. «Мин элегрәк (сугышка кадәр) тормышның гүзәл мизгелләренең кадерен белмәгәнмен икән, хәзер исә кояш нурының да, бер йотым саф һаваның да, каткан икмәк кыерчыгының да никадәр кадерле икәнен аңладым», – дип язган ул алдарак искә алынган хатында.

Ул гомере буена шундый талымсыз булып калачак. Беркайчан да тормыш авырлыгыннан зарланмаячак. Бернәрсә дә тупламаячак, әйберләрен кадерләмәячәк. Әмма Колымадан алып кайткан алюминий кружкасын гомере буе саклый. Казаннан нәрсә алып кайтты икән соң ул? Үзе өчен һәм бөтен бу дөнья өчен бәһасез нәрсәләрне – континентара баллистик ракета төзү буенча тәүге сызым һәм исәпләүләрен, диләр.

Лядов урамы, 5нче йорт, 100нче фатир – Королёвның Казан адресы менә шундый. Алтынчы подъездга керү ишегә бүген магнитлы йозакта. Әмма без шулай да түр ишектән кереп йөрүен күз алдына китерик: шул ук баскыч басмалары, шул ук култыксалар... Бишенче кат, мәйданчыкта дүрт фатир – безгә сулга. Йөзенче номерлы ике бүлмәле фатирга аяк басабыз – менә ул тәрәзәләр! Һаман шулай ук кояш нурларына чумып утыралар. Тәрәзәдән күренеп торган балалар бакчалары да, каршыдагы арка да шул ук, чын, барысы да сакланган, тәрәзә төбендәге биек каенны гына кискәннәр...

Королёв бу фатирның бер бүлмәсендә яшәгән. Икенчесендә кем соң? Мәгълүматлар төрле. Үзенең гаиләсенә ул «тагын бер иптәшем белән яшим», дип яза. Соңрак аның кызы Наталья үзенең китабында инженер Шнякин исемен атаячак. Әмма йортта яшәүчеләр конструкторның күршесе НКВД хезмәткәре булуын хәтерли, дөрес, ул конвой булудан бигрәк сакчы ролен үти. Күрше фатирда Глушко яшәгән. Бөтен подъезд «шарашканың» элекке тоткыннарына бирелгән булган! Хәер, бүген биредә ниндидер атаклы шәхесләр яшәвен хәтерләткән бернәрсә дә юк диярлек – кайчандыр активистлар кадаклап куйган «Биредә Королёв яшәде» пластик табличкасы гына боегып тора. 100 нче фатир да хәзер буш, дип сөйлиләр. Бәлки, аны кем-

Автор:
Ольга Туманская

Фото: Александр Ефремов

дер инде, киләчәктә бәһасезгә әйләнәсен аңлап, күптән сатып алгандыр?

ЙОЛДЫЗЛАР ИРЕКТӘН КАДЕРЛЕРӘК

Безнең көннәр. Моторлар җитештерү заводы ишегалды. Капка төбендә үк – КМҖБ эшчеләре койган Королёв горельефы. Совет гамәли космонавтикасына нигез салучы галим сугыш елларында бирεдә эшләгән. Ул монда килергә бик омтылган, хәтта үзенең төрмәдә утыру вакытын аңлы рәвештә озынайткан!

Колыма алтын приискларындагы каторгадан соң Королёв Туполев «шарагасында» – Омскида НКВДның ябык конструкторлык бюросында хезмәт куя. Башка тоткын конструкторлар белән бергә Ту-2 бомбардировщигын чыгаруны җайга сала һәм үзенең вакытыннан алдан азат ителүен көтә. Кинәт ул икенче бер «шарашка» җитәкчесе Валентин Глушконың аны Казанга күчерү артыннан йөрүен белеп ала. Анда реактив ракета двигателен төзү буенча эш алып барыла! Королёв гомере буе шуның турында хыялланмаганмыни? Иреккә чыгу өмете кабынуга карамастан, ул үзе дә Глушко «шарашкасына» күчерүләрен юллый башлый. Королёв Казанга килгәндә, яшерен РД-1 инде әзер диярлек була. Королёвның бурычы – аны самолетка яраклаштыру һәм сынаулар үткәрү. Бер ай эчендә генә дә аның җитәкчелегендә 900 сызым сызыла! Һәм алар барысы да кирәкле булып чыга...



Һәр иртәнә КМҖБнең 4 мең эшчесен Сергей Королёв горельефы каршы ала. Ул беренче совет реактив ракета двигателенең нәкъ менә бирεдә җыелуын һәм шул рәвешле безнең илебезнең ерак космоска тәүге адым ясавын искә төшереп тора.

Менә ул – тимерчыбык сеңерле «хәшәрәт». КМҖБ музеендагы легендар РД-1 установкасы.

КМҖБ музеенда мин әлеге легендар установканы күрдем: тимерчыбык сеңерле хәшәрәт ул. Артында – аны дөньяга тудыручыларның фотосурәтләре. СССР НКВДсының төрмә тибындагы махсус конструкторлык бюросы тоткыннары. Кайсы исемне генә атасаң да, йолдызлы шәхес – Глушко, Королёв, Жирицкий, Севрук, Лист, Чаромский, Стечкин... Музей директоры Гүзәл Габдуллина алар турында сәгатьләр буе сөйли ала.

Сүз уңаеннан, РД-1 двигателе Пе-2 очкычында гына түгел, Лавочкин, Сухой, Яковлевның винтлы самолетларында да сыналган. «Мин капчыктагы мәчене алам дип уйлаган идем, ә капчыкта юлбарыс булып чыкты», – дигән аның турында Лавочкин.

«БУ ТОТКЫННАР ЯШИ...»

Казан авиация заводы. Завод идарәсе бинасы. Әйдәгез, мәрмәр баскычтан дүртенче катка менүебезне һәм сулга борылуыбызны күз алдына китерик. Шаһитләр әйтүенчә, сугыш елларында «шарашка» нәкъ менә шунда урнашкан була.

Яңа тоткын Королёв бирεгә 1942 елның 19 ноябрендә килә. «Киң җилкәле, уртача буйлы кеше, зур түгәрәк башы кыска муенга утыртылганга, гәүдәсе бераз бөкрәрәк тоела. Зур кара күзләреннән акыл сирпелә», – үзенең язмаларында ракетачы инженер Эдельман Королёвны шулай сурәтли. Бу вакытта инде Королёв каторга кичерешләреннән бераз айныган, Туполев «шарагасында» тамагын туйдырган, ә иң мөһиме – үзенең яраткан эшенә әйләнеп кайткан һәм шунлыктан «мөлаем, аралашучан һәм хатын-кызларга ихтирамлы» кеше кебек тоелган. Коллегалары аның ягымлы энергиясен,

Ул заман кешеләре галим-конструкторлар өчен НКВД махсус төрмәсенең яки «шарашканың» Казан авиация заводы идарәсе бинасында урнашуын хәтерли әле. Дүртенче катта – конструкторлык бюросы. Өченчесендә – төрмә тулай торагы.

Фото Казан авиация заводыннан алынды

кешеләрне бурычны хәл итүгә юнәлтә белүен, оештыру осталыгын, ярдәмчел һәм игътибарлы булуын искә төшерә. «Соңрак аңарда пәйда булачак хакимлек итәргә яратучанлык сыйфатлары Казанда бер дә сизелмәде».

Тоткыннар бер кат астарак яши. Королёв бүлмәсендә тагын 23 кеше була. Үзләренә генә йөрергә ярамый, аларны һәр җирдә НКВДның кораллы хезмәткәрләре озата йөри. Бу «шәм» хезмәткәрләр саны тоткыннарныкыннан азрак була, шунлыктан кайвакыт, кирәкле җиргә барыр өчен, сакчының бушавын көтәргә туры килә.

Әмма, махсус төрмәнең эчке тәртибенә карамастан, Глушко тәҗрибә-конструкторлык бюросында мөмкинлекләр дә күп була. Двигательләр конструкторы Алексей Исаев 1942 елда мондагы шартларны күрә һәм икенче бер галим-конструктор Борис Чертокка: «Бу тоткыннар бездән яхшырак яши. Без хыялллана да алмаган стендлары, лабораторияләре, җитештерүләре бар. Аларны саклыйлар, шунлыктан ихластан сөйләшеп булмаячак. Әмма безгә, иректәгеләргә, караганда ашатуын да яхшырак ашаталар. Иң мөһиме – аларның двигательләре күпкә ышанычлырак эшли», – дип сөйли.

Тоткынлыкта интексәләр дә, Казан «шарашкасындагылар» , хыялда гына булса да, үзләре күнеккән тормышта яшәргә тырыша. 1943 елда Королёв һәм Севрукны командирлар ашханәсендә тукланырга күчерәләр, анда исә тәүлегенә 800 грамм икмәк бирелә! Аны Севрук каһвә бөртекләренә алмаштыра, кичләрен исә үз «ресторанына» якын дусларын җыя. «Әйдә, «Риога» барабызмы?» – дип сөйләшәләр торган булалар. Каһвәне отбойга кадәр эчеп утыралар кайвакыт. Тәнәфесләрдә шаян спорт ярышлары оештыралар – кем кемне карават астына төртеп кертә? Аннары китап укыйлар. Китапларны да, каһвәне дә ялланып эшләүчеләр аша табалар, алар тоткыннарга, бөтен кагыйдәләрне бозып, булыша. «Шарашкага» «халык дошманнары» түгел, фидакарь галимнәр ябылуын гади кешеләр яхшы аңлый. Исаев әйтүенчә, Казан «шарашкасында» яшәүчеләр белән ике көн аралашкан арада ул сыеклыклы реактив двигательләр турында күбрәк әйбер белә – һәрхәлдә, Ракета фәнни-тикшеренү институты белән озак вакыт буе хезмәттәшлек итү чорыннан күпкә күбрәк мәгълүмат туплый.

Редакция материалны әзерләүдә ярдәм иткәннәре өчен «КМҖБ» АҖ музеена, Соцгород тарихын өйрәнүче Наталья Урейскаяга рәхмәтен җиткерә.

Цех капкасы ачылыр да, урамга легендар Пе-2 бомбардировщигы тәгәрәп чыгар кебек! Сугыш вакытында нәкъ менә бирелә, Казан авиация заводында, яңа РД-1 тизләткеч установкасы сыналган. Сынауда Королёв катнашкан.

Фото Казан авиация заводыннан алынды

«ПЕШКА» ФЕРЗЬГӘ ӘЙЛӘНӘ

Казан авиация заводының җыю цехы каршында басып торганда, әлеге зур капканың ничек ачылуын һәм урамга... самолет төртеп чыгаруларын күз алдына китерү бер дә кыен түгел. Менә ул Пе-2 бомбардировщигы! Самолет артыннан исә цехтан эшчеләр йөгереп чыга – барысының да үз «Пешкаларының» ферзьгә әйләнүен күрәсе килә.

Сериялэп җитештерелә торган машинаның койрыгына РД-1 реактив двигательле яңа тизләткеч установка куелган. Шуның нәтиҗәсендә самолет тизрәк һәм биектәрәк оча, моның өчен махсус төймәгә генә басарга кирәк! Пилот кабинасында яшь сынаучы – Александр Васильченко. Бу егет – булачак Советлар Союзы Герое. Аның янәшәсендә сынаучы инженер, тоткын Сергеев. Завод эшчеләре әлеге фамилия артына кем яшерелүен 1966 елдан соң гына беләчәк – «Сергеевны» телевизордан күргәч! Әлбәттә, язмада гына – ул чакта Королёв үзе инде вафат...

Эксперименталь очышлар сериясе 1943 елның 1 октябрендә башлана. Бервакыт 7 мең метр биеклектә самолетның двигателе шартлый. Койрык ягына ут каба, һәм ялкын тиз арада кабинага якынлаша. «Сикер!» – дип кычкыра пилот инженерга, биеклекне киметә төшеп, әмма ул баш тарта – авариянең сәбәбен ачыкларга кирәк була. Васильченко яна торган машинаны җиргә утырта ала. Үзе бик каты пешә. Королёвның муены, кулы, йөзе һәм күзе пешә – конструктор сукырая. Берничә көн буе тоташ караңгылыкта яши, әмма, бәхеткә, күзләре ачыла. Реактив двигатель һәм ракета тизләткече төзү эшләрен шәхсән контрольдә тоткан Лаврентий Берия нәкъ менә шул очрактан соң Королёвны очудан тыйган, диләр.

КОНСТРУКТОРГА КАНАТ БИРЕГЕЗ!

Каторгадан һәм махсус төрмәдә яшәүдән соң ирекккә чыккан Королёв Лядов урамындагы фатирында ялгызлыгыннан ләззәтләнә. «Кайтам, кичке ашка тиз генә берәр нәрсә пешереп ашыйм да караватка ятам, бераздан йокыга да талам. Рәхәт!» – дип яза ул әнисенә. Әмма ул махсус конструкторлык бюросында эшләвен дәвам итә – көненә 15–18әр сәгать баш ватарга туры килә.

Эшкә Королёв 9 нчы трамвай белән бара алган – ул йорты каршысында ук тукталган. Әмма трамвай бик начар йөргән, сәгать саен диярлек ватылган. Шәһәргә чыгасы булса, Соцгородтан Казанга сәяхәт ике сәгатькә сузылган. Тик Королёв шәһәрдә сирәк булган, эшкә исә трамвайсыз, җәяү дә барып җитеп була – нибары 15 минут вакыт кирәк!

Кайсы юлдан барган икән ул? Әйдәгез, күз алдына китерик әле. Подъезддан чыккач, каршыдагы йортның аркасы аша үтеп, «Крылья Советов» паркына керәсең. Озак аллеядан бераз баргач, сулга борыласың. Елның бөтен фасылында да матур, ышык, кошлар сайравына күмелгән парк илһамландыра. Бүген Королёвны мондагы агачлар гына «хәтерлиләр» инде. Берьялгызы гына аллеяләр буйлап йөргән конструктор нәрсә турында уйлаган икән? Иптәшләре белән бергәләшеп өйгә кайтканда, нәрсә турында сөйләшкәннәр?

Кайчандыр, 1929 елда, ул Циолковскийның «Исследование мировых пространств реактивными приборами» китабын укыган һәм планер белән самолетларда гына түгел, атмосферадан узып та очып булуны аңлаган. Әлеге идея – кешелекне яңа биеклеккә алып чыгу – Королёвны озак еллар буе илһамландырган. Ә менә бирелә, Казанда, ниһаять, ул бу идеяне тормышка ашырып булуга ышанган. ■

Автор Николай Морозовның «Предчувствие космической эры» документаль фильмы материалларын, Анатолий Эдельманның «Записки инженера-ракетчика» хатирәләрен, Наталья Королёваның «Отец» китабын, Королёвның хатыны Нинага язган хатлары тупланган «Королёв. Горизонт событий. Нежные письма сурового человека» җыентыгын, Борис Чертокның «Ракеты и люди» хатирәләрен файдаланды.

БЕЗ БЕЛГӘН **ШҮРӘЛЕ**

1945 ел. Сугыш. Җиңүгә кадәр тагын ике ай калган. Ә Казанда – премьера! «Шүрәле» – беренче татар балеты...

Автор:
Ольга Туманская

Фотолар Муса Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театрының музей архивыннан алынды

ЧЫНГА АШМАГАН ХЫЯЛ

1939 ел. Урамда атлар пошкыруы, тояк тавышлары ишетелгәли, ул да түгел шалтырап трамвай уза, кешеләр сөйләшүе колакка керә. Кинәт кенә әлеге гадәти ыгы-зыгыны шомлы, гаҗәеп матур музыка боза. Үтеп баручыларның кайсыдыр борылып карый. Көйнең кайдан килүен эзли. Өстән! Зур кунакханә тәрәзәләре аша моң агыла. Кунакханә бүлмәләренең берсендә рояль артында бөдрә чәчле егет утыра – 25 яшьлек Фәрит Яруллин...

Әгәр үз вакытында Мәскәү консерваториясе профессоры, күренекле педагог Генрих Литинский Фәрит Яруллинны күреп өлгермәгән булса, гаҗәеп «Шүрәле» балеты туар идеме икән? Генрих Ильич аны болай дип искә төшерә: «Яруллин бик тирәнгә яшерелгән, кулланылмый яткан гаҗәеп бай фантазиягә ия искиткеч талантлы кеше. Әлеге сәләтне киләчәк белән тартып чыгарырга кирәк. Һәм, әгәр бу тормышка ашса, гаҗәеп матурлык туачак иде».

Сүз уңаеннан, «Шүрәле» балетын язу идеясе үзе Литинскийга бәйле. Тукай әкияте белән танышканнан соң, ул әлеге әсәр белән шулкадәр илһамлана ки, яраткан укучысына, сынап карау нияте белән, аның беренче өзекләрен язарга бирем бирә. Нәтиҗә укытучыны канәгатьләндерә, шуңа күрә ул яшь шагыйрь Әхмәт Фәйзигә либретто язу үтенече белән мөрәҗәгать итә. Эш кызып китә!

– Яруллин беренче картинаны тәмамлый, аннан икенчесен. Биюгә яраклашуы, тәэсир итү көче буенча көйне мактап бетереп булмый, – дип яза Генрих Литинский Казанга, балетмейстер Гай Таһировка язган хатында, һәм шунда ук аны автордаш-хореограф булырга чакыра.

Литинский, әлбәттә, Гай Хаҗиевичның инде «Шүрәле» балетына язган сценарие барлыгы турында белми. Дөрес, сценарий бер генә актлы була, дип раслый балетмейстерның биографы Владимир Горшков: алай гына да түгел, Таһиров версиясен театр җитәкчелеге булачак постановканың нигезе итеп кабул иткән була. Әмма, бераз уйлаганнан соң, Таһиров шундый фикергә килә: кемнең «Шүрәле»се кызыклырак булуы турында Литинский белән бәхәсләшмәвең хәерлерәк. Һәм ул Литинскийның тәкъдимен кабул итә.

Балет буенча эшләргә талантлы Ленинград балетмейстеры Леонид Якобсонны да чакыралар. Эш шунда: «Шүрәле»не 1941 елда Мәскәүдә үтәргә тиешле Татар сәнгате декадасы программасына кертү турында карарны махсус комиссия кабул итә. Үтә дә җаваплы эш! Якобсон беренче һәм өченче актларны куярга тиеш була. Фәйзи либреттосы белән танышканнан соң, ул аны йомшаграк дип таба һәм сценарийны шактый үзгәртеп язарга уйлый. Бу хәл Яруллинны көйне дә үзгәртергә мәҗбүр итә. Гаҗәеп көч, киеренкелек сорала! Өстәвенә, бик кыска вакыт эчендә.

...Һәм менә ул Университет белән Бауман урамнары чатында урнашкан «Совет» кунакханәсендә – номерга рояле белән бергә бикләп куелган. Бернинди чикләүләрсез иҗат итү шарты белән. Ул иҗат итә дә, ә инде киеренкелек тәмам чиктән ашканда, ялгызлыгыннан яңгыр торбасы буйлап төшеп кача. Хәер, кунакханәдәге «тоткыннар»дан ул берүзе генә булмый. Тулы бер катны татар мәдәнияте эшлеклеләре били – барысы да Декадага әзерләнә. Җиһанов «Алтынчәч» операсы буенча эшли, Мозаффаров «Галиябану»ны яза. Эшләргә куратор итеп әлеге дә баягы Литинский билгеләнгән була. Һәр иртәне Генрих Ильич номерлар буйлап йөри, тикшерә, төзәтә, мактый, орыша...

Әлбәттә, 25 биючедән торган труппага – Татар опера театрының балет составы ул вакытта әнә шуның кадәр кешедән тора – мондый көчле куелыш буенча эшләве бик авыр була. Татария җитәкчелеге башкаладан «Остров танца» дип аталган күренекле хореография театры коллективын, һәм шулай ук Мәскәү һәм Ленинград балетларында иҗат иткән танылган осталарны чакыра. Нәтиҗәдә Казан театры труппасы



Личный листок

по учету кадров

1. Фамилия ЯРУЛЛИН

Имя Фарид отчество Загидуллович

2. Пол муж. 3. Год, число и м-ц рождения 1 января 1914 г

4. Место рождения г. Казань (село, деревня, город, район, область)

5. Национальность татарин 6. Соц. происхождение служащий-музыкант

7. Партийность б/п партстаж (месяц и год вступления) партбилет к/карточка №

8. Состоите ли членом ВЛКСМ, с какого времени и № билета

9. Образование высшее

Название учебного заведения и его местонахождение	Факультет или отделение	Год поступления	Год окончания или ухода	Если не окончил, то с какого курса ушел	Какую специальность получил в результате окончания учебного заведения, указать № диплома или удостоверения
Казанское музыкальное училище	класс виолончели	1930	1933		
Рабфак при Мос. консерват.	кл. композ.	1933	1934		
Тат. оперная студия Москов. консерватории	класс композиции	1934	1938		композитор

10. Какими иностранными языками и языками народов СССР владеете русский, татарский (читаете и переводите со словарем, читаете и можете объясняться, владеете свободно)

11. Учёная степень, учёное звание

12. Какие имеете научные труды и изобретения Балет "Шуралэ" в 3-х действиях. Песни о комсомоле, о Родине, Романсы /21 название/, обработка татарских, башкирских песен/12 назв./ Инструментальные произведения /12 назв./ Симфония № 1/2 части/

13. Выполняемая работа с начала трудовой деятельности (включая учебу в высших и средних специальных учебных заведениях, военную службу, участие в партизанских отрядах и работу по совместительству).

При заполнении данного пункта учреждения, организации и предприятия необходимо именовать так, как они назывались в свое время, военную службу записывать с указанием должности.

Месяц и год: вступления	Месяц и год: ухода	Должность с указанием учреждения, организации, предприятия, а также министерства (ведомства)	Местонахождение учреждения, организации, предприятия
1931	1932	Пианист и виолончелист Казанского театра рабочей молодежи – ТРАМ	Казань, ул. Плетнева клуб им. Вахитова
1932	1933	Пианист-концертмейстер Татарского радио-центра /совмещал с учебой/	Казань ул. К. Маркса д.36
1934	1938	Учеба в оперной студии при Мос. Консерватории	Москва ул. Герцена д.9
1939	1941	Тат. гос. театр оперы и балета композитор	Казань ул. Баумана 48 Большой театр
1941 июль	1941 сент.	Ульяновское пехотное училище курсант	
1942	сентб.	Действующая армия лейтенант командир стрелкового взвода 19 Танкового корпуса	

90 кешегә кадәр арта. Эш гөрли! Якобсон үзенең актларын Мехчылар клубында кабатлый һәм репетицияләргә Таһировны кертми. Моны ул гаять зур дулкынлануы белән аңлата.

«Шүрәле» премьерасының вакытын сугыш башлануы боза – тиз арада җиңүгә ирешергә насыйп булмый. Театрның штатын яңадан кыскарталар, балет труппасында бары тик җиде генә кеше кала. Таһиров урман кисү эшләренә чакырыла, аннан соң – Казан тирәли ныгытмалар төзелешенә. Яруллин фронтка китә. Литинский яраткан укучысын сугышка җибәрмәс өчен бик зур көч куя. Ул Яруллинны тылга кайтарту максатында нинди генә инстанцияләргә мөрәҗәгать итми, чөнки аның укучысы – «күренекле композитор һәм татар милли мәдәнияте өчен гаять зур байлык булып тора». Ләкин Литинскийның омтылышлары, тырышлыклары максатына ирешә алмый – Фәрит Яруллин сугышның иң хәтәр урыннарында – әле Курск дугасында, әле Белоруссия өчен барган бәрелешләрдә катнаша. «Минем «Шүрәле»не шулкадәр сәхнәдә күрәсем килде. Бер генә күзем белән булса да... Аның музыкасы миндә яши, ул һәрвакыт минем белән бергә», – дип яза композитор «Шүрәле» турында үзенең хатыны, балет артисткасы Галина Сачекка. Ләкин юк, әлеге хыялларга тормышка ашарга насыйп булмый...

БИИБЕЗМЕ... АВЫЛЧА?!

– Аякларың бармы?
– Бар.
– Ыштан киеп йөри аласыңмы?
– Алам.
– Димәк – артист!

Тарих битләренә теркәлгән контексттан аерып алынган әлеге сөйләшү елмаю уятырга мөмкин, моның сугыш вакытында Казанда ачылган күпләгән госпитальләрнең берсендә барган сөйләшү икәнлеген аңламаганда, әлбәттә. Гай Таһиров яраланган солдатлар арасында биюче барлыгын ишетә һәм тизрәк йөгерә – кадрлар мәсьәләсен хәл итәргә! Сугыш вакытында ир-атлар арасында биючеләргә кытлык бик зур була. Кайчак ирләр партияләрен хатын-кызлар башкарырга мәҗбүр. Тамашачылар искә төшерә: кайвакыт артисткалар, зал алкышлый башлагач, үзләренең мәһабәт ирләр образларын башкаруларын онытып, реверанс ясыйлар. Яшь аралаш көлүләр әнә шунда була да инде.

Заманы никадәр генә авыр булса да, Таһиров «Шүрәле» турында уйлый, онытмый. Вакытын бушка уздырмый: балет студиясе студентлары белән шөгыльләнә, тәҗрибәле артистларның осталыгын чарлый, фольклор экспедицияләренә йөри. Бервакыт шундый сәяхәттән гаять зур табыш белән кайта – 52 халык биюе! Барысын да эшкә җигә. Фольклор буенча әлеге тәҗрибә Гай Хаҗиевичка «Шүрәле»нең икенче актын сәхнәләштергәндә бик кирәк булып чыга – тамашачы каршында үзенең бөтен матурлыгы һәм үзенчәлеге белән татар авылы килеп баса. Безнең төбәк өчен шулкадәр кадерле, якын көйләр һәм образлар киләчәктә балетка тагын да җәтерәк төсләр өстәячәк.

«ШҮРӘЛЕ» ДӨНЬЯ БУЙЛАП АТЛЫЙ

…Бары тик 1944 елда гына, гаять зур тырышлыклар нәтиҗәсендә, Татар опера һәм балет театры кабат «Шүрәле»гә алына. Биючеләрнең күпләренә әле бу вакытта 16 яшь тә тулмаган, оркестрга уен кораллары гына түгел, музыкантлар да җитми. Халык күп булырга тиешле күренешләрдә балет артистлары белән бергә вокаль группаныкылар да уйный. Бу юлы беренче һәм икенче күренешләрне сәхнәләштерергә элек Зур театр солисты, ә 1944 елдан Казан ТЮЗының баш балетмейстеры булып эшләгән Леонид Жуков чакырыла. Икенче күренеш – Таһировныкы.

Сүз уңаеннан, үзе йөргән экспедицияләрдә Гай Хаҗиевич татар биюләрен генә тупламый, халык костюмнарын да җыя. Еш кына театрга Казан артында кия торган костюмнар эләгә. Таһиров балетка татарларга хас пластиканы өсти, биюләргә милли костюмны кертеп җибәрә – «Япмалы бию» дә, Сөембикә ячы костюмын караган музыкаль номер да нәкъ шул рәвешле барлыкка килә.

Балетның төп героинясы булган Сөембикә кош-кыз ролен Анна Гацулина башкара, югыйсә сугышка кадәр ул бары тик кечкенә кошчык ролен генә башкарырга тиеш була. Күп яктан Таһировның хуплавы, аның ярдәме нәтиҗәсендә балетка 29 яшендә килгән, гаҗәеп язмышка ия биюче – татар балетының беренче йолдызы әнә шулай кабына! Кошчык образы репетицияләрендә ул вакытта планлаштырылган Декаданың баш балетмейстеры Гацулинаның яше турында сорагач, исе китеп: «Сез элек кайда булдыгыз соң?» – дип сорый. Гацулина әле тагын егерме ел театр сәхнәсендә балкыячак, таң калган тамашачы, мөкиббән китеп, аның аягыннан ялгыш кына төшеп калган туфлиен сораячак, ә сәхнә арты хезмәткәрләре тактага ясалган спектакль күренешләрен бүләк итәчәк.

«Шүрәле»не куйганда кабынган тагын бер татар балеты йолдызы Бари Әхтәмов булачак. 1945 елның 8 мартындагы премьерада артист Али-Батыр ролен башкара, әмма балет сәнгате тарихына ул иң шәп Шүрәле булып кереп калачак – соңгы көннәренә кадәр Әхтәмов белән дус булган Леонид Якобсон аның турында нәкъ менә шулай язып калдырган. Сүз уңаеннан, балетның алга таба язмышы Якобсон белән бәйле була. Әлеге эше өчен Ленинград балетмейстеры Сталин премиясенә лаек дип табыла.

Казанда узган премьера зур уңыш казана. Һәм Якобсон аны Киров исемендәге Ленинград театрында (хәзерге – Мариинка) сәхнәләштерергә тәвәккәлли. Яңа партитураны Мәскәү композиторлары Владимир Власов һәм Владимир Фере башкара – һәм бу шулай тиеш була да, чөнки Ленинградта һәм Мәскәүдәге Зур театрда балетны өч составлы оркестрлар башкара! Фәрит Яруллинның гаҗәеп музыкасын бөтен дөнья нәкъ менә әлеге куелышта ишетәчәк.

«Шүрәле»нең уңышы искиткеч була. Сөембикә ролен – Майя Плисецкая, Былтыр партиясен Владимир Васильевның башкаруы гына да ни тора! Балет ил буйлап атлый, ул дистәләгән сәхнәдә куела, ә аннан соң, СССР чикләрен узып, Болгария, Монголия, Польша, Чехословакия, Румыния, Албания, Мексика театрлары афишаларын бизи….

– «Шүрәле» – сәхнәдән төшмәячәк әсәр ул, – ди Нәҗип Җиһанов премьера алдыннан балетның куелышын тикшерү комиссиясе утырышында. Бу 1945 елның 6 марты була. Бүген дә, күпме еллар үтүгә карамастан, «Шүрәле» безнең белән бергә Җиңүне бәйрәм итә.

Леонид Жуков – балет артисты, балетмейстер. 1944–1947 елларда Казанда эшли.



Әхмәт Фәйзи – либретто авторы.



Гай Таһиров – 1938–1952 елларда Татар опера театрының баш балетмейстеры.

Материалны әзерләгәндә А. Алмазованың «Фәрит Яруллин һәм аның «Шүрәле» балеты. Тормышының һәм иҗатының өйрәнелмәгән сәхифәләре». В. Горшковның «Гай Тагиров – балетмейстер», Д. Перегулованың «Казанский балет», Л. Донина, Г. Давлетьянова һәм Р. Такташның «Формирование сценических традиций национального балета как отражение идентичности татар», А. Кадыйрованың «Первая прима-балерина республики еще танцует!» дип аталган китаплары файдаланылды.

Редакция Татар дәүләт опера һәм балет театрының музей фондларын саклаучы Галия Акчуринага материалларны әзерләүгә күрсәткән ярдәме өчен рәхмәтен белдерә.

ТЫЮ САЛЫНГАН ТАРИХ

1944 елның августы. Сугышның иң куркынычы чагы артта калды, аның ничек тәмамланачагында инде беркемнең дә шиге юк. Фронтларда һөҗүм бара. Ә идеологик фронтта хәлләр ничек соң? Монда да кул кушырып утырырга ярамый, дошман йоклап ятмый ул! Иң «уңышлы» идеологик һөҗүм операцияләренең берсе Алтын Урдага каршы ясала.

Автор:
Нияз Әхмәдуллин

ШӘРЫК АЛДЫНДА БАШ ИЮ

1944 елның 9 августында ВКП(б) Үзәк комитетының «Татар партия оешмасында массакүләм-сәяси һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» карары дөнья күрә. Әлеге документ дөньяга чыгар алдыннан, республикада идеологик-сәяси эшнең торышын Мәскәү комиссиясе тикшерә. Аның иң кызган чагында җирле газетада ҮК кураторларының ачуын чыгарган тупланма басыла. ВКП (б) ҮК секретаре А. Щербаков исеменә доклад җибәрелә: «Красная Татария» республика газетасы редакциясе бу елның 14 июнь көнендә Берләшкән Милләтләр Оешмасы көненә багышланган махсус сан чыгарды. Газетаның беренче битендә редакция исеменнән: «Бу санны без батыр союзникларыбыз – Бөекбритания һәм Америка Кушма Штатларына багышлыйбыз», – дип хәбәр ителә. Газетаның исеме өстендә АКШ, Бөекбритания һәм СССР флаглары сурәте басылган һәм, моннан тыш, инглиз телендә сәламләү лозунгы бирелгән...» Нәтиҗә: газета «Гитлерга каршы коалиция булдыру һәм ныгыту эшендә Советлар Союзының ролен киметә, совет халкының һәм Кызыл Армиянең Гитлер Германиясенә каршы көрәштәге әһәмиятен түбәнәйтә».

Алга таба эшләр кыза бара. Бер айдан соң Үзәк комитетка чираттагы доклад китә. Бу юлы уяу комиссия Җучи Олысы (Алтын Урда) тарихының «хаталы» бәяләнүе, «Идегәй» эпосы каһарманы – Идегәйнең татар әдәбиятчылары һәм тарихчылары тарафыннан, Алтын Урда хакимиятенә каршы көрәшүче буларак, «бозык» рәвештә күрсәтелүе, татар халкының үткәннәрендәге, аның милли, мәдәни һәм дәүләтчелек тарихындагы «ялгыш» тикшеренүләр булуы сәбәпле, борчылуын белдерә. Болар барысы да совет халыклары дуслыгын ныгытуга комачаулый, Совет власте дошманнары тегермәненә су коя, дип нәтиҗә ясый доклад авторлары.

Иптәшләрнең сүзенә ышанганда, хаталар, чыннан да, куркыныч. Әйтик, Татарстанда «Идегәй» эпосын татар мәдәниятенең иң югары казанышы буларак бәяләргә җөрьәт иткәннәр икән. Хәтта, гөнаһ шомлыгы, Идегәйне Давид Сасунский, «Юлбарыс тиреле витязь» һ.б. белән бер рәткә куялар. Ул гына да түгел, Идегәйне «азатлык көрәше герое» буларак олылап, «Совет әдәбияты» журналында Нәкый Исәнбәт мондый нәтиҗәгә килә: Туктамышка каршы көрәшеп, Идегәй Алтын Урдада мөстәкыйль дәүләтләр, шул исәптән Мәскәү кенәзлеге барлыкка килү һәм бүленеп чыгу өчен җирлек әзерли...

Партия органнарының ачуңәфрәте һәм моның нәтиҗәләре тарих фәне өчен чын мәгънәсендә фаҗига булып чыкты. Урта гасырларның әдәби һәйкәле кинәт кенә Сталин идеологлары кулында тарихны кире язу өчен сәбәп-коралга әверелде... Август карарының бер пунктында түбәндәге юллар бар: «ВКП(б) Татар өлкә комитетына Татарстан тарихын фәнни өйрәнү эшен оештырырга тәкъдим итәргә, Татарстан тарихын яктыртуда (Алтын Урданы мактау, Идегәй турындагы ханлык-феодальлек чоры эпосын популярлаштыру) аерым тарихчылар һәм әдәбиятчылар тарафыннан җибәрелгән җитди җитешсезлекләрне һәм хаталарны бетерергә...»

«ДӨРЕС» НӘТИҖӘЛӘР

Юнәлешләр кичектергесез бирелә, тегермән ташы шунда ук әйләнә башлый. Өлкә комитетының беренче секретаре В. Никитин, Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры Х. Ярмөхәммәтов вазыйфаларыннан азат ителә, аларга шелтәләр белдерелә, кешеләр эштән куыла. Алтын Урда чорын тикшерүчеләренең «хаталары»н ачып күрсәтә торган, язучылар, сәнгать белгечләре иҗатында, галимнәрнең тикшеренүләрендә, идеология өчен җаваплы активлар эшендә «дөрес» басымнар куйган идеологик киңәшмәләр дә бер-бер артлы үтә,

Хәзер инде Алтын Урда, рус кенәзлекләрен талаган, артка сөйри торган феодаль дәүләт буларак, бары тик тискәре рухта гына искә алынырга мөмкин. Татар халкы тарихы рус халкы белән берлектә царизмга каршы күтәрелгән восстаниеләр аша гына яктыртыла, милли азатлык хәрәкәте алгарышка каршы хәрәкәт буларак бирелә. Мәскәү кенәзлегенең һәм Россия империясенең колонизаторлык сәясәтен өйрәнүгә тыю салына. Гомумән, хәзер татар халкының чын тарихы 1917 елгы революциядән соң гына башлана.

ВКП(б) үзәк органы – «Большевик» журналында редакция тарафыннан мәкаләләр басыла. Алардагы төп фикер – «Алтын Урданың ролен, фәнгә каршы килеп, зурайту, матурлау» «бөек идея» – «СССР халыкларының ленинчыл-сталинчыл дуслыгы»нан чигенү булып тора да инде. Ә бу исә «халыклар арасында дуслыкның өзелүенә, Совет дәүләтенең куәтен какшатуга» китерә. Моның белән шөгыльләнергә маташкан кеше «дошманның ярдәмчесенә, бөек эшебезгә аяк чалучыга әверелә». Үнгасулга бер адым ясыйсыз икән, үзегезгә үпкәләгез, янәсе, без кисәттек.

Шундый хәлгә тарыгач, татар халкы тарихы белән нишләргә соң? Алтын Урдада тамырлары юк икән, Идел буенда татар каян килеп чыккан да бүгенге бәхетле көненә кадәр кайда, ничек яшәгән? Алар Тәңренең үзеннән,

Иллюстрация: Тавил Хаҗиәхмәтов

җиде кат күктән туп-туры шушында төшеп утырмаган лабаса! Барлыкка килгән бушлыкны ничек тә булса тутыру өчен, гади генә бер схема уйлап табалар да аны махсус чарада – «Казан татарларының килеп чыгышы турында фәнни сессия»дә (1946 елның 25-26 апрелендә СССР Фәннәр Академиясенең Тарих һәм фәлсәфә бүлеге һәм СССР ФА Казан филиалы белән берлектә үткәрелгән) рәсми ныгытып-беркетеп куялар.

Партия галимнәре Идел буе татарларының нәсел шәҗәрәсе рус халкы кебек үк татар-монгол изүеннән интеккән Кама һәм Идел болгарларыннан гына килә дигән фикердә үзара «килешә». Идел буе Болгары иле Алтын Урда составына вассал дәүләт буларак керә... Казан ханлыгы, имештер, Болгар патшалыгы нигезендә барлыкка килгән, бу исә Алтын Урда таркалу нәтиҗәсендә мөмкин булган. Алтын Урда рус һәм башка изелгән халыкларның көрәше аркасында яшәүдән туктый. Шул рәвешле татар халкы тарихы ул вакыттагы ТАССРның кечкенә территориясе белән чикләнә. Алтын Урданың татар милләте формалашуда зур роль уйнаган бай мәдәнияте белән барлык элемтәләр дә кискен рәвештә өзелә. Нәтиҗәдә, татарлар үткәннәрсез, тамырларсыз кала.

Тарих сәхифәләренең бәяны СССРда алга таба бары тик әлеге идеологик схема гына барды. Соңгы дистә елларда Россия тарихын өйрәнү акрынлап фәнни юнәлешкә салына. Тарих, ниһаять, хакимият хезмәтчесе функцияләреннән арына бара. Бу – катлаулы һәм озак процесс булып чыкты. Күп кенә архивлар ачылды, чит илләрнең тарихи чыганаклары белән танышу мөмкинлеге туды, каты куллы партия, дәүләт цензурасы юк хәзер.

Нәтиҗәдә, илнең үткәнендә күп милләтле тарихның бай төсләрен колачлаган буяулар төрлелеге чагыла башлады. Россия халыклары дуслыгы өчен бернинди куркыныч та юк икән ләбаса. Үзара тигезләр арасында дуслык ныклырак була ул, дип өйрәтә тарих галиҗәнаплары.

«Татарстан» журналының махсус проекты

50нче еллар

БУЫННАР

ЗУР ҮЗГӘРЕШЛӘР БУЫНЫ

50 нче еллар буынына Сталин репрессияләреннән соң күтәрелергә, җимерелгән илне яңартырга, ТАССР нефть сәнәгатен торгызырга, авыл хуҗалыгын депрессиядән чыгарырга туры килә...
Сугыштан соңгы елларда совет Татариясе ничек яшәгән?* Индустриальләшү кем җилкәсенә төшкән? Бөек төзелешләргә ил кемне җибәргән? Авыл хуҗалыгын ничек күтәргәннәр? Торак проблемасын нинди юллар белән хәл иткәннәр?

ХРОНОГРАФ

1951

- Иң атаклы Казан сталинкаларының берсе – Казан финанс-икътисад институты бинасы төзелеше тәмамлана
- 387 нче Казан заводында илебездә беренче вертолёт – Ми-1 җитештерелә башлый

1952

- «Теплоконтроль» заводы сафка баса

1953

- Казанда 22 нче авиация заводында беренче стратегик бомбардировщик Ту-16 серияләп чыгарыла башлый
- Шәһәр тибындагы Әлмәт бистәсенә шәһәр статусы бирелә

1954

- Казанда яңа аэровокзал ачыла
- Булачак күренекле татар җырчысы Илһам Шакиров Казан музыка училищесына укырга керә
- Татарстанның булачак беренче Президенты Минтимер Шәймиев Казан авыл хуҗалыгы институтының беренче курсына укырга керә
- Киләчәктә дөнья күләмендә танылу алачак композитор София Гобәйдуллина Казан консерваториясен тәмамлый
- Казанда Ирек мәйданында – В.И.Ленинга, КДУның төп бинасы каршында студент В.Ульяновка һәйкәл куела
- Казанда тагын бер яңа җитештерү – Компрессорлар заводы эшли башлый

* 50 нче еллар буыны турында тулырак – журналыбызның 2019 елның август санында.

Фото ТР Милли музееннан алынды

1955

- Иске Писмән эшчеләр бистәсе Лениногорск шәһәренә әверелә

1956

- Шагыйрь Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме (үлгәннән соң) бирелә
- Татария нефть табу күләмнәре буенча СССРда беренче урынга чыга
- Казанда Ирек мәйданында Муса Җәлил исемендәге Опера һәм балет театры бинасы кулланышка тапшырыла
- Казанда ТАССР Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе ачыла

1957

- Питрәч районы Әлбәдән авылында туып-үскән Брест крепосте сакчысы Петр Гавриловка Советлар Союзы Герое исеме бирелә
- Куйбышев сусаклагычын тутырганнан соң, су Казанга килеп җитә
- Казанда яңа елга порты ачыла
- Мәскәүдә зур уңыш белән Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасы уза.
- Миңлебай газ-бензин заводының беренче чираты сафка бастырыла
- Очучы Михаил Девятаевка Советлар Союзы Герое исеме бирелә
- Горький (Түбән Новгород) – Казан маршруты буенча беренче «Ракета» юлга чыга

1958

- Кабан күле буендагы скверда Габдулла Тукайга һәйкәл куела

1959

- СССР Бөтенсоюз халык хуҗалыгы күргәзмәсенең ТАССР павильоны уенчыклар павильоны итеп үзгәртелә
- Беренче миллион тонна нефть җир өстенә чыгарыла
- Казан телеүзәге үз эшен башлап җибәрә
- Яшел Үзәндә Серго исемендәге завод беренче «ДХ-120» – атаклы совет «Мир» суыткычын чыгара

САКСОФОН БЕЛӘН КЕРОСИНКА ӨЧЕН СОЛО

Җәй. Эссе. Ресторанның ачык тәрәзәсеннән исерткеч Moonlight Serenade агыла. Янәшәдә, кинотеатр фойесында, Армстронгның On the Sanny Side of the Street җыры халыкны кыздыра. Якындагы театрдан дәртле дә, талгын да Saint Louis Blues ишетелә. Труба, саксофон, бәрмә уен кораллары... Илленче еллар башы. Америкамы? Юк ла! Казан, СССР...

Заманны тояр өчен, аның тавышын һәм исен сизү зарур. Илленче еллар Казаны джаз тавышына күмелгән. Тарихи парадокс: халыклар юлбашчысы әле үзенең соңгы трубкасын да тартып бетермәгән, аның ярдәмчесе Михаил Суслов, космополитлыкны сүгеп, инде төкереген чәчә, ә Иделдәге провинциаль шәһәрдә – искиткеч музыкаль башбаштаклык! Чит илләрдәгечә стильле егетләр, «шанхайлылар» – галстук-күбәләк, модалы пиджактан – Баумандагы «Русское подворье» ресторанында һәм Горький паркындагы бию мәйданчыгында, «Родина» кинотеатрында һәм Офицерлар йортында ачыктан-ачык, яшеренмичә, «юаннар музыкасын» уйный...

Зыянлы буржуаз музыка әле ныгып җитмәгән җаннарны бик ансат кына яулый: Казан мединституты студенты Вася, бер тапкыр джаз әфьюнын татып карагач, гомергә аның колына әйләнә. Аның яшь дуслары белән дә – шул ук хәл. Аннары, күп еллар үткәч, язучы Василий Аксенов исенә төшерәчәк: аның яшьлеге, «кызыктыргыч ерак төнге дөнья утларыдай, әлеге «шанхайлылар» уты белән өртелгән булган» икән бит.

ШАНХАЙ-БЛЮЗ: СОВЕТ ВЕРСИЯСЕ

Котны салучы еланнар – «шанхайлылар» – Казанга Кытайдан кырыгынчы еллар азагында кайтып төшә. «Шәрык илләре свингы короле» Олег Лундстрем җитәкчелегендәге унтугыз кеше, тулы бер бигбенд. Лундстрем, Деринг, Бонарь, Баранович, Модин... Гәрчә башта Татарстанда Лундстремның бердәм джаз-оркестры юк дип саналса да (Ленин-Сталин партиясе сәясәтенә ачыктан-ачык каршы чыгып булмый бит), алдынгы карашлы яшьләр әлеге музыкантларны тиздән урамда таный башлаячак.

Әмма татар дипломатия сәнгате гамәлдә бит әле. Музыкантларны чыгыш ясаудан тыймыйлар, мөмкин булганда, аларны эшкә урнаштыралар, маэстро Лундстрем Казан консерваториясендә укый башлый

(СССРда дипломсыз маэстро партбилетсыз коммунистка тиң бит). Һәм биг-бенд, төркемнәргә бүленеп, әкренләп халыкны «буржуаз агу» белән «агулый». Кинотеатрларда, ресторан һәм клубларда. Билгеле инде, чамасын белеп һәм җиренә җиткереп: программада беренче чиратта – «Катюша», «Голубка» кебек һәм башка ышанычлы совет көйләре джаз эшкәртелешендә яңгырый. Һәм икенче чиратта гына – эшче-крестьян дәүләтенә чит-ят булган Глен Миллер, Дюк Эллингтон, Луи Армстронг җәүһәрләре… Дөрес, кайвакыт биг-бенд тулы составта җыела, һәм шул чакта инде иң бәхетлеләр Шанхайдагы кабатлаган диярлек концерт программасын ишетеп кинәнә…

Җирле чекистларның да музыкаль зәвыгы булган, ахрысы. ТАССР Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгында 1952 елның декабрендә Олег Лундстремның сәяси ышанычлылыгын тикшерү өчен ачылган эштә: «Агентура аны советларга хәерхаһлы, дип саный», – дип теркәлгән.

ЗУР ШӘҺӘР ИСЕ

Лундстрем джазы – Иделдән искән саф җил кебек. Киләчәктә булачак үзгәрешләр җиле ул, әмма әлегә бик зәгыйфь. Казан коммуналкаларындагы әчкелтем исләр, Постау бистәсендәге зәһәр амбре һәм шәһәр читендәге пролетарийлар яши торган йортлар тәрәзәсеннән агылган махмыр сулышын басу әлегә аның хәленнән килми.

Илленче еллар башы Казанны чит ил исләре белән гаҗәпләндереп булмый. Татарстан урамын икегә бүлә торган җирле Унтер-ден-Линден – юкә аллеясенең (җитмешенче еллар башына кисеп бетерелгән) июньдә чәчәккә күмелүе генә ил халкының яртысы өчен сабын кайнатыла торган Вахитов исемендәге химкомбинат чыгарган әчегән май исен баса алмый. Стратегик дары заводыннан күтәрелгән күксел болыт Петрушкин разъездындагы һаваны тәүлек буе серкә исенә мана. Сарык тиресе иләү (мутон җитештерү технологиясе өчен Казан мех комбинатына 1951 елда Дәүләт премиясе биреләчәк) шәһәрдәге «хуш» исләр букетына үз «тәмләткечләрен» өсти…

Әмма сәнәгать исләре чәчәк кенә әле – совет классикасы «Шипр» фонында «Красная Москва» ислемае кебек. Казан «Шипры» – керосин ул, аның үзеге дә, кырыйлары да тулысынча шул ускә баткан. Бөтен кешенең аш бүлмәсендә керосинка һәм керогаз төтенли; икмәк, тоз һәм шырпыдан соң, керосин иң үтемле товар санала. Аны алу өчен чиратка басу хәтта алдынгы эшчеләр сыйныфы белән ышанычсыз интеллигенцияне дә хокукларында тигезли.

Лундстрем хатыны белән Бауман урамында, театр хезмәткәрләре тулай торагында яши, бүлмә фанера белән бүленгән, уртак коридорда керосинка һәм кер юа торган тагараклар тора. Мөгаен, маэстро һәм башка «шанхайлылар» керосинны якындагы лавкадан – күрше Островский урамындагы тәбәнәк таш бина-бункердан аладыр. Керосин сатып алу – үзе бер могҗиза. Башта, эсседә әлсерәп, бик озак урамда чират торасың, аннары, ниһаять, мавзолейдагы кебек салкын һәм ярымкараңгы кибет эченә эләгәсең. Аермасы бер генә – саркофаг урынына, анда зур корыч чан тора, янәшәсендәге хезмәткәр литры 65 тиеннән ягулык бүлә…

Джаз дигәндә, Бродвей, Манхэттенның күккә ашкан йортлары, Американың куәтле машиналары күз алдына килә. Ерак дөнья утлары… Биредә исә – керосин, коммуналкалар. Моннан йөз ел электәге кебек үк Тукай урамындагы зур базар янында мәңгелек пычрак изгән шыгырдавык арбалар… Совет джазының киләчәге бар микәнни?

ИРКЕНРӘК СУЛЫШ АЛ ҺӘМ ҖЫРЛА

Бернничә елдан соңгы Казан. Илленче еллар уртасы. Губернатор сарае каршындагы Кремль бакчасында гранит эскәмиядә бронза Ильич моңсуланып утыра – аңа терәлеп үк утырган мыеклы көрәштәше исә юкка чыккан, әйтерсең, анда беркайчан булмаган да. Һәм, гәрчә керосинкалар кимемәсә һәм дары заводы снарядларга тәмуг катнашмасы тутыруын туктатмаса да, хәзер шәһәрдә сулыш алу бөтенләй башкача.

Иркенрәк сулана, тын юллары киңрәк кебек. Һәркемгә. Джазга – бигрәк тә. Казан үзе теләп «шанхайлыларга» бирелә. Инде дипломлы композитор һәм Качалов театрының

Автор:
Әскәр Сабиров

сәнгать җитәкчесе булган Олег Лунстрем дан нурларында коена. 1955 елның җәендә шәһәрдә афишалар ябыштырыла: Җәйге театрда джаз оркестры концертлары. Ун концерт булачак, әмма аларга эләгерлек түгел – бөтен билет сатылып беткән. Хезмәтчәннәр соравы буенча, Черек күлдәге иске циркта оркестр тагын бер концерт куя.

Джаз хәзер күңелгә якын, халык диңгез артыннан кайткан җәүһәрләр белән генә түгел, джаз эшкәртелешендәге татар көйләре белән дә хозурлана. Пластинка пәйда була, анда: «Олег Лундстремның Татар эстрада оркестры» дип язылган. Мондый оркестр рәсми теркәлмәгән, диләр, әмма бу хәзер беркемне дә хафаландырмый – хәрби френчтагы мыеклы кеше артыннан идеологик тыюлар да каядыр еракка киткән кебек...

Дмитрий Шостакович, татар композиторларының Лундстрем пластинкасындагы көйләрен тыңлагач, «Советская музыка» журналы редакциясендәге киңәшмәдә: «Совет җиңел музыкасы менә шул юлдан барырга тиеш», – дип әйтеп куя.

Товарищ Абсалямов А. С.
является участником декады татарского искусства и литературы в Москве 1957 года.
Министр Культуры ТАССР
(Х. Рахматуллин)
Татполиграф, 002622
ПФ 05496 от 27 апреля 1957 г. Тираж 1500

Товарищ Тарджиманов Д. В.
является участником декады татарского искусства и литературы в Москве 1957 года.
Министр Культуры ТАССР
(Х. Рахматуллин)
Татполиграф, 002622
ПФ 05496 от 27 апреля 1957 г. Тираж 1500

ИЛҺАМ ҺӘМ ПАРТИЯ – ИГЕЗӘК ТУГАННАР

Ирек бацилласы – йогышлы әйбер. Джазга яраган нәрсәләр ни өчен башкаларга ярамый? Мәскәүдәге Татар мәдәнияте декадасына әзерлек башлаган иҗат коллективлары (ул СССР Министрлар Советы карары белән 1957 елда үтәргә тиеш була) да үзләренең импровизациягә хокукын дәгъвалап чыга.

– Безнең эшебез иҗади, аның белән идарә итәргә ярамый, – дип киреләнә язучы Әмирхан Еники республика язучыларының 1956 елның маенда үткән җыелышында һәм мәдәнияткә партия тыкшынуын туктатырга өнди. Сталин бүләге иясе композитор Нәҗип Җиһанов исә бөтенләй аполитизм күрсәтә – Декадага партия турында җыр язудан баш тарта! Дәлилли дә: «Тәкъдим ителгән шигырь илһамландырмый, илһамсыз исә мин яза алмыйм». Декадага әзерлекне тикшерү комиссиясендә Җиһанов: «Опера театры составы сәнгатьлелек принцибы буенча түгел, бәлки иҗтимагый эш принцибы буенча расланган», – дип белдерә. Һәм тагын болай дип тә өсти: «Театр яхшы солистларны эшкә алмый, курәмсең, бөтен кеше дә Мәскәүгә бара алмас, дип шикләнә...»

«Хрущев җепшеклеге» беркатлы, хәйләсез интеллигенциянең башын әйләндерә, аларны буш хыялларга чумдыра. Партия өлкә комитетына агылган хатларда – мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятын мәҗбүри укыту, абитуриентларга имтиханнарны туган телдә тапшыру хокукын бирү һәм Казандагы югары уку йортларында татар телендә укыта башлау тәкъдимнәре. Язучылар Нурихан Фәттах, Әмирхан Еники, Шәйхи Маннур совет татарстанлыларының күпчелегенең яшерен хыялын – ТАССРны союздаш республикага әйләндерүне – һәркем ишетерлек итеп яңгыратырга кыюлык таба...

Хыяллар-хыяллар... Мәскәүдә 1957 елның җәендә уңышлы үткән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы чыныккан партиялеләр белән хыялый интеллигенция бәхәсендә кем җиңүен ачык күрсәтә. Әлеге вакыйгага махсус язылган һәм тиз арада онытылган «Давыл кошының яшьлеге» һәм «Язылмаган законнар» (нефтьчеләр хезмәте

турында) пьесалары, «Татарстан һәм Кытай нефтьчеләре арасында иҗади тәҗрибә уртаклашу» картинасы һәм башка шундый җәүһәрләр, әлбәттә инде, илһам килгәч язылган. Какшамас татар-кытай дуслыгы турында пьеса да шундыйлардан. Дөрес, ул барыбер башкала сәхнәсендә күрсәтелмәгән – совет-кытай мөнәсәбәтләре кисәк начараю сәбәпле, аны КПСС ҮК куярга рөхсәт итмәгән…

Әмма хәтта партия-гегемон да гүзәллек хисеннән мәхрүм түгел. Мәскәүгә милли сәнгатьнең чын җәүһәрләре дә бара: «Шүрәле» балеты һәм «Алтынчәч» операсы, «Зәңгәр шәл» спектакле… Соңрак, Декаданы әзерләү һәм уздыру комиссиясе хисабында, уңышның төп илһамчысы һәм оештыручысы кем булуын тыйнак кына билгеләп үтәчәкләр: «Спектакль, концертлар һәм башка чараларның идея һәм сәнгать дәрәҗәсен күтәрү буенча чаралар күрелде…»

Ә джаз ни хәлдә соң? Олег Лундстремның эстрада оркестры – программаның каймагы, Декаданың тулы хокуклы катнашучысы. Дөрес, коллектив хәзер Казанга гастрольгә генә киләчәк…

ЦЫЦ, МЕЛОМАННАР!

«Росгастрольбюроның» Казанда эч пошудан интеккән администраторының Лундстремның иске циркстагы нәкъ менә шул планнан тыш куелган концертына барып әләгүен күр әле син! Тыңлап таң кала һәм, халыкны терсәкләре белән ера-ера, сәхнә артына ашыга: «Егетләр, сез нишләп бу Казанда ятасыз, әйдәгез, Мәскәүгә!» – ди. Мәскәүдә исә ярдәм сорап куәтле Сергей Михалков янына барган, диләр. Янәсе, Казанда чын джаз музыкантларын тапкан, шуларга күченергә булышасы иде. Михалков мондый могҗизага бик ышанып бетмәгәч, инандыру өчен каты итеп әйтергә мәҗбүр булган, диләр: «Мин бит сезгә б… тәкъдим итмим инде!»

Казан меломаннарын иректә Шанхай джазыннан мәхрүм иткән кешенең фамилиясе Цыц булып чыккан. «Цыц, егетләр, джаз – сайлап алынганнар өчен генә», – дип нервланып шаярта бу җәһәттән яраткан концерт ризыгыннан мәхрүм калган Казан публикасы.

Ә калган шәһәр нишли? Казанда хәзер яңа авазлар яңгырый. Соцгород артында һаваны вертолет калаклары выжылдап кисә – биредә илдә беренче геликоптерларны җыялар. Яңа елга портында канатлары су астында булган судноларның двигательләре гүли – беренче «Ракета»лар Казаннан Горькийга кадәр йөри. Караваево, Казансу өстендә исә, көне-төне, үрдәкләрне куркытып, әле генә авиация заводында җыелган дәһшәтле стратегик Ту-16 очкычлары гөрелди. Алар инде Американы куркытырга, теләсә кайсы вакытта атом бомбасын төяп юлга чыгарга әзер…

Коммунизмга ышанычлы адымнар белән барыр өчен, бер аяктан атлау зарур. Димәк, бернинди дә импровизация булмаска тиеш. Дәртле маршлар, якты киләчәк, бөтен шикләнүләрне кире кагучы идеология бар икән, безгә джаз нәрсәгә соң? «Җепшеклек»? Провинциядә ул башкаладагы кебек сизелми, Мәскәүдәгедән иртәрәк тә тәгәлләнер, мөгаен…

Хуш, үзгәреш җиле, булып чыгамыни инде? Илленче еллар Казаны моңа риза түгел. Менә, йомры таш түшәлгән Тельман урамы буйлап, туфли үкчәсен сындырмаска тырышып, кара чәчле, ябык Сонечка Гобәйдуллина консерваториягә йөгерә. Менә Ленин урамында, университет аудиториясендә, мәңгелек күн курткасын һәм чаңгы ботинкаларын кигән Слава Говорухин лекция барышында ук студентлар капустнигы өчен сценарий уйлап таба… Музыка училищесында, оялчанлыгын җиңәргә тырышып, кулларын кая куярга белмичә, кичә генә авылдан килгән Илһам Шакиров моңлана. Мехчылар клубында исә, үзенең яңа төзелгән «Казан утлары» ансамбленә кушылып, татар сандугачы Әлфия Авзалова җыр суза. Ун яшьлек Альберт Әсәдуллин исә, билетсыз килеш трамвай баскычына басып, Постау бистәсеннән төшеп килә. Әнә тагын, ял итәргә көч-хәл белән вакыт табып, авыл хуҗалыгы институтының иң җитди студенты һәм ялкынлы җанатары Минтимер дуслары белән стадионга китеп бара…

Тиздән, кайберләре – иртәрәк, икенчеләре – соңрак, алар яңа музыка, яңа стиль, яңа кино һәм яңа тормыш авторларына әйләнәчәк. ■

ТОТКЫНЛЫКТАН СОҢГЫ ТОРМЫШ

Җиңүдән соңгы биш ел, ун... Тормыш бал да май түгел, ләкин беркем дә зарланмый: сугыш кына булмасын. Адым саен сугыш китергән кайгы-хәсрәтне күрергә була. Әнә тәгәрмәч беркетелгән тактадан «машина» ясап, шуны йөрергә җайлаган аяксыз гарипләр. Күзләрен сагыш баскан аз сүзле толлар. Тагын – исән калып гаепле булганнар: тоткынлык тәмугын узган солдатлар. «Әсирлектә булган» мөһере – гомерлек тамга. Шулай да 1957 елда әлеге тоткыннарның өчесенә Советлар Союзы Герое исеме бирелә...

ҮЛЕМ ЛАГЕРЕННАН КАЧА АЛГАН БАТЫР

Автор:
Әскәр Сабиров

Атаклы Покрышкин дивизиясенең элеккеге очучысы һәм Заксенхаузен үлем лагереның элеккеге хәрби тоткыны Михаил Девятаев илленче еллар башында – Казанда кечкенә генә катерның капитаны. Моны да зур бәхет дияргә була: сугыштан соңгы елларда эшкә урнашырга дип кая гына бармасын, кире боралар. Мордовиядәге үзенең туган авылы Торбеевода балачак дусты, райком секретаре да яңагына суккандай була: «Сиңа монда эш бар дип беләсеңме?! Монда Идел юк, әйдә, бар, үзеңнең Иделеңә кит»...

ГОМЕРЛЕК МӨҺЕРМЕ?

Казанда да элеккеге әсирләрне кочак җәеп каршы алмыйлар. Девятаев баштарак кайда туры килсә, шунда эшләп азаплана, баржаларга утын төйи. Аннан соң елга портында, кызганып, вокзал буенча кизү торырга алалар үзен. Аннан соң менә – катер капитаны. Ләкин ул төп гаделсезлек белән һич кенә дә килешә алмый: аны, фашистлар әсирлегеннән дошман самолётында кача алган хәрби очучыны, хыянәтче дип саныйлар. Һәм һәрвакыт бу хакта искә төшереп торалар: берьюлы берничә вазыйфа башкарганнарга – өстәмә түләү, ә аңа – юк. Затон башлыгы тынычландырырга тырышмак була: «Син әсирлектә булган кеше, эшкә алганга рәхмәт әйт». Хатыны Фәүзияне әледән-әле органнарга чакырып торалар: «Ирең нәрсәләр сөйли?» Девятаев Мәкәүгә хатлар юллый, тикшерүләрен, хыянәтче мөһерен алып атуларын сорый – җавапка тавыш-тын юк.

1956 ел. XX партия съездында Сталинның шәхес культы фаш ителә, ил репрессияләр һәм бер гаепсезгә хөкем ителгән миллионлаган кешеләр турындагы дөреслекне белә. Берничә айдан соң маршал Георгий Жуков ҮК Пленумында чыгыш ясарга әзерләнә: фашистлар белән хезмәттәшлек итмәгән әсирләрнең берниндн дә гаепләре юк, алар хыянәтче түгел... Пленум булмый кала, ләкин шулай да СССРда партия дәрәҗәсендә үк шуны аңлый башлыйлар: тоткынлыкта да үзләрен батырларча тотканнар бар, алар Ватанга хыянәт итмәгән.

ИСТРЕБИТЕЛЬ АВИАЦИЯСЕ «АРТИЛЛЕРИСТЫ»

1956 елның октябрендә «Советская Татария» газетасында бүлек мөдире, журналист Ян Винецкий, язмаларына геройлар эзләп, Казандагы хәрби комиссариатларның бусагаларын таптый. Шуларның берсендә аңа ниндидер башка сыймаслык хәл турында сөйлиләр. Янәсе, фашист самолетында качкан артиллерист бар, җитмәсә, үзе белән бергә тугыз иптәшен дә коткара. Винецкий, үзе дә элеккеге очучы буларак, берниндн артиллеристның да (ә Девятаев фильтрация лагерендагы писарьның ялгышы аркасында «артиллерист» булып китә) самолётны урлап кача алмаганын аңлый. Шулай да бу кешенең адресын ала.

«Артиллеристка» кунакка Винецкий, «Литературная газета»сының үзхәбәрчесе Булат Гыйззәтуллин белән бергә, кичке җидедә килә һәм аларның иртәнге җидегә кадәр сүзләре бетми. Соңрак, Девятаев үзе искә алганча, бу кичтә каенанасына самавырны биш мәртәбә яңартырга туры килә...

Ишеттем һәм яздым гына – бу илленче еллар турында түгел. Очрашудан соң ай-ай ярым вакыт үтә. Шул вакытта гына Винецкий үзе турында искә төшерә – шалтыратып болай ди: «Михаил Петровичка әйтегез, мин органнарга барырга һәм бөтенесен дә тикшерергә рөхсәт алдым». Соңрак ачыкланганча, әлеге эш белән КПССның Татар өлкә комитетының беренче секретаре дә кызыксынган икән...

БӘЙРӘМ ТАБЫНЫ

Ниһаять, очерк языла. Аны турыдан-туры «Литературная газета»га юлларга уйлыйлар. «Бөтен дөнья белсен өчен», – дип дәлилли үз ниятен Гыйззәтуллин. Яңа ел алдыннан бастырырга вәгъдә бирәләр. Аннан соң, 23 февральдә чыгачак, дип хәбәр итәләр... Моның урынына Девятаевка «Патриот» журналыннан полковник килә: «Михаил Петрович, әйдә, берәрне тотып куйыйк әле! Мине монда Винецкий материалын тикшерергә җибәрделәр...»

Ян Винецкийның очеркы «Литературка» да 1957 елның 23 маенда басыла. Куанычыннан нишләргә белмәгән Девятаев тимер юл вокзалына йөгерә һәм газеталар сатып ала – ун сумга! Эштә затон башлыгын да алыштырып куйганнармыни... Җитмәсә, тагын Мәскәүдән, СССР елга флоты министры Зосима Шашковтан шалтыраталар: тиз арада – Мәскәүгә!

Мәскәүгә Михаил Петрович «Советская авиация» журналында эшләүче Георгий Евстигнеев белән бергә оча – спиртлы эчемлекләр төялгән Ил-14 транспорт самолётында. Пассажирларының каһарман очучы икәнен белеп алган летчиклар

аны коньяк белән сыйлыйлар. Шулкадәр юмартланалар ки, самолет Мәскәүгә төшеп утыргач, Девятаев мондый кыяфәттә зур түрәләр янына барырга ярамаганлыгын аңлап ала. Министрга герой икенче көннең иртәсенә генә барып җитә, әмма соңга калганга ачулану түгел, йөзләренә дә чыгармыйлар. Киресенчә, министр барысын да чакырып, очучының батырлыгы, әсирлектә булганы өчен эшеннән чыгарылулары турында сөйли. Ә сүзен тәгәлләп, болай ди: «Михаил Петрович хәзер кайсыгыз янына керсә дә, ишекне аягы белән тибеп ача ала».

1957 елның августында Михаил Девятаевка Советлар Союзы Герое исеме биреләчәк. Бүләк тапшырылганнан соң, ул ай буе Константин Симоновның дачасында кунак була. Язучы аның хөрмәтенә банкет оештыра, шунда Герой беренче тапкыр устрицаларны авыз итеп карый.

Михаил Петрович Девятаев

Гвардия өлкән лейтенанты, очучы-истребитель, Советлар Союзы Герое. 1941 елның 22 июненнән – хәрәкәттәге армиядә. Һава сугышларында 9 дошман самолетын бәреп төшерә. Соңгы «фоккер»ны 1944 елның 13 июлендә юк итә, шул ук көнне үзен дә бәреп төшерәләр, аңсыз килеш әсир төшә. Лодзь хәрби әсирләр лагереннан качу омтылышы өчен аны Заксенхаузен үлем лагерена күчерәләр. Шундагы яшерен оешма кешеләре үлем көткән Девятаевның номерын башка, үлгән тоткынныкына алыштыралар, бу Девятаевның гомерен саклап кала. Степан Нитенко исеме астында Девятаев Узедом утравына җибәрелә, анда, Пенемюнде ракета үзәгендә, рейхның яшерен коралы – «Фау» ракеталары эшләнә. 1945 елның февралендә Девятаев һәм аның әсирлектәге тугыз иптәше немецларның «Хейнкель» самолетын кулга төшерәләр һәм шуңа утырып качалар. Самолетны һавага күтәргән Михаил аны фронт линиясенә кадәр алып барып җиткерә – совет зениткалары белән утка тотылган «Хейнкель» 61 нче армиянең артиллерия часте карамагына төшеп утыра. «Фау» җайланмалары һәм яшерен завод турында Девятаев тапшырган төгәл мәгълүматларга таянып, полигон бомбага тотыла. 1945 елның сентябреннән соң, Девятаевны Сергей Королёв эзләп таба, Узедомда элеккеге әсир совет космик техникасының булачак баш конструкторына немец «Фау»лары ясалган урыннарны күрсәтә.

Илленче еллар ахырында ул су асты канатлары булган беренче суднолар – «Ракета» капитаны була, соңрак «Метеор»да шулай ук капитан булып эшли. Башкалабызның мактаулы гражданины Михаил Девятаев Казанның Арча зиратында күмелгән.

МОАБИТ ТӨРМӘСЕ ТОТКЫНЫ

1950 еллар башы. Хәрби әсир Муса Җәлил күптән исән түгел. Шагыйрьне һәм аның «Идел-Урал» легионына кергән яшерен оешмадагы иптәшләрен немецлар 1944 елның августында ук Берлиндагы Плётцензее төрмәсендә җәзалап үтерә. Ләкин СССР Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы тарафыннан Муса Җәлил исеменә 1946 елда ук ачылган эзләү эшен беркем дә архивка озатырга җыенмый. Кемнәрнеңдер ялган күрсәтмәләренә нигезләнеп ясалган нәтиҗәләр буенча ул исән һәм яшеренеп ята. Кайдадыр Көнбатышта, бәлки, безнең илдәдер дә. Җәлилне Ватанга хыянәт итүдә һәм дошманнарга эшләүдә гаеплиләр.

ШИКЛӘР ПӘРӘВЕЗЕНДӘ

Вафат булган шагыйрьгә әлеге ялган шикләр авырлык китерә алмый. Ләкин туганнары – Әминә ханым һәм Чулпан «хыянәтче»нең хатыны һәм кызы исәпләнә, аларга бик кыенга туры килә. Шагыйрьнең башкаладагы Столешников тыкрыгындагы фатирына тәүлек әйләнәсе күзәтү оештырыла, хатынын Лубянкага даими чакырып торалар. Җентекләп сөйләвен таләп итәләр: кем килгән, нәрсә турында сөйләшкәннәр. Фашист тоткынлыгында, гаять авыр шартларда язылган шигырьләре әрәм: аларны бастырырга рөхсәт бирелми.

Шунысы да кызык: бу вакытка әсирләрнең тоткынлыкта килеш яшерен оешма төзүләре, үлем көткәндә дә баш имәүләре турында күп нәрсә инде мәгълүм була. Элеккеге хәрби әсир Нигъмәт Терегулов Татария Язучылар берлегенә Җәлилнең тоткынлыкта язылган дистәләрчә шигыре теркәлгән блокнотны алып килгән була. Шагыйрь белән бер камерада утырган, Каршылык хәрәкәтендә катнашкан бельгияле Андре Тиммерманс та шагыйрьнең соңгы үтенечен инде үтәгән – Брюссельдәге совет илчелегенә Моабит төрмәсеннән алып чыккан шигырьләр дәфтәрен тапшырган.

Ә ЦЕНЗУРА КАРШЫ...

Шагыйрьнең шигырьләре, аларның самимилеге һәм сафлыгы – аның гаепсез булуына, какшамас рухына иң шәп дәлил кебек. Моның шулай булуына 1948–1949 нчы еллар тирәсендә «Моабит дәфтәре» белән беренче мәртәбә танышкан Константин Симонов ихлас ышана – әлеге шигырьләрне аңа бер татар язучысы күрсәткән, дип сөйлиләр. Имеш-мимешләргә, уйдырмаларга игътибар итмичә, ул шигырьләрне «Новый мир» журналында бастырырга карар кыла. Лев Френкель сүзгә-сүз тәрҗемәсен ясый, Симонов кыска гына кереш сүз яза, шигырьләрне җыярга җибәрәләр, тик цензура тик ятмый – рөхсәт юк. Симонов Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгына мөрәҗәгать итә, әмма рөхсәтне барыбер ала алмый...

Кискен борылыш – 1952 ел. Июльдә Дәүләт куркынычсызлыгы министрлыгы Татар комитетының дүртенче бүлеге башлыгы подполковник Качалов партия өлкә комитеты үтенече буенча «М.М.Җәлиловнең үлеме фактын ачыклау» максатында Мәскәүгә мөрәҗәгать итә. Якынча бер айдан соң СССР ДКМның Дүртенче бүлегеннән җавап алына. «Эзләнүченең 1944 елда вафат булуы сәбәпле, аңа карата ачылган оператив эзләү эше ябыла», дип хәбәр ителә анда.

ҖӘЛИЛ ҖЫРЛАРЫ ЭЗЕННӘН

1953 елның апрелендә, Сталинның үлеменнән соң, инде «Литературная газета»ның баш мөхәррире Константин Симонов тагын бер мәртәбә Җәлил шигырьләрен бастырып чыгарырга омтылыш ясый. Бу юлы инде главлит (ягъни цензура), тиешле органнар белән киңәшләшкәннән соң, хәбәр итә: каршы килмибез...

Соңрак «Литературка»да Җәлил шигырьләре һәм илгә аның батырлыгы турында сөйләүче мәкаләләр тагын бер тапкыр дөнья күрәчәк. 1956 елның 3 мартында басма Юрий Корольковның «Җәлил җырлары эзләре буйлап» дигән мәкаләсен бирә. Берничә айдан соң, 1956 елның сентябре башында, Константин Симонов үзе Бельгиядәге Кнокке дип аталган курорт шәһәрендә оештырылган Халыкара поэзия фестивалендә трибунадан Муса Җәлилнең тол калган хатынының хатын укуы турында сөйли. Анда «күренекле татар шагыйренең төрмәдә язган шигырьләренең кульязмаларын коткарып кала алган, Муса Җәлил белән бергә фашистлар төрмәсендә тоткынлыкта булган Бельгия патриоты Андре Тиммермансның күркәм гамәле турында» язылган була. «Камерадагы күрше» дип аталган мәкаләдә Константин Симонов әңгәмәнең әдәби чигенешләрсез һәм төзәтмәләрсез бирелгән стенограммасы белән таныштыра. Әңгәмәдәш – Андре Тиммерманс – Муса Җәлилнең соңгы көннәренең шаһиты, шагыйрь турында бәяләп бетергесез мәгълүмат бирә алган кеше, язучы аны Бельгиядә эзләп таба.

...Советлар Союзы Герое (вафатыннан соң) Муса Мостафа улы Җәлиловка (Муса Җәлилгә) 1956 елның февралендә бирелә. Немец-фашист басып алучылары белән көрәштә күрсәткән гаять зур батырлыгы һәм ныклыгы өчен.

Муса Җәлил

Муса Мостафа улы Җәлилов. Татар совет шагыйре, хәрби корреспондент. Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты (вафатыннан соң). Армиягә 1941 елның июнендә чакырыла. Өлкән политрук буларак, Ленинград һәм Волхов фронтларында көрәшә, «Отвага» газетасының хәбәрчесе була. 1942 елның 26 июнендә Мясной Бор авылы янында бәрелештә каты яралана һәм әсирлеккә төшә. Немецлар төзегән «Идел-Урал» легионында яшерен оешма эшендә катнаша. Яшерен оешма әгъзалары легионерларның Кызыл Армия һәм партизаннар ягына чыгуын, хәрби әсирләрнең күтәрелешен оештыра. 1943 елның августында, күтәрелеш булырга тиешле датага берничә көн кала, Җәлил һәм аның көрәштәшләре гестапо тарафыннан кулга алына. 1944 елның 25 августында Берлиндагы Плётцензее төрмәсендә гильотинада җәзалап үтерелә. Муса Җәлилгә Советлар Союзы Герое исеме (вафатыннан соң) 1956 елның февралендә бирелә. 1957 елда шагыйрьнең «Моабит дәфтәрләре» циклы Ленин премиясенә лаек була (вафатыннан соң). Җәлил исеме кече планетага бирелә, Татарстандагы бистә, илдәге күп кенә шәһәрләрнең урамнары һәм проспектлары аның исем белән атала. Татарстанда иң яхшы яшь авторларга Муса Җәлил исемендәге Республика премиясе тапшырыла.

1950нче еллар

КӨНЧЫГЫШ ФОРТ САКЧЫСЫ

44 нче укчы полкның элеккеге командиры, Брест крепосте сакчысы һәм Хаммельбург, Регенсбург немец концлагерьларының элекккеге тоткыны Пётр Гаврилов илленче еллар башында Краснодарда яши. Шәһәр кырыенда үз куллары белән вак-төяктән салынган тыйнак кына йорт, кечкенә генә хәрби пенсия (аңлашыла ки, әсирлек стажга керми) һәм күршеләрнең кыек карашлары...

ИСӘН КАЛГАНГА, ГАФУ ИТЕГЕЗ

Ярар, болай да яшәргә була. Ни дисәң дә, бу туган авылы Әлбәдәндә аны 1946 елның июлендә авылдашлары каршы алуыннан яхшырак. Анда аны, немец тоткынлыгында булган кешене, халык дошманы кебек кабул итәләр. Урып-җыюда эшче куллар бик кирәк, ләкин аның ярдәменнән баш тарталар. Толлар артыннан каргыш яудыра. Питрәчкә, чүлмәк фабрикасына эшче булып китә. Аннан – бирегә, Краснодарга.

Гавриловка бәхет елмая, диярга була. 1945 елның 2 маеннан соң, аларны, Регенсбург әсирләрен, америкалылар азат итә, майорны урман аударырга түгел, Башкириягә укчы полкына запаска җибәрәләр. Тикшергәннән соң, хәтта званиесен дә кире кайтаралар һәм армиядә калдыралар. Иркутск өлкәсендә аны япон хәрби әсирләре тотылган лагерьга башлык итеп билгелиләр. Партиядән чыгарылган Гавриловның (тоткынлыкта булган, партбилет югалган) хәрби карьерасын дәвам итү шансы, әлбәттә, булмый инде. Бер ел да тотмыйча демобилизациялиләр, хәтта хезмәтендәге рәхмәтләргә дә карамыйча...

Краснодарда Петр Гавриловның ни дисәң дә эше бар – станоклар төзү заводында экспедитор, ләкин алар көчкә очын-очка ялгап яши. Шулай килеп чыга: сугыштан соң ул хатыны Екатеринаны һәм уллыкка алган малаен эзләп таба алмый – алар вафат булгандыр дигән фикергә килә. Тагын бер тапкыр өйләнә, ә еллар үткәннән соң, Брестка баргач, улының исән икәнлеген, армиядә хезмәт итүен ишетә. Екатерина да исән булып чыга, тик нык авырый икән. Гаҗәп, Гавриловлар параличланган хатынны инвалидлар йортыннан үзләренә, Краснодарга, алып кайтырга карар кылалар. Үлгәнчегә кадәр аны карыйлар-тәрбиялиләр.

ҮЛГӘННӘР АРАСЫНДА ИСӘПЛӘНӘ

Ул арада язучы Сергей Смирнов Брест крепостен геройларча саклаучылар турында документаль китап язарга ниятли. Аның кулында Брест крепостеның Көнчыгыш фортын каһарманнарча саклаган кызылармиячеләр турында немец донесениеләре була, ләкин оборонада катнашучылар арасында исән калганнарны тиз генә таба алмый. Ниһаять, Смирнов Брестта Көнчыгыш фортта сугышкан элеккеге лейтенант Яков Коломиец белән очраша. Коломиец Көнчыгыш форты оборонасын оештыручы кеше турында күп сөйли, ләкин аның фамилиясен исенә төшерә алмый. Смирнов аңа сугышчыларның истәлекләре буенча төзелгән командирлар исемлеген күрсәтә. «Мин 44 нче укчы полкның элеккеге командиры майор Гаврилов фамилиясенә җиткәч, Коломиец сискәнеп китте һәм, зур ышаныч белән, Көнчыгыш форт оборонасын майор Гаврилов оештыруы турында әйтте», – дип сөйли соңрак үзенең «Брест крепосте» повестенда Сергей Смирнов.

Смирновның исемлегендә Гаврилов үлгәннәр арасында исәпләнә. Коломиец киресен сөйли: «Гаврилов үлмәде!» Язучы Генштабка запрос юллый һәм ветеранның исән икәнлегенә инана. Гавриловның адресын алганнан соң, Смирнов аңа хат яза. «Мин хатта аны ничек эзләвем турында яздым, минемчә, аның Брест крепостенда, гаять зур каһарманлык күрсәтеп, батырлык кылуын да әйттем. Илнең бу турыда ишетәчәгенә һәм геройның кыюлыгын һәм фидакарьлеген лаеклы рәвештә билгеләячәгенә озак калмаганлыгына ышанам, дип тә өстәдем».

Ике атнадан соң Петр Гаврилов һәм Сергей Смирнов очрашачаклар. Аларның әңгәмәсе берничә көнгә сузыла. Геройның партия сафларына кире кайтырга тырышып та, уңышсызлыкка очравы турында ишеткәннән соң, язучы КПСС ҮКның партия контроле комитетына мөрәҗәгать итә һәм анда майор Гавриловның нинди батырлык кылуы турында белгәннәрен сөйли. Бер үк вакытта Смирнов Петр Михайлович турында үз истәлекләрен сөйләгән барлык ветераннардан да, Гавриловның крепость оборонасында катнашуы турындагы дәлилләрен мөһер сугып үзенә җибәрүләрен сорый.

БӘХЕТ БИЮЕ

Смирнов майор Гаврилов эше тикшерелә торган партия комиссиясе утырышында катнаша, ә аның Мәскәүдәге фатирында Петр Михайлович комиссия карарын көтә.

Гаделлек тантана итүен ишеткәннән соң, Смирнов болай дип яза: «Мин 56 яшьлек олы кешенең кинәт кенә бала-чагадай, сөенечтән нишләргә белмичә, сикер-сикерә биюен күрдем...»

Майор Гавриловның батырлыгы турында язучы Сергей Смирнов беренче тапкыр илгә радиодан сөйли – «Брест крепосте геройларын эзләгәндә» дип аталган тапшырулар циклында. Соңрак Смирнов «Брест крепосте» китабының берничә бүлеген майор Гавриловка багышлый. Бу Гавриловның Көнчыгыш фортны ничек саклаулары турындагы җентекле бәяне булачак. Өзек 1941 елның 23 июле – сугышның утыз икенче көнендә Гавриловның соңгы бәрелешкә күтәрелүенә кадәрге вакытны үз эченә ала.

Көнчыгыш фортның соңгы саклаучысының ничек әсирлеккә төшүе турында лагерь табибы хатирәләре китерелә: «Әсир майор командир формасында иде, ләкин бөтен киеме сәләмәгә әйләнгән, битен дары сөреме каплаган, сакал-мыек баскан. Ул яраланган, аңсыз хәлдә һәм соңгы чиккә җитеп ябыккан иде. Тире белән тарттырылган коры сөяккә калган скелет кына...».

Петр Гавриловка Советлар Союзы Герое исемен 1957 елның 30 гыйнварында бирәләр. 1941 елда Брест крепосте оборонасында хәрби бурычын үрнәк рәвештә башкарганы һәм шул вакытта күрсәтелгән искиткеч зур кыюлыгы һәм каһарманлыгы өчен.

Пётр Михайлович Гаврилов

Майор, Советлар Союзы Герое, Брест крепосте оборонасында катнашучы.Казан губернасы Лаеш өязе Әлбәдән авылында (хәзер Татарстанның Питрәч районы) туган. Кызыл Армия сафларында – 1918 елдан. Бөек Ватан сыгышы алдыннан – Брестта урнашкан 44 нче укчы полк командиры. Немецлар Брест крепостена һөҗүм иткәннән соң, берничә подразделениедән җыелган сугышчылар төркемен җитәкли, төркем Кобрин ныгытмасының Төньяк капкалары янында сугыша. 24 июньнән Көнчыгыш форт оборонасын җитәкли. 1941 елның 29 июне кичендә Көнчыгыш форт бомбага тотылганнан соң, Гаврилов, төркемендә калган сугышчылар белән бергә, казематларга яшеренә һәм каршылык күрсәтүне дәвам итә. Төркем берничә көн чыгарга омтылыш ясый. 23 июльдә берүзе кала һәм авыр яраланган килеш әсир төшә. Сугыштан соң Краснодарда яши һәм эшли. Васыять итеп калдырганча, Бресттагы мемориаль зыяратта күмелә. Казандагы, Бресттагы, Краснодардагы, Иркутскидагы һәм Питрәчтәге урамнар Петр Гаврилов исеме белән атала.



СУ БАСЫМЫ АСТЫНДА

Куйбышев гироэлектростанциясе илне арзанлы энергия белән тәэмин итү максатында төзелә. Әмма аның төзелеше Идел буе өчен ул бик кыйммәткә төшә. ТАССРда гына да 149 торак пункт тулысынча яки өлешчә су астында кала. Алар белән бергә никадәр чәчәкле болыннар, печән җирләре, уңдырышлы чәчүлекләр әрәм була...

Автор:
Катерина Котова

БАШКАЛАНЫ САКЛАП

Аяклар тубыктан комда, кулларда көрәк, башларда – ак яулык, миһербансыз кояштан башкача ничек сакланып булсын тагын? Хезмәт бик авыр, хатын-кызлар монда бөтенләй булмаска тиеш кебек. Әмма хәбәрченең объективы нәкъ менә аларга төбәлгән. Казан дамбасы төзелешендә эшлиләр. Әйе, әйе, су басу республикабыз башкаласын да читләтеп үтми! Шәһәребезнең бер өлеше су астында калмасын өчен, дамбалар системасын булдырырга, дренаж каналлары төзергә, яңа насос станцияләрен сафка бастырырга туры килә...

Төрле чыганакларга караганда, шәһәрне саклау өчен 300 миллионнан алып 1 миллиард сумга кадәр акча бүлеп бирелгән булган – аз түгел! 14 миллион сум тирәсе – Казан Кремле, һәлак булган сугышчылар һәйкәле һәм башка тарихи объектларга зыян килмәсен өчен карала. Моннан тыш, сүүткәргечләр, канализация челтәрен, трамвай юлларын, меңнәрчә йортны һәм башка корылмаларны күчерергә туры килде! Аларның барысына да су басу яный. Өстәвенә, су күләме Иделдә генә түгел, кече елгаларда да артырга мөмкин. Әйтик, Казансуның биеклеге аерым бер урыннарда 11 метрга күтәрелә, ә Горький исемендәге парк янындагы суның киңлеге 2 километрдан арта.

Бу эшләрдән соң тышкы кыяфәте шактый үзгәргән Казанга берәр файда каламы соң? Беренчедән, шактый зур акватория, аны хәзер республика мөмкин кадәр үзенә отышлы итеп куллана ала. Яңа Казан порты Иделнең әйдәп баручы предприятиеләренең берсенә әйләнә. Фаразланган план күрсәткечләрен ул 1962 елда ук үтәп, тоткан чыгымнарын 6 ел эчендә каплый ала. Шәһәрдә пристаньнар саны өч тапкыр арта.

Икенчедән, Идел шәһәргә кадәр килеп җитә, ә моңарчы елга белән башкала арасында ераклык 4 километр булган! Хәзер инде Казан – судагы шәһәр, һәм моның икътисадый гына түгел, ә эстетик яктан да файдасы зур.

БӨЕК КҮЧЕНҮ

Зоя Лешеваның туган авылы Болгар* бу көннәрдә туздырылган умарта оясын хәтерләтә. Туган җирләре, өлешчә булса да, «су басу зонасы»на кертелә. Бөтен кеше йөгерә, ыгы-зыгы килә, бүрәнәләп йортларын сүтәләр һәм булган мал-мөлкәтләрен җыйныйлар. Тату халык яши биредә. Күченү дә бергә бара. Ләкин туган җирләрдән берсенең дә китәсе килми. Хәер, гади кешенең теләкләре, уй-фикерләре берәүне

ФАКТЛАР ГЫНА. СУ БАСУ ЕЛЬЪЯЗМАСЫ

Кайбер мәгълүматлар буенча, 1952 ел башына су басу зонасы исемлегендә тулысынча суга батачак – 4511, өлешчә су керәчәк 2137 йорт булган. Соңрак инде башка саннар күрсәтелә: республикага 12 меңгә якын йортны күчерергә туры килә – бу 50 мең кеше дигән сүз. Бу теманы өйрәнүчеләр фикеренчә, ул чакта су басуның реаль масштабларын аңлаучылар аз булган. Кайбер мәгълүматларга караганда, Татарстанда 290 мең гектардан артык мәйданны су басарга тиеш булган. Аеруча Лаеш, Куйбышев һәм Алексеевск районнары җирләре зыян күрер, дип фаразланган. Мәсәлән, Лаеш районында колхоз печән җирләренең 93 проценттан артыгын су астында калдыру күздә тотыла. 16 райондагы йорт яны участоклары да куркыныч астында тора. Ничек кенә булмасын, күченү эшләре 149 авыл торак пунктында башкарыла. Гадәттә, күченү өчен яңа урыннар яшәүчеләр ризалыгы белән сайлана. Әмма башкарма комитетлар тарафыннан еш кына бу шартлар үтәлми.

Кешеләрне һәм хуҗалыкларны күчерүдән тыш, су басу алдыннан урманнарны да «чистартырга» кирәк. Бу мәсьәләләр буенча аңлашылмаучанлыклар күп була. Су киләчәк мәйданнарның төгәл күләме билгеле булмаса да, ел саен Татарстанда урман кисү һәм аны ташу эшенә меңләгән кеше җәлеп ителә.

дә артык кызыксындырмый. Авыл сусаклагыч сулары астында калырга тиеш булганга, иртәме-соңмы барыбер күченергә кирәк.

Борчылу, чарасызлык, каушау – күченеп китүне көткән кешеләр арасында шундый кәеф хөкем сөрә ул вакытта. Хәер, үзгәрешләрне җиңел кабул итүчеләр дә була. Махсус комиссия милекне бәяли, аннан соң күченүчеләргә акча һәм яңа урын бирелә, еш кына ул – чиста кырда, кече Ватаннан егерме-утыз километр ераклыкта урнаша. Йортларын сүткән кешеләргә бүрәнәләрен күчереп бирәләр, башкаларга яңадан өй салырга кирәк була. Кайсыбер материалларны бушка бирәләр, ләкин күп очракта чарасын үзеңә күрергә туры килә. Бүрәнәгә дә акча җитмәгән чак – йорт салам дип терлек суючылар күп була.

Бик күп архив документларын өйрәнгән тарихчы Евгений Бурдин күченеп китүнең авырдан башлануы турында әйтә. 1952 елның 20 июненә су басу зонасыннан бер генә гаилә дә күчеп китми. Аларның берсенә дә дәүләт тәкъдим иткән яңа урыннар ошамый чөнки. Әйтик, Алексеевск районының Бурцево авылында яшәүчеләр Кече Кызыл Яр авылына күчәргә каршы тора. Лаеш районының Татар Агайбашы халкы 35 километр ераклыктагы Державиного күчүдән баш тарта. Аларның балалары хәзер кайда яши икән? Архивларда бу турыда мәгълүмат юк.

Шулай ук су басу зонасына эләккән Ново-Мордово авылында, нигездә, оста котельщиклар, балта осталары, слесарьлар яши. Шуларның берсе – Василий Еремин. «Яшьләр заводта эшләде, исерекләр булмады», – дип сөйли ул. Зур күченү елларында бөтен Идел буйлап вербовщиклар йөри башлый. Эшчеләр, завод белгечләре, алар белән килешүләр төзеп, даими яшәү өчен башка районнарга китә башлый, Самара янындагы

Биш ел эчендә Куйбышев ГЭСнең гидроузелын гына түгел, плотинасын да төзергә, гаять зур территорияне су астында калдырырга әзерләргә дә кирәк була. ТАССРда 149 торак пункттагы халыкны башка җирләргә күчереп утыртырга туры килә.

ФАКТЛАР ГЫНА.
СУ БАСУ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Хәбәрченең объективында – хатын-кызлар. Казан дамбасын төзүдә катнаша. Шәһәрнең бер өлеше су астында калмасын өчен, саклану корылмалары системасын төзергә туры килә.

Поджабный, Саратов өлкәсенең Алексеевка эшчеләр бистәсенә, Куйбышев өлкәсенең Сухая Речка җирлегенә... Шулай итеп, Татарстан акрынлап кадрларын югалта.

Сүз уңаеннан, су басу зонасына авыллар һәм бистәләр генә түгел, кайбер шәһәрләр дә эләгә. Шуларның берсе – Куйбышев (элеккеге исеме – Спас). Анда яшәгән Сара Миличихина истәлекләре буенча, яңа урында бернәрсә дә булмый, шул исәптән – хастаханәләр дә. Мондый хәл халыкны күчүдән баш тартырга этәрә. «Еладык, китәргә теләмәдек. Тол хатыннар күп иде, аларга бигрәк тә куркыныч, ялгызларга кем ярдәм кулы сузар? Төп кыенлык кешеләрне күченергә күндерү булды. Моның өчен хакимият кызыксындыру чарасы уйлап тапты: яшь укытучыларны җыеп, аларга шарт куйды: әгәр барырга ризалашсагыз, ике айдан соң яңа урында фатир бирәбез, диделәр». Түрәләр нәрсә эшләгәнен белә: укытучылар – хөрмәтле кешеләр, алар күченсә, башкалар да иярәчәк.

Күченү эше эзлекле бара, урам артыннан урам китә. Нәтиҗәдә, Куйбышев бөтенләй бушап кала. Кешеләр белән бергә яңа урынга йортлар, кибет, мәктәп кенә түгел, хәтта юллардан һәм урамнардан ташлар, биналарны сүтүдән калган иске материаллар да ташыла. Барысының да кирәге чыга.

Куйбышев халкы яңа урынга килеп карагач, шакката: тирә-якта кыр, берән-сәрән йортлар күренә. Сара Миличихина сүзләренә караганда, кешеләр яңа урынга 30 августта килеп җитә, ә 1 сентябрьдә мәктәптә дәресләр башланырга тиеш була. «Мәктәп төзелеп бетмәгән иде – түбәсе дә, тәрәзәләре дә юк. Бу типлаштырылган мәктәп бинасы иске шәһәрдән күчерелгән була. Яшәргә урын юк, укытучылар өчен каралган кечкенә бүлмәдә төн кунып йөрдек. Анда диван бар, берничә кеше шунда йоклый».

Хакимият кешеләрне күченергә күндерү өчен әллә нинди хәйләләргә бара. Туган якны өйрәнүче Леонид Абрамов еш кына Ржавец авылын искә ала, анда, Болгар тирәсендәге су басу зонасына эләккән авыллардан җыелган барлык борынгы иконалар саклана. Бу гына да түгел. Ново-Мордово авылында 1861 елда төзелгән Троицк чиркәве дә су басу зонасына эләгә. Авыл халкы бу турыда белгәч, Ржавец шәһәрендә үзләренең изге урыннары хөрмәтенә Троицкий

Менә 1955 елның 31 октябре килеп җитә. Идел инде ябылган. Куйбышев сусаклагычын тутыру башлана. 29 декабрьдә ГЭСның беренче гидроагрегаты эшли башлый; соңгысы, егерменчесе, 1957 елның октябрендә эшкә керешә. Су тиз тула, әмма аңа дип исәпләнгән мәйданнар бик зур. Планлаштырылган күләменә сусаклагыч 1957 елның июненә генә ирешә. 1958 елның 9 августында Хрущев рәислегендәге Хөкүмәт комиссиясе тантаналы шартларда гигант корылманы кабул итү актына кул куя. Бу турыда әйдәп баручы совет массакүләм мәгълүмат чаралары гына түгел, ә дөнья-күләм журналистика да хәбәр итә. Генсек тонналаган сунның 25 метр биеклектән аска ыргылуын күрсен өчен, плотинаны ачканда махсус 250 тонналык кран кулланыла. Сүз уңаеннан, шаһитларның истәлекләре буенча, төзүчеләрне генсекның сәламләү сүзе гаҗәпкә калдыра: анда биш ел эчендә башкарып чыккан гаять зур, бик авыр хезмәт өчен бер генә рәхмәт сүзе дә булмый. Идел ГЭСлары каскадында әһәмиятле урын алып тора, илебезнең мәйданы 6 мең квадрат километрдан артып киткән иң зур сусаклагычларының берсен төзү елъязмасы әнә шулай тәмамлана.



гыйбадәтханәсен төзергә рөхсәт сорый. Хакимият ризалаша.

СУ АСТЫНА КҮМЕЛГӘН

Ул төнне Анастасия Трусованың мәңге онытасы юк. Аңа бушап калган туган авылы Пичкассыга әйләнеп кайтырга туры килә – сарайда мал-туар калган була. Төн кунарга дип ниятләсә дә, булдыра алмый. «Шулкадәр курку басты, кире йөгереп кайттым», – ди ул. Тирә-юньдә яңгырап торган тынлык – ә кайчандыр тормыш кайный иде! Зур су ташуын көтеп барысы да катып калган. Монда елганың биеклеге 28 метрга күтәрелергә тиеш иде.

Су күтәрелгәч, өскә сусаклагыч урынын әзерләү җитешсезлекләре генә түгел (кешеләр хәтта зиратлардан юылган табутларның Идел буйлап йөзеп йөрүен дә искә ала), проект ясаучыларның хаталарын да өскә чыгара. Пичкассы авылын беренче елларда гына су баса, аннары китә. Су килеп тә җитмәгән күпме ташландык җирләр кала! Бу хакта белгәч, кешеләр таланган, бушаган туган якларына кире әйләнеп кайталар. Әйтик, Спас район газетасында Куйбышевның иске өлешен су басканнан соң коры калган урында төпләнеп яшәгән ике «робинзон» турында материал дөнья күрә. Алар землянкаларда көн итә, балык белән туклана, хәтта мал-туар да асрый... Шунысы кызык: Евгений Бурдин архивларда «робинзоннар» турында мәгълүматларны эзләп таба һәм аларның су басу зонасыннан куйдән баш тарткан элеккеге Куйбышев кешеләре булуын ачыклый. «1957 елның кыш һәм яз айларында, аларны мәҗбүри рәвештә күчерергә теләгәндә, иске шәһәрдә инде беркем дә булмый, биналарның күбесе күчерелгән, калганнары яндырылган яки җимерелгән, аеруча нык биналарның кирпеч диварлары гына торып калган була. Гомер буе шушында гомер иткән кешеләргә туган җирләренең һәлак булуын күреп тору никадәр авыр булуын күз алдына да китереп булмый», – дип яза туган якны өйрәнүче. Сүз уңаеннан, су басмаган ташландык авыллар, бистәләр, шәһәрчекләрнең кайберләренә бүген дә килүчеләр бар, алар – кайчандыр биредә яшәгәннәрнең балалары, оныклары.

БАТЫРЛЫК НӘТИҖӘЛӘРЕ

Зур төзелеш нәтиҗәләренә карата бүген мөнәсәбәт төрле. Бер яктан, мондый зур су күләме Татарстанны диңгез ярына әйләндерде диярлек. Уңай яклар арасында икътисадый файда да, узган гасыр башында ук шактый зур зыян китергән су ташуларның булмавы да бар. Моннан тыш, кайбер экологлар су биеклеген күтәрү елгаларыбызны төрле индустриаль пычрануардан саклый дигән фикердә.

Икенче яктан, күп кенә белгечләр ГЭС эшләтеп җибәрүнең һәм зур күләмдәге коры мәйданнарны су басуның нәтиҗәләре тискәре булган, дип уйлый. Көчләп китәргә мәҗбүр ителүчеләрнең яшәү рәвеше бозылуга, зур территорияне су басуга бәйле экология һәм микроклиматның үзгәрүе дә яхшы түгел. Авыл һәм урман хуҗалыгы, терлекчелек өчен дә кыйммәтле җирләр су астында кала. Ярлар юыла. Иделдә агым тизлеге кими, бу акрынлап аның ләмләнүенә китерә. Елганың төр ягыннан флорасы һәм фаунасы үзгәрә, өстәвенә плотиналар уылдык чәчү өчен йөзүче балыкларга киртә булып тора. Моннан тыш, кайбер галимнәр сейсмик активлыкның артуы турында да сөйли... Әйе, кешенең табигатькә шул рәвешле нык тыкшынуы сирәк очракта гына көтелгән нәтиҗәләргә китерә.

Бүген әлеге гигант төзелешнең нәтиҗәләрен бер яклы гына бәяләмиләр. Кешенең табигатькә мондый көчле йогынтысының нәтиҗәләре бик аз очракта гына көтелгәнчә һәм бертөрле генә була...

* А. Черкасовның «Спасск-Куйбышев-Болгар – свидетель времен и судеб» эше өчен тупланган истәлекләре файдаланылды.

«Татарстан» журналының махсус проекты

60нчы еллар

БУЫННАР

ГАЛӘМГӘ АТЛАУЧЫЛАР БУЫНЫ

60 нчы еллар буыны – беренче космонавтларны галәмгә озатучылар, Камада нефть химиясе комплексын һәм Түбән Кама ГЭСын төзүчеләр, хәрабәләрдән беренче Казан «хрущёвка»ларына күчүчеләр һәм, һава торышы көйсезлекләренә һәм югарыдан төшкән мәгънәсез карарларга карамастан, күп итеп иген игүчеләр алар. Оборона предприятиеләрендә илнең атом-төш калканын коючылар, ә 1967 елның 7 ноябрендә, Совет хакимиятенең 50 еллыгын бәйрәм итү көнендә, коммунизмда яшәргә тиешле киләчәк буыннарга теләкләрен юллаучылар...
60 нчы елларда совет Татариясе ничек яшәгән?* Казанны бизәп торачак биналарны кемнәр төзегән? Нефть химиясе гиганты ничек башланган? Американы юкка чыгарырга сәләтле самолётлар кайда туган?

ХРОНОГРАФ

1960

- Казанның Совет районында киң экранлы ике заллы «Дружба» кинотеатры ачыла
- Чаллы районының Афанас авылы янына булачак нефть химиясе комплексын һәм шәһәрне төзүчеләрнең беренче чана-трактор поезды килеп җитә

1961

- Яшел Үзәндә «Метеорлар» – су асты канатлары булган югары тизлекле теплоходлар төзи башлыйлар

1962

- Беренче тапкыр Мәскәү телетапшыруларын трансляциялиләр

1963

- Казанда Планетарий ачыла. Аны Петропавловск соборының Түбән Сретение храмында урнаштыралар
- Яр Чаллы янында Түбән Кама ГЭС төзелә башлый
- «Оргсинтез» заводы гамәлдә булганнар сафына кушыла

* 60нчы еллар еллар буыны турында тулырак – журналыбызның 2019 елның октябрь санында.

Фото Гадел Хәировның шәхси архивыннан алынды

Ноябрь демонстрациясе. 1960 ел.

1965

- Казанда Ми-8 вертолётлары чыгарыла башлый

1966

- Казанда Ил-62 самолётлары сериялəп чыгарыла башлый
- Түбән Кама эшчеләр бистәсенә шәһәр статусы бирелә
- Казанда Беренче май мәйданында герой-шагыйрь Муса Җәлилгә һәйкәл ачыла

1967

- ТАССРның Дәүләт симфоник оркестры оештырыла
- Казанның Николай Ершов урамында Совет хакимияте өчен көрәштә һәлак булганнар истәлегенә монумент ачыла
- «Түбән Кама Нефтехим» комбинатында беренче продукция чыгарыла
- ТАССР башкаласында Сынлы сәнгать музее ачыла
- Түбән Кама шәһәрендә ТЭЦ-1 эшли башлый
- Казан консерваториясендә концерт залы ачыла
- Казан циркының яңа бинасында беренче тамашалар күрсәтелә

1969

- Мәскәү энергетика институтының Казан филиалы ачыла
- Н. К. Крупская исем. Ленинград мәдәният институтының Казан филиалы оештырыла
- Яр Чаллыда автомобиль заводлары комплексын төзү турында карар кабул ителә
- Чулман буендагы автогигант төзеләсе урыннан беренче чүмеч җир алына
- Казан авиация заводында Ту-22М стратегик бомбардировщикларын сериялəп чыгару җайга салына

КЫЮЛЫК ҺӘМ МӘХӘББӘТ БЕЛӘН ТӨЗЕЛГӘН КАЛА

«Мы счастливее очень многих
И, пожалуй, богов сильней:
Если землю творили боги,
Мы творим города на ней...» –

Александра Пахмутова һәм Николай Добронравов әлеге җырны 1960 елда бөтен илдән ТАССРның комсомол төзелешенә юл тоткан яшьләрнең омтылышы белән рухланып иҗат иткән. «Татарстан» хәбәрчеләре «Түбән Кама» исемле урын өчен кайчандыр тормышын яңабаштан башларга курыкмаган кешеләр белән очрашты.

Автор:
Олеся Бондаревская

– «Без кая эләктек? Йа Хода, бу бит узган гасыр!» – отрядыбыз билгеләнгән урынга килгәч, мине шундый уйлар биләп алды. Тирәякта кечкенә вагоннар гына тырпаеп тора, ә калганы – кар каплаган басу-кырлар… Электр да, эчәргә яраклы су да, радио да, телевидение дә юк. Без әллә кайда еракта, тайгада кебек идек, – дип искә ала Рафаил Глянц. 1961 елның гыйнварында ул Түбән Кама төзелешенә эшчеләрнең һәм белгечләрнең икенче дулкыны белән килә. Татарстанның нефть эшкәртү сәнәгате үзеге төзелеше узган гасырның 60 нчы елларында әнә шулай шып-шыр буш кырда һәм хәзерге заман өчен гаҗәеп, акылдан язарлык энтузиазм белән башлана.

Проект идеясе яхшы аңлашыла: 50 нче елларда ТАССРда нефть ятмаларын, шул исәптән, илдәге иң зурларның берсе булган Ромашкино ятмасын үзләштерү дә, тулы куәтенә бара. Ә республикада аңа кадәр нефть эшкәртү сәнәгате, нефть химиясе бөтенләй юк иде. 1958 елда СССР Министрлар Советы Татарстан АССРның төньяк-көнчыгыш өлешендә Түбән Кама сәнәгать районы төзеләчәген билгели торган ике карар кабул итә. Аның үзеген алга таба эшкәртү өчен яраклы пластмасса, синтетик каучук һәм углеводород чималының яңа төрләрен чыгарачак завод – Европада иң эре нефть химиясе комплексы тәшкил итәргә тиеш була.

БЕРЕНЧЕЛӘРГӘ САЛЮТ!

«Мин яңа шәһәр төзергә киттем», – дип язган хатынына экскаваторчы Иван Коршин. Ул үзе кебек 24 эшче белән, махсус техниканы чаналы трактор поездына төяп, 1960 елның 25 декабрендә Лениногорскидан юлга чыга. Кич белән беренче төзүчеләр Актүбә авылына килеп җитә. Ату тавышыннан куркып калган халык аларны каршы алырга чыга, баксаң, җирле аучы әлеге кунаклар хөрмәтенә мылтыктан салют аткан икән. Алдагы елын Иван Коршин тулысынча диярлек экскаватор кабинасында үткәрә.

Марафон берничә ел дәвам итә. Булачак шәһәр берьюлы бөтен нәрсәгә мохтаҗлык тоя: төзелешне алып барырга кирәк, аның өчен материаллар, һәм бу тирәдә әсәре дә булмаган юллар зарур. Бервакыт чистарту корылмалары өчен нигез чокырын тиз казыганга, «Татэнергострой» җитәкчесе Евгений Королёв бригадага бер банка спирт һәм 10 шешә аракы алып килә… һәм шунда ук яңа объектка озата. Иван Коршинның комлы вак таш катнашмасын КРАЗ белән БЕЛАЗларга тиз төяү күнекмәсе алтын бәясенә тиң була. Бервакыт шоферлар нигез чокыры казырга җибәрелгән Коршинны алмаштыручы экскаваторчының акрын эшләве турында Евгений Королёвка зарлана. Җитәкче исә Коршинны кире кайтарырга куша һәм экскаватор белән төяп алып кайтыр өчен «Кировец» кичке сәгать унда килеп тә җитә. Билгеләнгән пунктка ярты чакрым калгач, тагылма салулап, 46 тонналы экскаватор платформадан юл читендәге үтеп булмаслык пычракка оча. Куркынычсызлык техникасын төгәл үтәү Коршинны коткарып кала: ул «Кировец» кабинасында барган була. Ә экскаваторны тартып чыгару тән буена сузыла…

ЯУЛЫКЛЫ ГҮЗӘЛКӘЙЛӘР

«Гел егетләр генә. Мин патша кызы кебек вагонда яшим. Патша кызлары вагоннарда яшәми, ди-



сезме? Алар күп нәрсәне югалта, дияр идем. Авыр, әмма күңелле яшибез», – дип яза көндәлегендә 1961 елда комсомол Зина Златковская. Кызлар егет-җилән белән иңгә-иң торып эшли, вагоннарда яши. Бу вагоннар янәшәдәге бараклар белән бергә Төзүчеләр бистәсе дип атала башлый. Торак биналар эчендә мичтән һәм ике катлы караватлардан башка берни дә юк. Бистә һәм төзелеш базасы – бөтен дөнья шуннан гыйбарәт. Якындагы авылга кадәр 5 чакрым барасы. Тирә-якта үтеп булмаслык сазлы пычрак. Бар юаныч – күршеләрдән алган керосин лампасында китап уку яки кәрт сугу. Ипи хәтле ипине дә Чаллыдан китерәләр. Кайчагында ул шакырдап туңа – балта белән чабарга туры килә. Мондый шартларда кәттәлек турында уйларга да түгел, тик ул еллардагы фотосурәтләрдән безгә чын гүзәлләр карап тора, аларның күзләре шатлык, тормыш дәрте белән яна. Бу кызларга өчпочмаклы кыек яулык белән тупас эш киемнәре – комбинезоннар, свитер һәм эшче чалбарлары да искиткеч килешә. Аннары, 70 нче елларга таба, биредә беренче чәчтарашханә, тегү остаханәсе, кием кибете пәйда булачак, ә әлегә җылы су белән юыну да – зур бәхет.

– Кызлар, чыгыгыз, су алып киләләр! – бу чакыруга чиләк, чәйнек, кәстрүлләрне күтәреп, шунда ук чыгып йөгерергә кирәк. Актүбә тирәсендә эчәргә яраклы су түгел, гомумән, бернинди су да булмый. Аны 9 чакрым читтәге Кызыл Чишмә авылыннан трактор китерә. Су ташучы трактор көн буе йөреп тора. Су һәркемгә дә җитсен өчен, мондагы халык торба кисәкләреннән ябыштырып ясаган савытларны әллә ничә тапкыр тутырырга туры килә.

ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕЗ АЛГАРЫШ

Татарстанда Түбән Кама дигән кала төзелүе турында хәбәр бөтен ил буйлап тарала. Күпләр өчен зур төзелеш торак, азык-төлек һәм товарлар белән яхшы тәэмин итүне, һөнәри үсеш мөмкинлекләре дигәнне аңлата. Сугыш кичкән һәм аның тәэсирләреннән әле яңа гына зур тырышлык белән арынып килгән кешеләр өчен зур төзелеш тотрыклы тормыш дигәнне дә белдерә. Актүбәдәге бистә һәм тирәюньдәге авыллар төзелештә хезмәт куючы меңләгән кеше белән бик тиз тула. Аз-маз мөмкинлек булган бөтен җирдә, хәтта кул астындагы төзелеш материалларыннан әмәлләнгән алачыкларда да яшиләр. 1963 елда төзелешкә «Татэнергострой» идарәсе төзүчеләре җитәкчесе Евгений Королёв һәм «Түбән Кама Нефтехим» оешмасының булачак директоры Николай Лемаев килә һәм алар процессны үз кулларына ала. Ләкин галәмәт зур проектны гамәлгә ашыручылар бу вакытка кадәр үзләрен үзләре кайгыртып гомер кичерә. Иң якын хакимият органнары, район советы, партия райкомы, район башкарма комитеты Яр Чаллыда урнашкан. Шунда ук Круглое поле станциясенә, материаллар да китерелә, аннан аларны йөк машиналарында стройбазага ташыйлар.

АЛГА ҺӘМ БЕРНИГӘ КАРАМАСТАН

Проектны «Лениногорскнефтестрой» тресты алып бара. Аннан килгән күрсәтмәләр кайчак төзелештәге бурычлар белән бөтенләй ярашмый. 1962 елның язында хезмәт җитештерүчәнлеге күрсәткечләрен яхшырту максатыннан 300 кешене кыскартырга дигән боерык килә. 46 нчы төзелеш-монтаж берләшмәсе җитәкчесе Иван Точилин, бу хәлнең мәгънәсезлегенә ачуы чыгып, иң кыйммәтле хезмәткәрләр – механизаторларны эштән җибәрү турында боерыкка кул куя. 1 май бәйрәменә туры килә бу. Механизаторлар туп-туры Алабугага, КГБ бүлекчәсенә барып, Бөтендөнья хезмәт көнендә югары тәҗрибәле 300 белгечне эшсез калдырган Точилинны хокук саклау органнары тарафыннан күз уңында тотуларын сорыйлар. Тиздән төзелешкә килгән комиссия Иван Точилинны вазыйфасыннан куар өчен җитәрлек хокук бозулар таба. Шулай итеп, 46 нчы төзелеш-монтаж идарәсен 28 яшьлек Рафаил Глянц җитәкли башлый. Шул ук елны ул беренче сынавын уза: 1 сентябрьдә шәһәрнең беренче бинасын – 1 нче мәктәбен кулланылышка тапшыра. Соңрак Рафаил Григорьевич «Түбән Кама Нефтехим» директорының гражданлык төзелеше өчен җаваплы урынбасары булачак. Түбән Кама шәһәрендәге торак һәм социаль объектларның күп өлеше аның җитәкчелегендә төзелә.

ТОРМЫШ ҺӘМ ҮЛЕМ МӘКТӘБЕ

Киң урамнар, күп катлы йортлар, парклар һәм скверлар – булачак Түбән Каманы 1955 елда Гидрологик экспедиция инженерлары Алабугадагы студент-практикантларга әнә шулай тасвирлый. Искиткеч матур һәм кызыктыргыч картина күзаллана. Шул кадәр ямьле ки, студентларның берсе – Владимир Власов, физика укытучысы дипломын алгач, төш-хыялдагы шәһәргә юл тота. Әмма анда 1964 елда гына төпләнә ала ул. Һәм шунда ук үзе хезмәт куячак 2 нче номерлы мәктәп төзелешенә элэгә. «Мәгариф бүлегеннән куратор булырсың», – диләр аңа, төзелешнең генераль планын тоттырып. Июнь ае үтеп бара. Июль аенда инде Владимир Власов, мондый темплар белән эшләгәндә, мәктәпне сентябрьгә тапшырып булмаячагын аңлый. Евгений Королёвка кадәр керә. Тегесе хәлне төшенә, төзелеш ике сменада бара башлый. Августта исә өчәр сменалы эш оештырыла. Бу вакытта физика укытучысы республика буйлап парталар, мебель, җиһазлар эзләп йөри. Мәктәпне вакытында тапшыралар. Ә Владимир Власовка торак бирелә – кечкенә кухнясы һәм душы булган 4 квадрат метрлы каравылчы бүлмәсе. Ул анда хатыны һәм ике баласы белән яши башлый. Тиздән идән астында су тула торган чокыр булуы ачыклана. Кыш буе – юешлек, дым-

лы ис. Власовларның кече улы салкын тидерә. Малайны коткарып кала алмыйлар... Берничә елдан соң, тормышларына яңа мәгънә бирепр, кызлары туа. Власовлар гаиләсе – Түбән Камага бар гомерләрен багышлап, шәһәр үсешенә күп тырышлык салган затлар. Владимир Федорович тәрбияләгән укучылар хәзер Мәскәү, Санкт-Петербург, Киев фәнни-тикшеренү институтларында эшли. Аңа, Татарстанның атказанган укытучысы һәм Түбән Кама шәһәренең мактаулы гражданына, хәзер 84 яшь. Ә укучылары килә дә килә...

АФАНАС КЫЗЫ

– Әгәр мин Роза Зариповна янына кайтмасам, ул миннән аерылып китәчәк! – Афанас хастаханәсенең баш табибы Фатыйх Хәйбуллин яшь Валентинага әнә шулай дип белдерә, Казан дәүләт медицина университетын кызыл диплом белән тәмамлаган кыз авыруларны кабул итү бүлекчәсенең бусагасын атлап керүгә. Хастаханә Төзүчеләр бистәсеннән берничә чакрым ераклыкта урнашкан була. Кыз бирегә юллама буенча килә, беренчел карау-тикшерү һәм операция бүлмәләре булган яңа иркен бина күрергә өметләнә. Ә чынлыкта баракка килеп чыга, пациентларны әнә шунда кабул итәләр һәм 30 авыруга исәпләнгән стационар да шунда урнашкан икән. 1961 ел үтеп бара. Үзәк район хастаханәсе («Түбән Кама Нефтехим» медсанчасте) ачылышына кадәр 6 ел бар әле. Хастаханәнең «ашыгыч ярдәме» булып ат җиккән Ваня абый эшли. Шәфкать туташларының тәҗрибәсе зур, барысы да яхшы булачак, дип, Валентинаны ышандырып, Фатыйх Миңлебай улы терапевт хатыны янына чираттагы ялга кузгала. Якын-тирәдәге берничә авылга, ә хәзер әле яңа бистәгә дә хезмәт күрсәткән ике табиб өчен, әлбәттә, бу ял бик кирәк. Белеме буенча теш табибе булган Валентинага көтмәгәндә терапевт, аннары хирург, аннары гинеколог роленә керергә туры килә... Төп диагностика коралы – куллар, ә төп күнекмә – салкын канлылык.

Бервакыт төнлә комбайн астына эләккән ир-атны алып килүләр. Баш тиресе тулысынча салдырылган диярлек, кан елга булып ага. Пациентны Яр Чаллыга җибәрү аны бакыйлыкка озату дигән сүз. Бу көнгә кадәр Валентина үзен яралар тегә белмим, дип уйлый. Белә икән. Ир исән кала. Гомумән, Фатыйх Хәйбуллин Валентинага ышанып тапшырганнарның барысы да исән кала.

Геннадий Сумароков, 1 нче музыка мәктәбе укытучысы, 3 нче Балалар музыка мәктәбе директоры:

– Ул чорның иң яраткан җыры – «Ах, ты зимушка-зима». Казан музыка училищесын тәмамлагач, 1965 елда мин Мәдәният министрлыгы юлламасы белән Түбән Камага килдем. Башта Соболеково авылында яшәдем. Эшкә 1 нче музыка мәктәбендә баян дәресләре укытырга биш ай җәяү йөрдем. Аннары Камадан ком-чуерташ катнашмасы ташый торган шоферлар белән дуслаштым, барасы юлның яртысын шулар белән үтә идем. Шәһәрдә фатир биргәч, күпкә җиңелрәк булды. Әмма эш күп иде. Ул елларда һәр шәһәр бәйрәмендә халык уен коралларында уйнаучылар программаның иң төп номерларыннан саналды. Мин аккомпаниатор да булып эшләдем. «Түбән Кама Шин»га да бардым. Җыю цехында хор оештырганнар иде, төшке аш вакытында без «Подмосковные вечера», «Сормовская лирическая», «Уральская рябинушка» җырларына репетиция ясыйбыз... Аннары мине 3 нче музыка мәктәбе директоры итеп сайладылар. Ул торак йортның берничә фатирында урнашкан иде. Бүлмәләр арасындагы кайбер диварларны сүтүгә ирештем – шулай итеп актлар залы барлыкка килде. Хәзер боларның барысын да искә алу үзе бер кызык. Миңа 83 яшь, хәзер уйнамыйм инде. Әмма укучыларым уйный. Шуларның унысы профессиональ укытучы булды.

МАТУР ЯШЬЛЕК

Ул чорларның иң зур бәласе криминаль абортлар була. Әйләнәтирәдә гел яшьләр, ә контрацепция турында сөйләшүләр юк дәрәҗәсендә, бала табар урын да юк диярге мөмкин. Бервакыт шундый аборттан соң авырайган хатын-кызны алып киләләр. Аның бөерләре эшләми башлаган, хәле авыр. Чаллыдан килгән акушер хатын пациентны коткарып калып булмаячак, дип белдерә. Валентина Фатыйх Хәйбуллинның Казанга, диализ ясарга мөмкин булган тимер юл хастаханәсенә шалтыратуын үтенә. Казанда аппарат ватылган, дип хәбәр итәләр, тик Мәскәү белән элемтәгә кертергә ышандыралар. Валентинаның гаҗәпләнүенә каршы, Афанас хастаханәсенә, чыннан да, Мәскәүдән шалтыратып, пациентканы Казанга озатырга тәкъдим итәләр, ә аннан башкалага алып китәр өчен самолет җибәрәчәкләр икән. Валентина авыру хатынны озата бара. Мәскәүдән самолет килеп, аны алып та китә. Хатын исән кала һәм соңрак өч тапкыр әни дә була әле.

Бераздан шәһәргә табиблар – искиткеч, талантлы, намуслы белгечләр килә башлый. Медицина хезмәте үсә. 1966 елда Валентина Шишонина үзен тулысынча төп белгечлегенә багышлау мөмкинлеге ала. Стоматология сырхауханәсе мөдире вазыйфасын калдырып, ул хәзер дә теш табибы булып эшли. Улы – Түбән Кама үзәк район хастаханәсенең гинекология бүлеге мөдире. Оныгы Ижевскида табиблыкка укый…

«ХИМИЯ» ТАҢЫ АТА

«За ночь ровно на этаж
Подрастает город наш,
Раньше всех к нам приходит рассвет.
Снятся людям иногда,
Голубые города,
У которых названия нет».

60 нчы елларда бу җыр Түбән Камада бик еш яңгырый. Тормыш җайга салына бара, күпкатлы йортлар, балалар бакчалары, мәктәпләр, хастаханәләр төзелә. Яңа шәһәргә кешеләр килә дә килә. Анда яшәүчеләр өчен эшли алмастай нәрсәләр булмый. «Түбән Кама Нефтехим» турбиналары күккә ыргыла, «Түбән Кама Шин» заводының мәйданнары киңәя. Николай Лемаевның уҗәтлеге нәтиҗәсендә күп нәрсә тормышка ашырыла. Ул Мәскәүдәге бу тармак җитәкчелеге белән уртак тел табып, теге яки бу карарларның кирәклегенә ышандыра белә. Әйтүләренчә, нәкъ менә ул, КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Фикрәт Табиев ярдәме белән, иң башта ук «Түбән Кама Нефтехим» проектының зарурилыгын яклап чыга, һәм ил өчен бу предприятиенең кирәклек дәрәҗәсе автомобиль төзелеше яки энергетика предприятиеләреннән бер дә ким булмаганлыгын исбатлый. Николай Лемаев өчен кечкенә мәсьәләләр булмый. «Түбән Кама Нефтехим» өчен Мәдәният йорты салынырга тиеш түгеллеген ачыклагач, ул төзелешне барыбер килештерүгә ирешә – Техниклар йорты дигән булып…

ҮТКӘННӘР – БҮГЕНГЕДӘ

Үткәннәргә борылып караганда һәм тирә-юньгә күз салганда, геройларыбыз үз-үзләренә ышанмый. Бөтенләй тәҗрибәсез килеш, энтузиазм һәм үз Ватаннарына ышаныч белән генә коралланып, чыннан да, алар яшьтәшләре белән шушы искиткеч шәһәрне, киң, яшел проспектларны, куәтле заводларны төзи алдылармы? Әйе, чыннан да, бу – алар эше, менә фотографияләрдә төзелешкә, заводка, хастаханәгә, мәктәпкә баралар. Һай вакыт ничек тиз үтеп киткән! Бу урын белән беренче очрашудан соң узган еллар аны бүгенге хәлгә китерү өчен сарыф ителгән. Алар үзләре моңа үкенмиме? Юк, үкенмиләр. Ул чакта сайлау мөмкинлеге булса, алар янә шул ук юлны – яраткан Түбән Кама каласында яшәүне һәм аны төзүне сайлар иде.

Галина Исмәгыйлова, табиб – акушер-гинеколог:

– Гамир Гарифович белән без Төзүчеләр бистәсенә 1964 елның июнендә килдек. Эссе вакыт. Хастахәнә барагыннан каршыбызга шәфкать туташы йөгереп чыкты. Хирург Фатыйх Миңлебаевич чыгып киткән, ә шуннан соң сукыр эчәге ялкынсынган авыруны алып килгәннәр икән. Гамир Гарифович кичекмәстән операция ясарга тиеш иде… Ул кереп китте, ә мин әйберләр белән юл уртасында калдым. «Кайда соң без?»… Әмма ничек кенә булса да, табиб хастахәнә янында яшәргә тиеш, дип уйлый идек. Табибларның ул буыны акча турында уйламады да. Соңрак, безгә ике бүлмәле фатир биргәч: «Менә сиңа мә! Без монда нәрсә эшләрбез икән?!», – дип, анда әрле-бирле йөрдек тә әле.

Гамир Исмәгыйлев алга таба шәһәрнең баш хирургына әйләнә, 3 нче шәһәр хастаханәсенә нигез сала һәм аның баш табибы була. Түбән Камада медицина үсешенә зур өлеш керткән шәхес. Хәзер – Россиянең һәм Татарстан Республикасының атказанган табибы. Хатыны, акушер-гинеколог Галина Ивановна хатын-кызлар консультациясен ачу, 1 нче бала тудыру йортын төзү, 2 нче һәм 3 нче шәһәр хастаханәләрендә гинекология бүлекләрен булдыру эшендә башлап йөри.

Түбән Кама каласының төзелеше хакындагы гаҗәеп тарихларны сез шәһәрнең комплекслы музеенда ишетә аласыз. Редакция музей хезмәткәрләренә материал эшләгәндә күрсәткән ярдәмнәре өчен зур рәхмәтен белдерә.

ХРУЩЁВ ТАТАРСТАНДА. БЕРЕНЧЕ ҺӘМ СОҢГЫ СӘФӘР...

1964 елның 10 октябрь таңы. Казанга якынлашып килүче «Омик» бортында тенор тавышлы берәү, хисле итеп, «Вдоль по речке, вдоль да по Казанке...» дип моңлана. Аңа сак кына баритон кушыла. Солист – КПСС Үзәк комитетының беренче секретаре Никита Сергеевич Хрущёв. Кушылып җырлаучысы исә вазыйфасы буенча моңа лаек кеше – партиянең Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табиев...

Автор:
Әскәр Сабиров

Никита Сергеевич хисләре ташудан җырлый – биредән, су өстеннән, Казан әкияттәгедәй матур күренә. «Җепшеклек» һәм «хрущёвка»лар тудыручының үзенең кәефе дә бик шәп. Никита Сергеевич һәм аны озата йөрүче затлар «Ом-290» белән Боровое Матюшинодагы обком дачасыннан кайтып бара. Кичә аларны патшадай каршы алдылар, милли ризыклар белән сыйладылар, балык тоту да көтмәгәндә уңышлы булып чыкты.

КАРШЫЛАУ. ИХЛАСТАН ҺӘМ БОЕРЫК БУЕНЧА

«Тарихи сәфәре өчен рәхмәтле һәм аның тарафыннан хезмәттә яңа батырлыкларга илһамландырылган елга флоты хезмәткәрләре» исеменнән чәчәк бүләк итүче яшь матрос ничек тәэсирле кызара! Никита Сергеевич, билгеле ки, аның елгачы булмавын да, элгәрек әзерләнгән сценарийны бозып, дулкынланудан сөйләм сәләтен югалткан командир урынына тырышуын да белми. Ярый әле, органнарда эшләүче уңган егетләр теләсә нинди уңайсыз хәлдән чыгу өчен гел кул астында...

Ә кичә Казанда ничек каршыладылар Никита Сергеевичны! Аэропортта – пионерлардан гладиолуслар! Хәрәкәт маршрутының буеннан-буена – сокланулы йөзләр! Елмаялар, кул селкеп сәламлиләр. Ачык «Чайкада» баскан, пиджагына дүрт Герой Йолдызы кадаган Хрущёв канәгать, ул үзе дә халыкны бәйрәмгә генә кия торган эшләпәсен селкеп сәламли. Әйтерсең, юлбашчыны күреп калырга дип, үз теләге белән бөтен шәһәр чыкан.

Чыннан да, беркемне дә куып китерергә туры килми – Хрущёвны күрергә дип күпчелек үз теләге буенча, кызыксынып җыела. Әмма инде барыбер партия җитәкчелегеннән башка моның кадәр үк бердәм килеп чыкмас иде. Казанлы Борис Милицынның дистәләрчә ел узгач республика басмаларының берсендә дөнья күргән хатирәләреннән өзектә: «Мин эшли генә башлаган Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институтына, Хрущёв җитәкчелегендәге хөкүмәт кортежын каршылаганда хезмәткәрләрнең кайсы нинди урамда басып торырга тиешлеген күрсәтеп, алдан ук разнарядка килде...» – дип искә алына.

Милицынның коллегаларына Лумумба урамында «кизү торырга» боерыла, тик алар Хрущёвны күрми кала – әлбәттә инде, маршрут үзгәртелә. КДУда планлаштырылган очрашу да булмый кала. Югары дәрәҗәле кунакны берничә сәгать буе бушка көткән университет укытучыларын һәм студентларны нәтиҗәдә өйләренә кайтарып җибәрәләр. Никита Сергеевичны «Оргсинтез» заводында да, авиация заводында да көтеп җиткерә алмыйлар, гәрчә химиклар һәм самолёт төзүчеләр белән очрашу программада соңгы минуткача була. Моңа кадәр, Хрущёв сәфәренә бер ай кала ук, юлларга асфальт җәяләр, коймаларны буйыйлар һәм хәтта Ленин районындагы Кизический монастырь зиратындагы авышкан чардуганнарны, кабер ташларын да алып ташлыйлар...

Ил өчен стратегик булган предприятиеләргә (берсендә тиздән этилен һәм полиэтилен җитештерү сафка бастырылачак, икенчесендә Ту-22 бомбардировщикларын җыйлар) барудан Хрущёвның ни өчен баш тартуы сер булып кала. Ихтимал, программа куркынычсызлык ниятеннән үзгәртелгәндер. Бәлки



исә, нинди дә булса авылда, кырда үзен бик ышанычлы сизгән Никита Сергеевичның бу өлкәләрдә үзенең бәһасез киңәшләрен бирергә хәленнән килмәгәнгәдер.

КУЛДАН ИДАРӘ ИТҮ МОГҖИЗАСЫ

Ә менә инде икенче көнне Татарстанның көньяк-көнчыгышында Хрущёв үзен судагы балык кебек хис итә. Бигрәк тә «Авангард» колхозы кырларында, анда дәүләт җитәкчесенә «кыр патшабикәсенең» үрнәк плантацияләрен күрсәтәләр. Әмма әле эш кукуруз белән генә бетми бит. Колхоз рәисе Газизулла Кәрамуллинны яхшы уңыш өчен мактаганнан соң, Хрущёв сорау бирә: «Әйтегез әле миңа, чиста пардан нинди уңыш аласыз, колхоз пар басуыннан яки туңга сөрүдән ике елда күпме уңыш җыя?» Дәүләт җитәкчесенең һичшиксез шәхси катнашуын таләп иткән әлеге сорау бик озак һәм тәфсилләп тикшерелә.

Аннары исә Никита Сергеевич бәрәңге үстерүнең колхоз һәм Татарстан өчен нинди гаҗәеп перспективалар ачуы турында әңгәмәдәшенә тулы бер лекция укый: «Сез Ростов-на-Дону, Азәрбайҗан, Үзбәкстан өчен бәрәңге җитештерә аласыз...» – ди. Бүлбеләрдән мул уңыш җыю өчен кирәкле агротехниканы, табигый ки, Хрущёв рәискә шундук җентекләп үзе аңлата, мөмкин кадәр күбрәк минераль ашлама кулланырга киңәш бирә.

Минераль ашламаларның колхозга бик аз күләмдә генә бүленүен белгәч тә, Никита Сергеевич югалып калмый: «Без сезгә сатылачак бәрәңге үстерелечәк бөтен мәйданга җитәрлек минераль ашлама бирә алыр идек. Әмма бу ашламаларны билгеле бер вексель хисабына гына бирергә кирәк. Ашлама аласыз икән – вексель бирегез: әлеге ашламаны кулланудан сез сатарга яраклы күпме бәрәңге үстерәчәксез», – ди.

Хрущёв Татарстанда кулдан идарә итү могҗизасын да күрсәтә. Колхозда «Мироновская-88» уҗым бодаен чәчәргә теләүләрен, әмма орлык булмавын белеп алуга ук, өч көннән орлык могҗизалы рәвештә табыла да. Кирәкле сортлы өч тонна бодай ашыгыч рәвештә самолет белән Харьковтан кайтартыла – махсус «Авангард» колхозы өчен...

НЕФТЬ ГАЗЛЫ СУДАН АРЗАНРАК

Никита Сергеевич колхоз кырларына нефтьчеләр янында экскурсиядә булганнан соң ук килә. Байлыкны күрсәтү Карабаш тавыннан башлана, аннан әйләнә-тирәдәге берничә чакрымдагы бөтен нефть суырткычлары, бораулау вышкалары, нефть җыю парклары уч төбендәгедәй күренә. Хәтта Ромашкино чыганагының зур картасы янына куелган күзәтү торбасының да кирәге чыкмый. Нәкъ менә биредә, Карабаш тавында, Хрущёвка нефть чыгаручыларның казанышлары турында сөйләгәндә, җаваплы иптәшләрнең берсе мәгълүм гыйбарәне әйткән диләр: янәсе, татар нефтенең бер чиләге дәүләткә бер стакан газлы судан арзанракка төшә.

Сәнәгать пейзажлары белән хозурланганда, Никита Сергеевич янып торган иярчен газ факелларына игътибар итә һәм шундук кызыксына: аларның җылысын, мәсәлән, су җылыту яисә теплицаларда яшелчә үстерү өчен кулланып булмыймы икән? Яраннары дәшми калуны артыграк күрә, чөнки, Табиев фаразынча, иярчен газны берничек тә болай гына файдаланып булмый. (Бик кыйммәтле нефть чималы, иярчен газ, шуннан соң да ике дистә ел буе бер файдасызга күкне җылытуын дәвам итә – ред.иск.).

Аннары иң алдан бронялы «ЗИС» барган кортеж Азнакай ягына юнәлә, юлда барганда, Социалистик Хезмәт Герое Алексей Тимченко бригадасы Никита Сергеевичка бораулау җайланмасын ничек күчереп йөртүләрен күрсәтә. Җиде «С-100» тракторының аны яңа урынга өстерәвен күзәткәндә, дәүләт җитәкчесе тагын кызыксына: моны азрак трактор белән эшләп булмыймы? Була, әмма дәүләт нефтьчеләргә куәтлерәк тракторларны бирми, дип җаваплыйлар. Биш көннән соң «Татбурнефть» трестына куәтле дүрт «С-400» тракторы килеп җитә.

ЫШАНЫЧЫҢ БУЛМАСА – УЗМА

Никита Сергеевич белән хушлашу табыны Азнакайдан унике чакрым ераклыктагы Сәпәй (шул заманнардан бирле аны Хрущёв урманы дип йөртәләр) урманында әзерләнә. Зур чатыр, корылган табын, данлыклы Юныс Әхмәтҗанов пешергән затлы татар халык ашлары – барысы да бик югары дәрәҗәдә була. Хрущёвка токмач та, өчпочмак та ошый, әмма барыннан да бигрәк тутырган тавык күңеленә хуш килә. Фикрәт Табиев искә төшерүенчә, аны авыз иткәч, Хрущёв: «Бу тавыкларны миңа юлга куегыз», – дип боера. Юныс Әхмәтҗанов исә тиздән Ленин ордены белән бүләкләнә...

Хрущёв республикадан кутәренке кәеф белән китә. Аның «Татарстан миндә яхшы тәэсир калдырды», дигән сүзләрен китерә 1964 елның 12 августында «Советская Татария» газетасы. Сәфәр, чыннан да, бер кимчелексез диярлек үтә. Бер кечкенә генә вакыйганы исәпкә алмаганда. Кортеж бара торган маршруттагы юл буендагы бер плакатта: «Ит һәм сөт җитештерү буенча АКШны куып тотыйк!» дигән шигарь язылган була. Тик шул юл белән үк кире кайтканда плакатның икенче ягындагы ДАИ язган сүзләр күренә: «Ышанычың булмаса – узма!»

Ике айдан соң Никита Сергеевич Хрущёвны КПСС ҮК беренче секретаре һәм совет хөкүмәте башлыгы вазыйфасыннан азат итәчәкләр һәм пенсиягә җибәрәчәкләр. ■

Автор: Алсу Троицкая

БӘХЕТ ТУЛЫ ЕЛЛАР...

Якты, шатлыклы 60 нчы еллар... Аларның кайтавазы безне бүгенгә кадәр озата килә – модалы кием коллекцияләрендә, йорт җиһазлары һәм интерьер дизайнында, музыка һәм кинода. Әле ул гынамы? Ул еллар сәламе – тулы бер микрорайоннар. Бай тарихлы, энергетикалы йортлар. «Җепшеклек» рухы һәм ул буынның тормышны яңартуга һәм яхшы киләчәккә өметләнүенә шаһит өйләр.

«Хрущёвка» йортлар төзү 1959 елда башлана һәм 1980 нче елларда тәмамлана.

Гадәттә, фатирлар – бер бүлмәледән дүрт бүлмәләргә кадәр.

1
бүлмәле фатир 30 м²

2
бүлмәле фатир 43 м²

3
бүлмәле фатир 54 м²

Түшәм биеклеге
260 см

Кухня мәйданы
4,5–6,8 м²

Бәдрәф һәм ванна бүлмәсе бергә

1960 елның 17 май иртәсе, Казан. Ларионовлар гаиләсе кечкенә кухняда алмаш-тилмәш иртәнге аш ашый – берьюлы биш кеше бер өстәл артына сыеп булмый. Чәчен күпертеп ясарга өлгергән әни кеше плитә янында мәш килә. Ап-ак нейлон күлмәк кигән әти кеше тәрәзә янында «Известия»нең яңа санын укый: «Ышанасыңмы, кичә Михаил Бонч-Бруевич исемендәге Ленинград электротехник элемтә институтыннан тәҗрибә рәвешендә беренче төсле телетапшыру үткәрелгән! Тиздән төсле телевизорлар да пәйда булыр, мөгаен...»

Йомырка тәбәсе, «докторская» колбасасы һәм көйгән сөт исе тарала. Ә стена артыннан өчпочмак исе «сызып керә» – күптән түгел Казанга күченгән Ибраһимовлар әбиләрен кунакка алып килгән. Ларионовлар белән Ибраһимовларны уртак кухня дивары гына түгел, ә ике гаиләнең дә Ленин районындагы яңа йортка ярты ел элек кенә күченеп керүе берләштерә.

Ларионовларның яңа өч бүлмәле фатиры – чын җәннәт. Иң әүвәл, әлбәттә, аш бүлмәсе. Кечкенә – нибары 5,7 квадрат метр гына, аның каравы, үзебезнеке! Монда ни генә юк: газ плитәсе, савыт-саба юу өчен раковина, шкаф-буфет, тәрәзә астындагы суыткыч, ишек өстендәге антресоль, түшәм астында гына ванна бүлмәсенә караган тәрәзә. Газ колонкасы исә Ларионовларны тәүлек буе кайнар су белән тәэмин итә торган уңайлыкның иң югары ноктасы.

Ә җәмәгать мунчасында чиратта утырмыйча, үз ваннаңда юыну – нинди бәхет, нинди рәхәтлек! Дөрес, ванна бүлмәсе сыерчык оясы кадәр кенә, бәдрәф белән берләштерелгән, әмма анысы мөһим түгел. Монда тагын әле шулкадәр нәрсә куярга мөмкин! Әни кеше күрше хатын аша танышлык белән алган «Волга» кер юу машинасы өстендә әти кеше саллы гына киштә кадаклый. Анда гаиләнең уртак байлыгы – «Зенит» фотоаппаратына төшерелгән фотографияләрне ясау өчен өчен кирәк-яраклар урын ала. Ванна бүлмәсе генә димәгән бит! Безне зал, йокы һәм балалар бүлмәсе кызыксындыра.

Ларионовлар залының диварында – ясанып-бизәнеп төшерелмәгән, аклы-каралы, «тере» фотографияләр, бу һәвәскәр сурәтләр өйгә тормыш рухы һәм җылылык хисе бирә. Бирдә үк трюмо бастырып куелган, чөнки үтәли уза торган зал – бер үк вакытта ата-ананың йокы бүлмәсе дә әле. Дивар янында диван-софа торуы әнә шуның белән аңлатыла. Тагын әле шудырып ачыла торган пыялалы ялтыравык сервант, почмакта – торшер, ике кәнәфи һәм озын гына авыш аяклы тәбәнәк өстәл...

Әлбәттә инде, бигрәк тә кызларына бәхет ишелеп килде – Любаның хәзер үзенең аерым бүлмәсе бар. Хәер, җиһазлар малайларныкы кебек үк – бер кешелек карават һәм гади генә шкаф. Аның каравы, «Кызыл Октябрь» дип аталган пианино бар...

КОММУНИЗМГА КЕРЕШ

Әйе, нәкъ менә 60 нчы елларда «Ларионовлар», «Ибраһимовлар», «Ивановлар» һәм «Әхмәтовлар» гаиләләре бер гаиләгә бер газ плитәсе була алуын, ванна һәм бәдрәфкә чиратта торырга да кирәк түгел икәнен белде. Һәркем аерым фатир ала алсын өчен, рекордлы санда торак төзи башладылар. Үзенчә бер социаль торак революциясе миллионлаган совет гаиләләренә бәхет китерә. Кешеләрнең коммуналь фатирдагы күршеләреннән башка гына шәхси тормыш алып бару мөмкинлеге барлыкка килә.

«БЕР ТӨНДӘ НӘКЪ БЕР КАТКА ҮСӘДЕР БЕЗНЕҢ КАЛА»

– Әйдәгез, Хрущёв индустриализациясе башланганчы, СССР халкының 80 проценты, шул исәптән Татарстанныкы да, ничек һәм нинди шартларда яшәгәненә күз салыйк, – ди Россиянең мактаулы, Россиянең һәм Татарстанның атказанган төзүчесе **Борис Кадников.** – Бөек Ватан сугышы тәмамлануга бары тик 15–20 ел вакыт узган. Илнең Европа өлешендәге 40% территория 3–4 ел немецлар оккупациясендә булды, йөзләгән шәһәр, меңләгән сәнәгать предприятиесе, заводлар, фабрикалар җимерелгән, яндырылган. Меңләгән торак йорт, мәктәп, хастаханә, колхоз һәм совхозлар ишелгән. Бәхеткә, фашистик Германия ТАССРга кадәр килеп җитә алмады. Ул вакытта СССР хөкүмәте һәм КПСС Үзәк комитеты бар көчне илнең халык хуҗалыгын торгызуга юнәлтте. Һәм эш башкарылды да.

Хрущёв заманындагы төзелешләргә, күпләп йортлар төзи башлаганчы, һәркем диярлек бик кысанлыкта яшәде. СССРда йөз меңләгән гаилә революциягә кадәрге таш йортларда, агач бараткларда яки хәтта подвалларда

Фото: Александр Ефремов, ачык мәгълүмат чыганакларыннан.

урын алган коммуналь фатирларда яши. Ә коммуналкаларда – берничә гаиләгә бер кухня һәм бәдрәф…

Мин Казанга 1958 елда килдем. Хатыным һәм ике игезәк балабыз белән җәмәгатемнең әнисендә 18 квадрат метрлы бүлмәдә яшәдек – Карл Маркс урамындагы 38/5 номерлы ике катлы иске йорт опера театры каршында иде. Әллә ничә бүлмәле озын коридордан гыйбарәт иде ул – бөтен уңайлыклары ишегалдында булган чын кырмыска оясы. Утыз ел элек ул йортны сүттеләр. 1960 елда КПСС Үзәк комитеты һәм СССР Министрлар Советы «СССРда торак төзелешен үстерү турында»гы атаклы карарны кабул итте. Шуннан соң тормышка ашырылган массакүләм социаль төзелеш проекты күп гаиләләргә аерым фатирлар – бушлай торак алырга мөмкинлек бирде.

– 60 нчы еллар башында зур панельле йорт төзелешенең үсеш темплары бүген дә шаккатыра, – дип ассызыклый Борис Александрович. – Аның механизмы күз алдында камилләштерелә. Төзүчеләр монтаж эшен шундук үзләштерә барды, хуҗалык хисабындагы беренче бригадалар һәм участоклар барлыкка килде. «Бер төндә нәкъ бер катка үсәдер безнең кала» дигән җыр сүзләре – шул кызу төзелеш вакытыннан. 1961 елда 2 нче трест төзүчеләре өч ай эчендә Совет районында 80 фатирлы биш катлы йорт торгызып, аны файдалануга тапшырды, хәзерге Вахитов районы, Әмәт бистәсе. 1962 елда «Татстрой» идарәсенең беренче тресты коллективы 146 мең квадрат метр торак файдалануга тапшырды, ә ун ел эчендә төзүчеләр 1 миллион 565 мең квадрат метр торак күтәрде, шул рәвешле дистәләрчә мең казанлы гаиләне яңа фатир белән сөендерде.

Ул вакытта төзелеш 4–5,9 катлы йортлардан гыйбарәт иде. Аз катлы йортлар салу төзелеш темпын тизләтте һәм дәүләткә шактый арзанга төшә иде, чөнки йортлар лифтсыз гына төзелде бит. Һәм тагын бер үзенчәлек – төзелеш комплекслы алып барылды. Торактан тыш, татарстанлылар өчен ел саен йөзләгән мәктәп һәм балалар бакчасы, хастаханәләр һәм сырхауханәләр, сәүдә предприятиеләре һәм клублары сафка бастырылды.

Хәзерге яңа өй-биналар фонында халык «хрущёвка» дип атаган биш катлы өйләр бүген, бәлки, шыксызрак та күренәдер, алардагы фатирлар да заманча фатирлар белән чагыштырырлык түгел. Хәер, һәр нәрсәнең үз вакыты. Әмма нәкъ менә 60 нчы еллардагы зур панельле йорт төзелешенең шундый үсеше бик кискен торган торак проблемасын гына хәл итеп калмыйча, мондый мөһим социаль бурычны алдагы унъеллыкларда да киң колачлы һәм иҗади тормышка ашыру өчен нигез дә салган, дип саныйм. Совет кешесенең тормышы тамырдан үзгәрде.

«Хрущёвка»лар төзелеше.

АЛДА – ЯКТЫ КИЛӘЧӘК

– 60 нчы елларда төзегән йортлар, аларны ничек кенә сүксәк тә, революциядән соң халык өчен беренче торак булды, – дип саный Казанның хәзерге Мәскәү районындагы Ленская урамында урнашкан шундый өйләрнең берсендә яшәүче **Татьяна Вершинина.** Ул ире белән әлегәчә гомер кичергән фатирны 1962 елның 3 мартында ала:

– Ирем хәрби иде, аны демобилизацияләгәндә, балаларны әнием янына, Псков өлкәсенә кайтарып куйдык. Ә үзебез Казанга күчендек. Восстание урамындагы подвалда кайнана янында яшәдек. Анда 11 квадрат метрлы бүлмәсе һәм кечкенә генә кухнясы бар иде. Ә 1962 елда иремә шушы фатирны бирделәр.

Без бәхеткә күмелдек дип әйтү генә аз. Ул чакта «хрущёвка»лар гына түгел, бараклар да куаныч иде. Иремнең абыйсының гаиләсе баракта тагын ике гаилә белән бергә яши иде. Барысының да балалары бар. Аларның «диварлары» урынына – шифоньерлар һәм кара пәрдәләр. Уңайлыклардан шул электр уты гына. Суны колонкадан ташыйлар, ашарга керогаз белән әзерлиләр. Ә бөтен Казан, бөтен Татарстан халкы кебек үк, җәмәгать мунчаларында юынды. Бөтен ил буенча шулай булды… Һәм менә без фатирлы булдык, ремонт ясадык, җыештырдык, аз-маз җыелган акчага күпмедер җиһазлар да сатып алдык. Шунда ук әнием Казанга балаларыбызны алып килде.

Минем өчен ул вакыт – һәркем дә бер төрлерәк яшәгән чор, – дип елмая Татьяна Константиновна. – Һичкемнең артык мөлкәт-байлыгы чекерәеп тормады. Фатирлар бикләнми иде диярлек. Кемнән? Өсталләр бик еш зурайтыла, күчерелә иде – кунаклар күп килә. Аларны тозлы кәбестә һәм кайнар бәрәңге белән сөенә-сөенә каршылый, сыйлый идек. Үзебез дә кунакка йөрдек. Болай гына, сөйләшер-аралашыр өчен. Бер атна алдан телефоннан шалтыратып, кисәтеп тормыйча гына.

Ишегалларында агачтан агачка кер бавы суза идек. Һәр гаиләнең үз бавы бар. Ишегалларында агачлар утырттык. Без бирегә күченгәндә, монда шәхси йортлар тора иде. Тирәяктагы биш һәм тугыз катлы йортлар соңрак калкып чыкты. Агач бура өйләрдә яшәгәннәрнең күбесе хәзерге Ленская, Декабристлар һәм Тверь урамнарына күчендe. Агачлар, куаклар һәм чәчәкләр – боларның барысын да үзебез утырттык. Элек ишегалдына агач утыртырга һәркем чыга иде – бала-чагадан алып иң өлкән яшьтәгеләргә кадәр.

Гомумән, 60 нчы елларда күпләрнең бакчасы пәйда булуга карамастан, ишегалды безнең өчен аерым дөнья кебек иде. Ишегалдында һәрвакыт кем дә булса бар иде: әбиләр дисеңме, комлыкта уйнаучы сабыйлар һәм әниләрме, домино һәм кәрт сугучыларммы. Яхшы, һәркемгә аңлаешлы тормыш иде. Агачлар утырттык, балалар үстердек һәм алар коммунизмда яшәячәгенә чын күңелдән ышандык. Алда безне якты киләчәк көтә иде. Бәхет тулы еллар…

1960 нчы еллар.
Казан, Ленин урамы.
Сәлимхан Насыйбуллин фотосы.

ТОРМЫШНЫҢ МӘКТӘПКӘЧӘ ЧОРЫ

Узган гасырның 60 нчы елларында Казанда яшәгән бер гаиләгә фотосәяхәткә чыгабыз. Андый фотосурәтләр гадәттә бәрхет белән тышланган калын альбомнарда саклана. Алар теләсә кайсы вакытта үзләрен сак кына алып караганны көтеп, караучыны үткәннәргә алып китәргә әзер. Алар җуелмый, бозылмый, юкка чыкмый. Нибары тагын йөз-ике йөз елдан соң саргаерга гына мөмкиннәр.
Безнең автор Гадел Хәировның альбомына беренче йөз еллык куркыныч түгел. Альбом да, Гадел дә яшь әле, аларның гомере гасырлар белән үлчәнми. Еллар белән генә – биредә сезнең алдыгызда безнең автор һәм аның мәктәпкә кадәрге чорында үз күзләре белән күргәннәре.

Бауман урамы, ТЮЗ актёры.
А. Купцов архивыннан.

Дустым Федя Чумаков һәм Ленин бакчасындагы Тюлень фонтаны.

Фото Гадел Хәиров архивыннан

1962 ел. Үзәк загста никахлашу тантанасы. Кияү – Рево, кәләш – Рәшидә. Икесе дә инженерлар.

1961 ел. Ленин бакчасы. Валерий Грязнов фотосы.

10 нчы автобус.

1967 ел. Ана белән бала.

Бауман урамындагы атаклы «кытыршы» кибет.

Студентлар йөри торган 2 нче трамвай.

Свердлов урамы, Карл Маркс бюсты урнашкан сквер.

«Хезмәт резервлары» боксчылары. М. Горький исемендәге парк.

ТАССР

Празднование 100-летия Татарской АССР

Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү

1920–2020